ISSN 2618-9623

Төбәк тарихы буенча журнал
Краеведческий журнал

# Туган җир

# Родной край

1*2020

## № 205
## Постановление Национального правления об объявлении Волго-Уральского штата

29 ноября 1917 г.

Милләт Мәҗлесенен 29нчы ноябрь утырышында чыгарган тарихи әһәмиятле карары.

1. Русиянең идарәсе кушма җөмһүрият булырга тиеш.

2. Русия штатлары эчендә Уфа, Казан, Оренбург губерналары вә боларга чиктәш башка губерналарның төрек-татарлар торган кыйсемнәренә кергән бер штат (Җәнүби(коньяк) Урал вә Идел буе штаты булырга тиеш).

3. Бу даирә эчендә аерым кечкенә штатлар булмаска тиеш.

4. Матлуб (теләнгән, таләп ителгән) штатның чикләрен сызу вә шуны гамәлгә кую юлларын хәзерләү вә шул өлкәдә яши торган төрек вә татар булмаган һәммә халыкларның хакы булуын игътибарга алып, шул халыкларның [Учредительный] собраниесен җыю лазем табыла.

5. Хәзердән үк Милләт Мәҗлесе хозурында тупраклы мохтарият (автономия) комиссиясе төзелер.

6. Матлуб штатта яшәүче милләтләрдән мөрәккәб (кушылган, бергә җыелган) [Учредительный] собрание чакыруны Милләт Мәҗлесенең хакы танып, тупраклы мохтарият комиссиясенә шул штат тугрысындагы кирәкле ляихәне ашыгычлык белән хәзерләнеү һәм тизлек илә, Идел буе – Җәнүби Урал штатының хәдудын (чиген) сызып, Милләт Мәҗлесеннән тасдыйкъ (раслау) иттереп аларак, шул хәдуд эченә кергән бөтен кавем вә милләтләр илә килешү вә сөйләшүне тапшырыла.

7. Җәнүби Урал вә Идел буе өлкәсендә яшәүче төрек-татарларның тупраклы мохтариятенә алу эшендә һәммәсе берләшеп хәрәкәт итүләрен тәэмин итү өчен тупраклы мохтарият алуда Башкорт мәркәз бюросы һәм корылтае белән аңлашылыр. Башкорт корылтае белән аңлашу тупраклы мохтарият комиссиясенә тапшырылыр.

8. .......

9. Башкорт шурасына тупраклы мохтарият комиссиясе исеменнән бу карар белдерелә.

10. Эчке Русия төрек-татарының әксәрен (күпчелеген) эченә алган Идел буе вә Җәнүби Урал штаты ясалу мәсьәләсенең тәмамән әл-хәл кылынып бетүен көтмичә игълан кылынган милли вә мәдәни мохтариятемезне гамәлгә куюны дәвам иттерергә лазем тапты. Тупраклы мохтарият комиссиясенә түбәндәге затлар сайланды [Имзалар].

Алынды: 100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов. Казань: Изд-во «Заман», 1917. ББ. 445–446.

Бөтендөнья татар конгрессы
Татарстан Республикасы татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр
җәмгыяте

# ТУГАН ҖИР

Төбәк тарихы буенча журнал

## 1*2020

Казан – 2020

Всемирный конгресс татар
Общество татарских краеведов Республики Татарстан

# РОДНОЙ КРАЙ

Краеведческий журнал

1*2020

Казань – 2020

УДК 908
ББК 26.89 (2Рос.Тат)
Т 70

**Баш мөхәррир:**
Дамир Мәүләви улы Исхаков,
тарих фәннәре докторы

**Баш мөхәррир урынбасары:**
Борһанов Альберт Әхмәтҗан улы,
тарих фәннәре кандидаты

**Редакцион коллегия:**
Аблязов Камил
Акчурин Мәгъсум
Бәйрәмова Фәүзия
Гатауллин Ринат
Гариф Нурулла
Гыйләҗев Искәндәр
Габдрафиков Илдар
Закиров Ринат
Измайлов Искәндәр
Ситдиков Айрат
Сафин Фаил
Тычинских Зәйтүнә
Хисамов Олег
Шәйдуллин Рафаил

**Редакцион-нәшер итү төркеме**
***Җаваплы сәркатип:***
Сәгыйдуллина Мөнирә Хәлим кызы
***Корректор:***
Фәйзуллина Дания Илдус кызы

**Главный редактор:**
Дамир Мавлявеевич Исхаков,
доктор исторических наук

**Заместитель главного редактора:**
Бурханов Альберт Ахметжанович,
кандидат исторических наук

**Редколлегия:**
Аблязов Камил
Акчурин Магъсум
Байрамова Фаузия
Гатауллин Ринат
Гариф Нурулла
Гилязов Искандер
Габдрафиков Ильдар
Закиров Ринат
Измайлов Искандер
Ситдиков Айрат
Сафин Фаиль
Тычинских Зайтуна
Хисамов Олег
Шайдуллин Рафаиль

**Редакционно-издательская группа**
***Ответственный секретарь:***
Сагидуллина Мунира Халимовна
***Корректор:***
Файзуллина Дания Ильдусовна

**Басманың адресы:**
Казан шәһәре, Карл Маркс ур., 38/5
e-mail: Monitoring_vkt@mail.ru
Татар төбәк тарихы буенча кварталлык журнал
Татар һәм рус телләрендә

**Адрес издания:**
г. Казань, ул. Карла Маркса, 38/5
e-mail: monitoring_vkt@mail.ru
Ежеквартальный журнал по татарскому краеведению
На татарском и русском языках

ISSN 2618-9623

**Туган җир:** Төбәк тарихы буенча журнал [Родной край: Краеведческий журнал].
№ 1. Казан: Бөтендөнья татар конгрессы. 2020.

## Эчтәлек

*Булат Ибраһим.*
Татар булып. ........................................ 10

***Редакциядән***

Генерал сүзе. ........................................ 11

***Татарстанның 100 еллыгын каршылап***

*Р.К. Вәли.*
Тәүге суверенитет атасы… ........................................ 14

***Милли һәм төбәк тарихын өйрәнүнең фәнни-методологик яклары***

*Д.М. Исхаков.*
Кай кабиләсенең тарихы һәм Госманлылар династиясенең барлыкка килүе турындагы мәсьәлә ........................................ 34

*Р.Ф. Гатауллин.*
Башкортостан халыкларының территориаль бүленеше ........................................ 51

***Төбәк тарихы буенча фәнни мәкаләләр***

*Р.Х. Әмирханов.*
Авыл халкының социаль-көнкүреш шартларын анализлау максатында халык санын алу (ревизия) һәм метрик материалларны җәлеп итү ........................................ 61

*Р.Б. Хаплехәмитов.*
Советлардан соңгы чорда интеллигенция һәм татар теле. ........................................ 72

*А.И. Бугарчев, О.В. Степанов.*
Татарстанның Әлки районыннан археологик һәм нумизматик табылдыклар ........................................ 77

***Фәнни-популяр язмаларда төбәк тарихы***

*Ф. Ә. Бәйрәмова.*
Сөембикә ханбикәнең җинүе һәм җиңелүе ........................................ 82

*Ф.З. Яхин.*
XIV гасыр себер татар шагыйре шәех Икани турында ........................................ 89

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова.*
Курган татарларында сакланган дастаннар ........................................ 94

*И.Г. Закирова.*
Вагай районы халык иҗаты ........................................ 106

*Р.И. Вострякова, Н.С. Худякова.*
Олекмин татарлары ........................................ 116

*М.Х. Ибраһимов.*
Башкортостандагы социаль-икътисади һәлакәт: 1921–1923 еллардагы ачлык ...... 131
*Д.Н. Тажи.*
Лишуннар ...... 140
*А.Һ. Казаков*
Алтынмы, иманмы? ...... 155
*Батулла.*
Мәңгелек «Сак-Сок» ...... 158
*Г.С. Хазиева.*
Авылым кушаматлары ...... 162
*Р.Р. Яушев.*
Нәсел шәҗәрәсен реконструкцияләү тәҗрибәсеннән ...... 173
*И.З. Гарифуллин.*
Башкортостанның татар милли хәрәкәте хроникасы ...... 180

***Мирасыбызның төбәк тарихына кагылышлысы***

Идегә дастаны (дәвамы) ...... 189

***Олуг Татар иле***

*А.Н. Гәрәева-Акчура.*
Төркиядәге Солтановлар кем? ...... 202

***Шәхесләребез***

*Б.Ә. Заһиров.*
«Билгесез» тәрәккыят көрәшчесе ...... 215
*Г.П. Сәгыйдуллина.*
Себер татарларының бер зур химик-галиме турында ...... 222

***Татар рухы***

*А.Г. Хәйретдин.*
Әрвахлар өчен дога кыйлыйк... ...... 224
Татар дастаннарында милли тарих. *Р. Минһаҗ әңгәмәсе* ...... 247

***Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар***

Хроника ...... 254
«Яшьлеккә сәяхәт» ансамбленә унике яшь ...... 258
Милли-фәнни басма буларак барыйк ...... 260

***Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат. Рецензияләр***

М.М. Әхмәтҗановның «Судьбы людские» китабы турында ................261
А.Г. Бахтинның «Начало царства Казанскаго…» китабы турында ......263

***Милли ашлар, сәламәтлекне саклау юллары***

Катлы шомырт бәлеше. Кабак тәкәсе.....................................................264
Матурлык серләре .......................................................................................265

***Хушлашу***

Гәрәев Мәхмүт Әхмәт улы ......................................................................266
Бөтентатар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте кысаларында Төбәк тарихы буенча иң яхшы эш бәйгесе турында нигезләмә ............................269

***Авторлар буенча белешмә***

## Содержание

*Булат Ибрагим.*
Быть татарином ............ 10

***От редакции***

Слово Генерала ............ 11

***Навстречу 100-летию Татарстана***

*Р.К. Вали.*
Отец первого суверенитета… ............ 14

***Научно-методологические аспекты изучения национальной истории и краеведения***

*Д.М. Исхаков.*
История племени Кай и вопрос о происхождении династии Османов ............ 34

*Р.Ф. Гатауллин.*
Территориальное расселение народов в Башкирии ............ 51

***Научные публикации по краеведению***

*Р.Х. Амирханов.*
Привлечение материалов переписи населения (ревизии) и метрических с целью анализа социально-бытовых условий сельских татар ............ 61

*Р.Б. Хаплехамитов.*
Интеллигенция и татарский язык в постсоветский период ............ 72

*А.И. Бугарчев, О.В. Степанов.*
Археологические и нумизматические находки из Алькеевского района РТ ............ 77

***Краеведение в научно-популярных публикациях***

*Ф.А. Байрамова.*
Победа и поражение Сююмбике ханбике ............ 82

*Ф.З. Яхин.*
О сибирском татарском поэте XIV века шейхе Икани ............ 89

*Л.Х. Мухамметзянова.*
Дастаны, сохранившиеся у курганских татар ............ 94

*И.Г. Закирова.*
Народное творчество Вагайского района ............ 106

*Р.И. Вострякова, Н.С. Худякова.*
Олекминские татары ............ 116

*М.Х. Ибрагимов.*
Социально-экономическая катастрофа в Башкирии: голод 1921–1923 гг. ........ 131

*Д.Н. Тажи.*
Лишуны........ 140

*А.Х. Казаков.*
Золото, вера? ........ 155

*Батулла.*
Вечный «Сак-Сок»........ 158

*Г.С. Хазиева.*
Прозвища моего села........ 162

*Р.Р. Яушев.*
Из опыта реконструкции родословной ........ 173

*И.З. Гарифуллин.*
Хроника татарского национального движения Башкортостана ........ 180

***Наше историко-краеведческое наследие***

Дастан «Идеге» (продолжение) ........ 189

***Magna Tartaria***

*А.Н. Гараева-Акчура.*
Кто такие Султановы из Турции........ 202

***Известные личности***

*Б.А. Загиров.*
Борец «неизвестного» прогресса........ 215

*Г.П. Сагидуллина.*
Об одном крупном учёном-химике из сибирских татар........ 222

***Татарский дух***

*А.Г. Хайретдин.*
Помолимся за духов предков... ........ 224

Национальная история в татарских дастанах. *Интервью Р.Р. Мингазова* ........ 247

***Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики***

Хроника........ 254

Ансамблю «Яшьлеккә сәяхәт» двенадцать лет ........ 258

Мы должны быть как национально-научное издание ........ 260

***Информация о краеведческих трудах. Рецензии***

«Судьбы людские» М.М. Ахметзянова ....................................................261
О книге А.Г. Бахтина «Начало царства Казанскаго…» ..........................263

***Национальная кухня, пути сохранения здоровья***

Слоистый черемуховый пирог. Пирог из тыквы......................................264
Рецепт красоты.........................................................................................265

***Некрологи***

Гареев Махмут Ахметович.......................................................................266
Положение о конкурсе на лучшую краеведческую работу в рамках Всетатарского общества краеведов ...........................................................269

***Сведения об авторах***

*Булат Ибраһим*

## ТАТАР БУЛЫП

Яулар купса, атлар кирәк булган,
Җайдакларын көткән яу атлары.
Һәрбер заман үзе тарих яза,
Һәрбер чорның үзенең татарлары.
Безнең тарих тирән,
Тамырларын эзләп табыйм, дисәң.
Җире каты.
Кайчакларда бер арбада кайта
Батыр даны белән яманаты.

Шанлы тарих, чәнечкеле гөлдәй,
Чәнчеп ала үтеп йөрәкләргә.
Татар дигән кызу канлык гүя
Тумыштан ук безнең күкрәкләрдә.
Тумыштан ук тынгысызлык бездә.
Тумыштан ук бездә ярсу йөрәк.
Мөһим түгел нинди чорда туу,
Татар булып гомер итү кирәк!

**Редакциядән**

**От редакции**

## СЛОВО ГЕНЕРАЛА

*В ходе дискуссии по поводу установления в Российской Федерации новой памятной даты – Дня окончания Великого стояния на реке Угре (1480), были высказаны разные мнения. Одно из них принадлежит президенту Академии военных наук России, доктору исторических и военных наук, генералу армии Махмуту Гарееву, человеку весьма известному в татарском мире и в российском обществе. Уже после выхода его интервью редакция журнала запланировала его перепечатать, были планы и дополнительного разговора с ним. К сожалению, судьба распорядилась иначе – нашего знаменитого соотечественника не стало. Однако редакция решила опубликовать его интервью. По нашему мнению, оно является образцом совмещения патриотизма и любви к своему народу, обращенному в том числе и к потомкам. Всем нам можно поучиться у нашего земляка умению оставаться татарином при любой ситуации.*

*Махмут ага Гареев останется в памяти татар всего мира вот с этим своим последним интервью – Словом Генерала.*

***– Махмут Ахметович, вы являетесь одним из крупнейших специалистов по военной истории России, хорошо знаете значение ключевых исторических событий, сыгравших определяющую роль в судьбах нашего государства. Какой след в истории нашей страны оставили события Стояния на Угре?***

– В первую очередь, необходимо разобраться с понятиями. Как известно, Федеральный Закон «О днях воинской славы и памятных днях России» призван увековечить в народной памяти как победные дни государства, так и памятные даты в истории Отечества, связанные с важнейшими историческими событиями в жизни государства и общества.

О значении Стояния на Угре для обретения Московским великим княжеством независимости от ордынских ханов ученые спорят давно, и единого, устраивающего всех мнения до сих пор не выработано. Ведущие специалисты по средневековой истории нашей страны, такие как Антон Горский, Илья Зайцев, Вадим Трепавлов и другие считают, что данное событие не имело решающего значения в освобождении Руси от ордын-

ской зависимости. Такой же точки зрения придерживаются историки Академии наук Татарстана.

Можно прислушаться ко всем сторонам в дискуссии, но для меня главным остается следующий критерий – объединяет эта памятная дата все народы России или нет, способна она консолидировать современное российское общество или может вызвать определенные трения.

И здесь все не так очевидно, потому что история Золотой Орды, постзолотоордынских государств, среди которых и Московское княжество, и Крымское ханство и Казанское, является общим наследием для многих народов России. Тем более, что речь идет прежде всего о предках двух государствообразующих народов страны: русских и татар. Однобокие интерпретации этого общего наследия могут быть очень болезненными.



Что мы собираемся отмечать? Один из эпизодов борьбы за власть на развалинах Золотой Орды с неясным результатом? Мне кажется, что мифологизированную дату, по которой даже в профессиональном научном сообществе нет устоявшегося мнения.

***– То есть вы считаете, что нельзя вести речь об историческом значении Стояния на реке Угре как большой победе войск Ивана III?***

– Несмотря на то, что Стояние на Угре связано, в первую очередь, с военным событием, тем не менее, я не вижу в нем сюжета воинской славы, достойного увековечивания на федеральном уровне. Потому что не было сражения; мало того, не было внешнего захватчика, которому следовало бы дать решительный отпор. Отношения выясняли по сути два

равновеликих субъекта, считавших себя наследниками средневековой татарской державы – Золотой Орды.

Летописи свидетельствуют, что осенью 1480 г. на противоположных берегах реки Угры сошлись войска Ивана III и хана Большой Орды Ахмата. Однако сражение не состоялось, так как обе силы не решились вступить в бой. После того как великий князь дал приказ своим воинам отступить, отошел от берегов реки и хан Ахмат. Таким образом, мы не видим здесь ни проявлений воинского искусства, ни воли к победе. Скорее неуверенность в своих силах и нежелание биться до последнего.

Поэтому, на мой взгляд, надуманными являются попытки некоторых историков, вслед за Николаем Карамзиным, видеть в Стоянии на Угре проявление особого полководческого таланта и предвидения, подобного действиям фельдмаршалов Михаила Кутузова и Михаила Барклая-де-Толли в 1812 г. Тем более что политическая ситуация после 1480 г. не изменилась. Московское княжество продолжало платить «выход» ордынцам, а Большую Орду в итоге разгромило в 1502 г. Крымское ханство.

***– Какие же исторические события, по вашему мнению, достойны увековечивания на законодательном уровне России?***

– В первую очередь, те, что объединяют многочисленные народы страны вокруг великого подвига по защите рубежей Отечества. Таких примеров в нашей истории множество. Сила и слава нашего оружия, приведшие страну к победам, известны всему миру.

Ведь что такое победа? По всем классическим определениям это успех в битве, в войне при полном поражении противника, причем противника внешнего, захватчика. В этом смысле великими событиями являются победа над Наполеоном, разгром гитлеровской Германии в ходе Великой Отечественной войны и другие эпохальные сражения, в которых плечом к плечу, в едином порыве участвовали представители всех народов нашей России. То, что и сегодня является предметом общенациональной гордости.

В этой связи попытки включить Стояние на Угре 1480 г., в общем, рядового для Средневековья события, в список памятных дат истории Отечества мне представляются научно необоснованными, противоречащими реальным историческим процессам той далекой эпохи.

*Беседовал Алексей Угаров.*

*https://tass.ru/novosti-partnerov/7018249?utm_referrer=https%3A%2F%2Fzen.yandex.com%2F%3Ffrom%3Dspecial&utm_source=YandexZenSpecial*

**Татарстанның 100 еллыгын каршылап**

**Навстречу 100-летию Татарстана**

***Рәмзи Вәли***

## ТӘҮГЕ СУВЕРЕНИТЕТ АТАСЫ...

*Дәүләтчелекне яулап алуның тарихы бай һәм гыйбрәтле. 1552-нче еллардан соңгы чор татар халкының үз теле, әдәбияты, мәдәнияте һәм бәйсез дәүләте өчен көрәш чоры буларак карала ала. Казанны шактый татарларның тырышлыгы белән дә колонизаторга биргәннән соң, әле озак еллар дәверендә моның белән килешәсе килмәгән татарлар һәм башка халыклар да, корал тотып, үз-үзләрен аямыйча көрәшә. Бу эштә беренчеләрдән булып Тау ягы халкы, Казанны алганчы ук, Иван Грозныйга каршы көрәшкә чыга. Карашәм авылыннан Касыйм шәехнең һәм аның көрәштәшләренең хәзерге Төрләмә, Свияжск тирәсендәге хәрәкәтләре хакында «Карашәм шәҗәрәсе»ндә мәгълүмат сакланып калган. Бу эшкә башкортлар, мордвалар, хәтта чувашлар да шактый өлеш кертәләр... Салават Юлаев, Емельян Пугачев восстаниеләре һ.б. – болар барысы да колонизаторлар белән көрәш тарихы. Шөкер, безнең тарихчыларыбыз, бу өлкәдә шактый уңышларга ирешеп, татар халкының да бу көрәшләрдә актив катнашуын күрсәтә алдылар, әмма мондый эш әле дәвам итәр һәм яңадан-яңа хезмәтләр нәшер ителер, дип өмет итәбез.*

*Инкыйлаблар башланып китеп зур үзгәрешләр дәверенә кергәч татар егетләре, бик яшь булуларына карамастан, бәйсез дәүләт булдыру өчен көрәшне дәвам иттеләр һәм озак дискуссияләрдән соң, ниһаять, Уфада булып узган Милли мәҗлеснең татар-башкорт халкының «Идел-Урал штаты» турындагы карарын искә алмыйча, «Кече Татарстан» туды. Шулай булса да татар өметен өзмәде, түзде, инде булганына канәгатьләнеп, җиң сызганып эшкә керешә. Хәлбуки, Республиканы игълан итү (25 июнь, 1920 ел) әле суверен дәүләт булды дигән сүз түгел иде.*

### Суверенлык икетеллелектән башлана

Икетеллелек турында махсус карар кабул ителгән булса да, Сәед-Галиев Совнарком рәисе булгач бары тик Мәскәү, Сталин алдында ялагайлыгын күрсәтеп, халык мәнфәгатьләренә игътибарлы булмады. Аның өчен

төп мәсьәлә хәл ителгән – хакимият башында ул, «суллар» вәкиле. Суллар өчен инде инкыйлаб булды, милли проблемалар хәл ителде. Сәед-Галиев тә, суллар лидеры буларак, шул фикердә һәм аның өчен дә алгы планда милли проблемалар түгел, ә бары тик хакимиятне үз кулында саклап калу иде. Билгеле булганча, сул коммунистлар өчен инкыйлабтан соң милли проблемалар, имеш, хәл ителгән, без, социализм төзеп, коммунизмга барачакбыз. Аның тормыш иптәше дә рус милләтеннән иде. Нәкъ бер ел дигәндә, Сәед-Галиевнең сәясәте белән канәгать булмаганлыктан, аны «уң» коммунистлар тырышлыгы белән эшеннән азат итеп, урынына «уңнар» позициясендә торган сәламәтлек саклау министрын – Кашаф Мохтаровны – Совнарком рәисе итеп сайлап куялар. Менә шуннан ***соң, нәкъ Татарстан игълан ителгән көнне, 1921 елның 25 июнендә, Татарстанда икетеллелек игълан ителә – татар һәм рус телләре дәүләт теле итеп билгеләнәләр. Менә шушы вакыттан 1923 елга кадәр Татарстан суверен Республика буларак хәрәкәт итә***. Гомумән алганда, бу өчьеллык беренче суверенитет өчен көрәш еллары була. Шушы елларда суверенитетның төп таләпләре бик тә уңышлы рәвештә тормышка ашырыла башлыйлар. Татарстан халкы, кайсы милләттән булмасын, зур теләк белән Совнарком рәисе Кашаф Мохтаровны һәм аның хезмәттәшләренең сәясәтен тормышка ашыру эшен хуплады. Татарстан дәүләте төзелеп, суверенитетны тормышка ашыра башлау авыр дәвергә – ачлык, корылык елларына туры килсә дә эшче, крестьян, интеллигенция, хәтта партиянең Өлкә комитеты да каршы килмәде, киресенчә, бөтен коммунистлар вакытлыча булса да бердәм хәрәкәт иттеләр.

Озак еллар дәвамында беренче суверенитет турында сүз булмады, ә Кашаф Мохтаровның хакимияте, кылган эшләре хакында язарга ярамады, чөнки ул халык дошманы булып йөрде. Мондый проблемалар татар тарихында бик күп.

Дәүләтчелек өчен беренчеләрдән булып XIX гасырның 60-нчы елларында көрәш башлаган Мулла Иле (Яшел Үзән районы) авылы имамы Баһаветдин әл-Болгари Вәисов тарихын 100 елдан соң гына өйрәнә башлаган идек, Аллага шөкер, 1990 еллардан соңгы чорда яңа чыганаклар һәм махсус мәкаләләр, китаплар, ә 2011 елда бу тарихка багышланган аерым диссертация да якланды һәм расланды. Аның авторы – Мулла Иле авылы егете Шәкүров Камил Равил улы (җитәкчесе – фәкыйрегез).

Баһави әл-Болгари Вәисинең дәвамчысы, гайрәтле һәм сөйкемле акыл иясе – улы Гайнанетдин әл-Болгарины да фаҗигале рәвештә 1918 елның 1 мартында атып үтерәләр. Бу хәрәкәт тарихы да озак еллар дәверендә өйрәнелмәде, чыганаклар, ябык фондларда сакланып, алар хакында тузга язмаганнарны язып, советлар чорында ул шәхесләргә пычрак ыргытып

тордылар. Бу турыда совет тоталитар режим чорында хәлләрнең ничек булганлыгын Гайнанетдин Вәисов әл-Болгариның кызы Хаҗәр Вәисованың КПССның ҮК генераль секретаре М.С.Горбачевка язган хатыннан яхшы күренә. Бу хат – чын тарихи документ. Ул, милли хәрәкәттә катнашкан вәисиләрнең тарихын дөрес язмаулары белән беррәттән, аның җитәкчеләренә пычрак атучыларга чик куярга чакыра. Үзләренең хәлләренә килгәндә, алар өчен тормыш «мучительно и горько» иде, ди [Валеев, Валеева: 2010. Б. 196–202].

XIX гасырның 60-нчы елларыннан соңгы чорда ук Баһаветдин әл-Болгари татарларның дәүләтчелеген кайтару хакында патша хөкүмәте белән көрәш башлый. Шул вакытта Татарстан Республикасы булмаганлыктан, ул Болгар дәүләтенә таянып фикер йөртә, аны торгызу хакында сүз алып бара... Патшага язган бер хатында ул: «Без сезне яратабыз, хөрмәт итәбез, догалар укыйбыз, әмма сезнең дәүләтегез безгә кирәкми», – ди. Аның дәүләтчелек мәсьәләсен күтәреп чыгуы үзе бер батырлык булган. Бигрәк тә ул заманның законнарын искә алсаң. Бәйсез дәүләтчелекне таләп иткән Баһави Вәисов әл-Болгари 10 ел психиатрия больницасында ятып, шунда һәлак булды [Вәлиев: 2007].

Шушы хәрәкәт тарихын революциядән соңгы чорда язырга рөхсәт ителмәде. 1965 елда аспирантурага кергәч, ул хәрәкәт белән кызыксынуымны яратмадылар, диссертация, монографияләремә ул турыда кертүне тыйдылар. Мин берсен дә тыңламадым, яздым, әмма 10 ел дәверендә гел уңайсызлыклар белән яшәдем. Докторлык диссертациясен яклау да озакка сузылды (1976 елда әзер эш, төрле сәбәпләр аркасында, бары тик СССР җимерелә башлагач кына – 1990 елда якланды һәм бер ай эчендә расланды).

Хәзер мөмкинлекләр башкачарак. Шуңа күрә моннан файдаланып, үзебезнең чын көрәш тарихын бернәрсәгә дә карамыйча язуны дәвам итәргә кирәк.

Тоталитар режимның корбаны Кашаф Мохтаров һәм аның хезмәттәшләренә кагылган тарих та озак еллар дәверендә «секретный» фондларда сакланды һәм беренче суверенитет тарихы, аның төп идеологы Кашаф Мохтаров турында язырга ярамады. Бары тик 1990 елларның азагында гына аның Үзәк архивта сакланып калган кайбер материаллар, Дамир Шәрәфетдинов тырышлыгы белән, Казан архивына кайтарылды. Россия дәүләт архивы җитәкчесе В.Козлов та бу эштә зур булышлык күрсәтте. Аннан соң партияләр архивында Кашаф Мохтаровның шәхси «эше» булдырылды. Монда бөтен чыганаклар булмаса да, бу «эш» аның кем булуы һәм ничек Республика белән җитәкчелек иткәнлеген шактый ачык тасвирларга мөмкинлек бирә.

## Кем соң ул Кашаф Мохтаров?

*(1896–1938)*

Ул 1896 елда Казан губернасының Лаеш өязе Тауиле авылында крестьян семьясында туа. Пермь шәһәрендә гимназиядә укый һәм университетта медицина буенча белем ала. 1918 елда большевиклар фиркасенә керә. 1918–20 елларда Пермь губернасы Башкарма комитетының әгъзасы. Ул анда милли комиссариат белән җитәкчелек итә. Гражданнар сугышында да катнашып өлгерә. Блюхерның 51-нче дивизиясендә мөселман полкының политругы була, аннан 3-нче армиянең политругы.

Егерме бер яшьлек Кашаф Мохтаров, шулай итеп, үзен чын көрәшче икәнлеген күрсәтеп өлгерә.

Озак тартышулардан соң, 1920 елның 25 июнендә Татарстан Республикасы игълан ителгәнлеге барыбызга да мәгълүм, әмма аны тормышка ашыручылардан Сәед-Галиев, Солтан-Галиев яисә Мулланур Вахитовларга гына басым ясыйлар. Һичшиксез, бу эштә алар да зур өлеш керткәннәр. Ләкин М. Солтангалиев һәм М. Вахитовларның «Болак арты республикасы» белән көрәшләрен дә онытырга ярамый. Алар менә монда Ильяс Алкин, Галимҗан Шәрәфләр, Газиз Монасыйповлар кебек көрәшкән булсалар, бәлкем, бәйсезлеккә якынрак килгән булыр идек, әмма... Солтан-Галиев соңрак бу турыда үзе дә хата ясаганлыгын әйтеп узды. Ул 1918 елда Алкиннарны кулга алган булса, 1923 елда аның үзен Сталин кулга алды, партиядән куды, соңрак Соловки лагерларына озатып, аттырды.

Татарстан Республикасы игълан итү алдыннан Мәскәүдә Вакытлы революцион комитет төзү буенча И. В. Сталин зур эшләр башкара. Аның рәисе Мирсәет Солтан-Галиев булырга тиеш булса да, И. В. Сталин бу урынга тыңлаучан, һәм «генеральная линия»не хуплап торучы, буталчык суллар вәкиле Сәед-Галиевнең кандидатурасын вакытлы ВРКка (Вакытлы революцион комитет – Р. В.) тәкъдим итә. Бу инде аның беренче Совнарком рәисе булачагына ишарә дә ясый. Монда синең белемең, халкыңның сиңа карата мөгамәләсе, тәҗрибәң дә искә алынмый. Сталинның бу теләкләре «Үзәктә» дә хуплана. Урыннардагы булачак җитәкчеләрнең белеме аннан-моннан гына булып, алар инициативасыз, куркак, явыз хәтерле, сүз тыңлаучан булырга тиешләр иде. Бу самодержавие сәясәтенең дәвамы итеп түгел, ә шовинизмның дәвамы буларак каралырга тиеш. Әлеге сәясәт исә, белгәнегезчә, бүген дә дәвам итә.

Объектив сыйфатлары белән ВРКка рәислеккә төрле яктан килгән Мирсәет Солтан-Галиевне И. В. Сталин өнәми һәм аннан баш тарта. Бу татар милли көрәшчеләренең башына сугу булганлыгы бүген инде билгеле. Ул вакытларда М. Солтан-Галиев милли мәсьәләләргә кагылган бик

күп мәкаләләр яза, чыгышлар ясый һәм И.В.Сталинның үзен, хәтта ленинизмны да тәнкыйтьләп китү юлына баса. Әлбәттә, инде Казандагы «Болак арты республикасы» белән актив көрәшкән, большевикларга чын күңеленнән ышанып хәрәкәт иткән Солтан-Галиев тә үзенең алданганлыгын сизә башлый. Менә шунда инде ул милли сәясәтнең Советлар тарафыннан халыкларны алдау сәясәте икәнлегенә төшенә башлап, үз фикерләрен ачык рәвештә конференция, җыелышларда сөйли. Әлбәттә, мондый акыллы, кыю фикер иясенең И.В.Сталинга да, гомумән, Үзәккә дә кирәге булмаган. Шулай итеп, төп роль Сәед-Галиевкә тапшырыла... Ул ВРКның рәисе итеп куела.

Менә шушы комитет составында халыкның исәнлеген саклау бүлеге җитәкчесе итеп Кашаф Мохтаров куела. Ул – Сәед-Галиев белән капма-каршы фикердә торган кеше. Сәед-Галиев «сул коммунист» булса, Кашаф Мухтаров «уңнар» ягында иде.

***Уңнар*** милли мәсьәләләрне хәл итү ягында һәм алар бу өлкәдә бөтен эшне ***урыннардагы үзенчәлекләрне искә алып эшләргә өндәделәр***. Икътисади өлкәдәме яисә тел, мәдәният, тарих, сәясәт – болар барысы да урындагы үзенчәлекләрне искә алып эшләгәндә генә уңышка ирешүгә мөмкин икәнлеген турыдан-туры алга куеп хәрәкәт иттеләр алар. Эшләр бу дәвердә Татарстанда тиз арада уңай якка борыла. Хәтта 90% якын руслар һәм башка милләтләр дә татар телен өйрәнергә тотындылар. Нәтиҗәдә чын-чынлап төрле милләтләр арасында дуслык мөнәсәбәте туды. ГПУдан киткән бер чыганакта Татарстанда тынычлык, бернинди ризасызлык юк, диелә. Менә инде бу Кашаф Мохтаров хакимиятенең бер җимеше, дип каралырга тиештер. Шушы чорда Карашәм авылында яшәгән Р.Абдюшев исемле шәхес үзенең язмасында: «Ул вакытта авылда яхшы хәрәкәтләр башланды: мәктәпләр ачылды, кирәк-ярак барлыкка килде, кибетләрдә кадак, тоз, ситсы һ.б. товарлар булдырылды», – дип күрсәтә. – Крестьяннар артык продукцияне базарларда сата башладылар», – ди ул тагы. Бу чыннан да шулай булган. Автор үзенең язмасында татарлар белән руслар арасындагы реаль тигезлек урнашуын күрсәтә [Кульязма бездә саклана].

Мохтаровның Сәед-Галиевтән аерылып торган ягы тагы шул – ул Үзәкнең күрсәтмәләре белән дә санашмаска әзер торган шәхес булган. Сталинның «генеральная линия»се белән беррәттән урындагы үзенчәлекләрне искә алып сәясәт алып баруны таләп итә бу җитәкче. Өч ел эчендә ул татар милләте өчен бик зур эшләр эшләп өлгерә. Әлбәттә, берүзе генә түгел. Аның 15кә якын хезмәттәшләрен әле 1924 елда, Кашаф Мохтаровны урыныннан алгач, Сталин төрле районнарга куып тарата. Имеш, бергә булып шул ук сәясәтне дәвам итә алмасыннар. ***Яхшы сәясәт өчен барысы да Сталинны гына тыңларга тиешләр иде...***

«Уң» һәм «сул» коммунистлар арасындагы аңлашылмаучылык белән Мәскәү, бигрәк тә Сталин, бик оста файдаланган. Алар арасына, мөмкинлек булган саен, ут салып, аларны чәкәштереп торган. Бу эшкә ул әле революциягә кадәр үк тупланган үзара бәрелешләр тәҗрибәсен кулланган.

Мирсәет Солтан-Галиевнең язуына караганда, «суллар» һәм «уңнар» арасындагы көрәш, 1918 елда булып узган Шәрык коммунистларының беренче съездында кискенләшеп, икегә аерылышу нәтиҗәсе була.

Беренче группа «вахитовчылар», ә Вахитов һәлак булганнан соң «солтангалиевчеләр», дияргә була. Чөнки ул уңнарның җитәкчесе итеп каралды. Бу группада Кырымнан Фирдевс һәм төрек коммунистлары җитәкчесе Мостафа Сөбхи да булган.

Икенче группа үзләрен «интернационалистлар», «сул коммунист-бухаринчылар» дип исемләп, уңнарны «милләтчелектә» гаеплиләр. Болар милли-колониаль проблемаларны инде чишелгән дип карыйлар, алар өчен милли мәсьәлә инде Октябрь революциясе тарафыннан ук хәл ителгән. Хәзер аларның ***төп максатлары – хакимиятне үз кулларында тоту***. Икенче съездда бу бүленү көчәя төшә. Сәед-Галиев, тагы 12–13 кеше, Солтан-Галиев һәм аның группасына каршы көрәш ачалар. Бу атака өч юнәлештә була. Ул турыда Солтан-Галиев болай ди: «Нападение на нашу группу происходило в трех направлениях:

а) Со стороны противников идеи Татаро-Башкирской республики. Тут соединились два противоположных течения: Шамигулов и попавший под влияние башкирских националистов Каспранский. Нас обвиняли в «связи» с бывшими левыми эсерами, якобы вошедшими в партию для ее взрыва изнутри;

б) Со стороны «левой группы гумметистов» в лице Нариманова и Исрафилбекова, обвинявших нас в шпионаже и связи с германскими шпионами, с одной стороны, с агентами панисламистов, с другой – в лице Рашит казый Ибрагимова и Баракатуллы;

в) Со стороны Саид-Галиева, который старался доказать, что мы в сущности ничем не отличаемся от наших националистов» [Султангалиев: 1998. С. 286].

Бу аерылулар Сәед-Галиев Татреспублика Ревкомы рәисе булгач тагы да тирәнәеп китә. Солтан-Галиевнең «Углубление раскола» дигән язмасында түбәндәге юлларны укыйбыз: «Произошло это, с одной стороны, потому, что в вопросе получения Татреспублики Саид-Галиев проявил крайнюю бесхарактерность, неустойчивость и беспозвоночность. Ответственным татарским работникам он заявил, что «добьется у Центра так называемой «большой» Татарии (Идел-Урал Республикасы яисә Татаро-Башкирская Республика) и что в случае отрицательного разрешения

вопроса Центром «бросит все и уйдет». Это же настроение им было передано и на места. Перед центром же Саид-Галиев выставлял себя совершенно иным, а именно: что ему все равно – будет Татреспублика или нет. И когда на заседании Политбюро ЦК партии представители местных татарских работников заявили, что они не берут ответственности за создание «малой» Татарии, Саид-Галиев заявил о своей готовности работать и в «малой» Татарии. Ясно, что после такого шага Саид-Галиева татарские работники простить ему не могли. Они восприняли его как ренегата» [Султангалиев: 1998. С. 287].

Шуңа күрә Казан аны салкын каршы алды. Ләкин ул үз хәлен яхшыртасы урынга республикада «чистарту» эшен башлап җибәрә. Төп һөҗүмне ул «татаристларга» каршы юнәлдерә. Икенче төрле итеп әйткәндә, милли проблемаларны дөрес итеп хәл итүне таләп иткән коммунистларга каршы ут ача ул. Хәтта Уфада нәшер ителгән «Шәрык ярлылары» газетасы да, аның кыланышларына бәя биреп, «нами из достоверных источников получены сообщения, что в Казани образовалась группа твердых коммунистов для решительной чистки Татарской Республики от татарских националистических коммунистов», дип язып чыга [Султангалиев: 1998. С. 288]. Кыска гына вакыт эчендә 15тән артык төрле өлкәләрдә хезмәт итүче җаваплы эшчеләр эшсез калалар. Бу эш өязләр, волостьлар масштабында да алып барыла. Сәед-Галиев татар коммунистларының (РКП-нең) секциясен бетерүдә, татар хәрбиләренең курсларын ябу өлкәсендә дә зур тырышлык күрсәтә. Центрмусвоенколлегиягә һәм аның органы булган «Кызыл Армия» газетасына да пычрак атуны башкара. Шулай итеп, дәүләтчелек туып кына килгәндә янә көрәш куера, тирәнәя. Моның башында «суллар» һәм аларның җитәкчесе Сәед-Галиев булганлыгы көн кебек ачык.

Шушы көннәрдә үк аның сәясәте белән «танышкан» күпчелек яңа «революция» әзерли башлый, әмма моны бары тик Сәед-Галиев һәм ул җитәкләгән Совнарком гына күрми, ишетми... Менә шуңа күрә дә аның «рәислеге» озакка сузыла алмый. Аны бер ел дигәндә эшеннән алып аталар, моны «уңнар» оештыра һәм аның урынына халык сәламәтлеген саклау бүлеген җитәкләгән яшь егет Кашаф Мохтаров сайланып куела.

Бу очраклы хәл түгел иде. Әле Татарстан Республикасын игълан итү һәм оештыру өчен төзелгән ВРК белән канәгать булмаган «уңнар» шулвакытта ук аңа каршы хәрәкәт башлап җибәрәләр. Бу дәвердә «уңнар»ны турыдан-туры Кашаф Мохтаров, Юныс Вәлидов, Исхак Казаков, Шамил Усманов, Фирдевс, Енбаевлар җитәклиләр. Бу турыда Микдат Борындыков түбәндәгене язып калдырган: «Мы с одобрения Султан-Галиева решили саботировать Ревком во главе с Саид-Галиевым и как можно ско-

рее провалить его. На II съезде Советов действительно правым удалось провалить левых, причем правые играли на самых больных струнах населения; они распространяли слухи о том, что голод в Татарии ужасающие размеры принял потому, что Саид-Галиев, желая выслужиться перед Москвой, весь хлеб из нее (Татарии) выкачал в другие области» [Султанбеков, Малышева: 1966. С. 199]. Нәтиҗәдә «уңнар» 1921–23 елларда Республика белән җитәкчелек итәләр. Ә Кашаф Мохтаров Совнарком рәисе итеп сайланып куела. Татарстанның Үзәк Башкарма комитеты рәисе итеп Рәүф Сабиров, Мәгариф халык комиссары итеп М. Борындыков сайлана.

Кашаф Мохтаров һәм «уңнар» хакимиятлек иткән чорны «Кашаф Мохтаров хакимияте» дип атау да дөреслеккә туры килә, чөнки ул, зур акыл иясе буларак, барлык өлкәләрдә дә үзен кыска вакыт эчендә күрсәтеп өлгерде. Шуны да истә тотарга кирәк – бу вакытта барлык проблемалар «уңнар» тарафыннан үзара киңәшләшеп эшләнелә. Партия, Совет органнары оештырган җыелышларга алар күмәк фикер белән килеп, дискуссияләрдә катнашып, зур җиңүләргә ирештеләр. Бу эштә кыюлык күрсәтүчеләрдән Кашаф Мохтаровның үзен һәм аның фикердәшләреннән Рәүф Сабировны, Ариф Енбаевны, Гасыйм Мансуровны, Микдат Борындыковны, Юныс Вәлидовны атап китәргә кирәк. Бу үзәкнең җыелышларында тагы Николай Петров, Әхнәф Шакиров, Исхак Казаков, Абдулла Вәлиев, Хафиз Сәйфи, Саттар Еникеев, Әхмәд Умаров, Максудов, бертуган Балтановлар һәм башкалар да катнашканлыгы билгеле. Аерым очракларда «уңнар» активы җыелышлар да оештыралар.

Кашаф Мохтаров хакимияте ***гаделлек сәясәтен*** башлап җибәрә: тиз арада татарларны зур елгалар, зур юллар тирәсенә кайтару, шулай ук татар яшьләрен вузларга тарту, татарларны дәүләт учреждениеләренә җәлеп итүне куәтләү һәм татар телен тормышка ашыру, аны чын дәүләт теле итеп карауны таләп итү – бу өлкәләрдә бик күп эшләр эшләнелә. Аларның программасында татар авылларына льготалар белән кредит бирү, татар эшчеләрен арттыру, татар банкын төзүләр һ. б. да каралган булган. Татар теленә килгәндә, Кашаф Мохтаров хакимияте 1921 елның 25 июнендә ***татар телен дәүләт теле итеп игълан итүгә ирешә. Минә шушы вакыттан Татарстанда беренче суверенитет башланды да инде***. Шушы чорда фәнгә караш та уңай якка үзгәрә. Хакимият татар халкының тарихын дөрес итеп язуны таләп итә, нәкъ бу чорда Татарстанда Академик үзәк төзелә. Кашаф Мохтаров Академүзәккә зур игътибар биреп, матди ярдәм күрсәтеп тора [Фаттахова, Валеев: 2002. С. 17]. Шушы чорда М. Худяковның «Казан ханлыгы», Галимҗан Шәрәфнең һәм башка галимнәрнең хезмәтләре барлыкка килеп, татар телен тормышка ашыруның дөрес тарихын язудан башланып киткәнлеге күренә.

Тагы шуны да әйтергә кирәк: Сәед-Галиевне Кашаф Мохтаров белән алыштыру ул гади үзгәреш кенә түгел иде, чөнки Кашаф Мохтаров үзе белән Совнаркомга, партиянең Өлкә Комитетына, гомумән, Татарстанга, уңай микроклимат алып килде. Мондый үзгәрешләр тарихта булып торалар, әмма алар татар дөньясында сирәк күренеш. Шул уңайдан, 1990 еллар микроклиматы да махсус өйрәнүне таләп итә, бу елларда булган үзгәрешләр алар беренче суверенитетның дәвамы дип каралырга тиештер. Кызганычка каршы, тарихчылар, сәясәтчеләр ул чорда 1921–23 еллар тарихын, Кашаф Мохтаров хакимиятенең тәҗрибәсен файдалана алмадылар. Ә ул хакимиятнең уңышлары – милли мәсьәләне хәл иткәндә урындагы үзенчәлекләрне искә алып, шуларга басым ясаудадыр. Менә шуңа таянып, үзбилгеләнүне тормышка ашырырга мөмкин булды. Бу инде бәйсез дәүләт төзүне алга кую дигән сүз иде. Октябрь революциясенә барганда һәм Гражданнар сугышы чорында татарларга барын да бирергә вәгъдә иткән Үзәк, тиз арада сәясәтен үзгәртеп, урындагы мондый хәрәкәтләр белән киң планда көрәш башлады, хәзер дә шул ук кабатланды.

1923 елның июнь аенда Мәскәүдә РКПнең яшерен киңәшмәсендә солтангалиевчелекне тәнкыйтьләп, СССРда киң планда «милләтчелек-солтангалиевчелек» белән көрәш башланды. Бу исә И.В. Сталинның татарларга гына түгел, ә башка Шәрык милләтләренә каршы сәясәте дә иде. Нәтиҗәдә солтангалиевчелектә гаепләнеп, бик күп Сталинны өнәмәгән, аның халыкларны ялгыш юлга этәрүен алдан күреп фикер йөрткән әһелләрне эш урыннарыннан алып, Рәсәй буйлап йөртеп, Татарстаннан аерып, аннан соң лагерларга озатып, Сталин өчен куркынычракларын физик яктан юк итү булды. Бу бигрәк тә 1930-нчы еллар ахырында һәм сугыш башланган чорда күренде. Хәтәр чор иде бу дәвер...

Бу сәясәт И.В. Сталинның һәм аның хезмәттәшләренең «генеральная линия»сенә каршы килә, чөнки алар урындагы үзенчәлекләр белән санашмыйлар, гомумән, халыклар язмышы аларны бөтенләй кызыксындырмый. Татар теле, татар алфавиты, татар дәүләте аларның бер планнарында да юк иде. Ничек кенә булмасын, халыкларны алдарга, аларның алга барышын туктатырга тырыштылар. Менә шушы мәкерле фикер иясе И. Сталин, «солтангалиевчелек»не уйлап чыгарып, киң планда милли кадрларга атаканы башлап җибәрде. Бу нәкъ Кашаф Мохтаров хакимиятен җимерү чорында – июнь аенда, 1923 елда Мәскәүдә үткән РКПнең яшерен киңәшмәсендә башкарылды. Шушы елның ахырында, 1924 елның март-май айларында Кашаф Мохтаров һәм башкалар да эш урыннарыннан алындылар.

Бу киңәшмәдә Сәед-Галиев, Кашаф Мохтаров, Рәуф Сабиров һ.б. да катнаштылар һәм чыгышлар ясадылар. Казан Совнаркомының рәисе Ка-

шаф Мохтаровның чыгышын без тулы килеш бирергә булдык, чөнки ул укучыларга бик үк билгеле түгел. 1923 елның 10 июнендә ул «киңәшмәнең» икенче утырышында чыгыш ясый. Утырышның рәисе Каменев иде. «Уңнар»ны тәнкыйть итеп, Фрунзе дә чыгыш ясый: «Для меня султангалеевщина... есть не что иное, как выражение мелкобуржуазной идеологии, прикрывающейся коммунистическим флагом», – ди ул [Тайны национальной политики ЦК РКП: 1992. С. 53]. Аннан соң Орджоникидзе, Скрыпник, Мануильскийлар чыгышлар ясап, үзләренең чын шовинистлыкларын күрсәтәләр. Менә инде шулардан соң, ниһаять, Кашаф Мохтаровка да 10 минутлык вакыт бирелә. Оста оратор, тирән фикер иясе монда да үзен сынатмады.

«Товарищи, мне хочется остановить ваше внимание на некоторых моментах обсуждения вопроса для того, чтобы не могло создаться хоть тени односторонности под впечатлением речей некоторых товарищей. Ведь ***задачей совещания,*** как отметили тов. Каменев и тов. Куйбышев, является необходимость ***добиться взаимного понимания***. А это понимание может ускользнуть, если удариться в односторонности и, особенно, если будем говорить не на тему.

Султан Галиев до последнего времени в татарской среде был известен и популярен как революционер-большевик. Работал в Красной Армии и во многих пролетарских учреждениях, на самых ответственных постах. И не случайно, как думает тов. Орджоникидзе, участвовал в формировании отдельных частей, а также в широкой работе и в самые критические минуты был вне каких-либо подозрений. Дальнейшая его работа и выдвижение до крупных постов в Москве, где он состоял членом коллегии Наркомнаца и председателя Федкозема, утверждает нас в убеждении, что не случайно объясняется нахождение его внутри нашей партии. Если таким образом мы устанавливаем неоднократно выраженное ему в процессе его выдвижения доверие партии, то согласитесь, могло ли быть странным доверие к нему работников татар, башкир и других? По-моему, в этом ничего странного нет. Если мы категорическим образом отмеже[вы]ваемся от его контрреволюционного поступка, то все же мы не можем отрицать, что в период революционной его работы мы шли с ним и во многом он помогал революционному развитию среди нас. Лично я считаю, что преступление не может являться логическим завершением, как некоторые старались доказать, прирожденного его национализма. Здесь уже говорили, что такой теории и практики нет и не было. Я думаю, и ЦК может подтвердить, что в прошлой деятельности Султан-Галиева выражений контрреволюции не наблюдалось, и мы, я заявляю, не видели их. Стало быть, момент зарождения преступления

есть формация последнего периода и в этом меня убеждает та окружающая обстановка, которая была в период X съезда Советов почти вплоть до XII съезда партии. Как писал Владимир Ильич, ***чуждый нам советский аппарат воспринял постановления X съезда Советов, как ликвидацию всех самоопределений. В силу ряда обстоятельств во главе этого «самодержавного» аппарата оказался И.В. Сталин***. А волна таких же чаяний прокатилась по всей периферии. А в это время проведение вопросов национальных республик здесь не в пример осложнилось и затруднялось. На это много примеров, даже на практике сношений у Татреспублики. Взять хотя бы проведение земельного кодекса. Ведь пришлось аппеллировать в Политбюро, чтобы добиться удовлетворения справедливых требований. ***И не зря тогда говорили, что необходимо на каждые двери Наркомзема приклеить вырезки из программы партии по национальному вопросу***. В этот период создалась, таким образом, обстановка возбуждения. И на острие давления оказался, в силу своего положения, Султан-Галиев. И могло быть так, что независимо от логического хода мыслей, он мог совратиться, совсем свихнуться с пути. Я этого говорю отнюдь не в оправдание хоть на тысячную долю поступка Султан-Галиева. Еще раз заявляю, что его поступок мы резко и категорически осуждаем.

Дальше я должен остановиться на ошибочной оценке Татреспублики, как имеющей наличие националистичности, что называется преступлением Султан-Галиева. По-моему, это просто голословно. На чем зиждется это обвинение? На том ли, что Султан-Галиев писал письма татарским работникам (оговариваюсь – никогда ни об одном басмаче он нам не писал) – на том ли, что Султан-Галиев использовал курьеров Татпредставительства не по назначению? – или потому, что татарские работники встречались с ним в прошлой революционной деятельности? Невольно создается впечатление, что ***обвинение дано слегка несерьезно***. А обвинение очень тяжелое. Особенно, когда годами идешь в ногах в рядах партии, когда ***в самых трудных условиях налаживаешь не только работу в национальной республике, но и добиваешься взаимного понимания с русскими товарищами, когда хоть частично достигаешь сознательной поддержки Советской власти отсталыми татарскими крестьянами*** и, наконец, когда наши же воспитанники двух командных татарских курсов в Казани в полном составе сражаются в Бухаре против басмачей и удостаиваются наград и похвал высшего командования, – ***в этот момент обвинить в измене революции этих же татарских работников, простите, абсурдно***. Тем более ЦК, в лице секретарей (это подтвердит тов. Сталин) не раз одобрял нашу линию поведения и всю деятельность. Поэтому думаю, что надо было обследовать

в начале нашу деятельность поближе и тогда делать выводы. А некоторые товарищи в своих сопоставлениях идут очень далеко и не к месту используют свое орудие. Они сваливают все в одну кучу,–как, здесь, например, вытащили вопрос о бывшей борьбе левых и правых и старались спутать его с разбираемым вопросом.

***Голос***. О нас не беспокойтесь.

***Мухтаров***. Я о вас не беспокоюсь, наши территории разные.

***Сталин***. Дорога одна.

***Мухтаров***. Да, дорога одна, все на тот свет придем… Мне кажется, что делать этого нельзя. Нельзя, потому, что элементы обоих группировок остаются в партии и с контрреволюцией ничего общего не имеют. Тов. Каменев здесь уже прерывал одного товарища, прося говорить только по теме, и надо полагать, что основные прения по затронутым в повестке вопросам будут обсуждены у своего места, но поскольку здесь уже касались хотя бы этой правизны и левизны, я принужден сказать дватри слова.

Бухарин очень хорошо сделал, заявивши, хотя и поздно, на XII съезде о своей ошибке, как о глупости. Но ведь его постановка питала таких, как Шамигулов. Они противопоставляли себя ленинскому толкованию национального вопроса. Мы работали в Татреспублике по ленинской школе. Наши расхождения в условиях Татреспублики углубились до X съезда партии, когда левые не различали никаких особенностей в социально-экономическом состоянии разных национальностей. Мы же говорили о необходимости учета разности стадий социально-экономического развития. X съезд партии правильность такого взгляда подчеркнул особенно точно, оговорив, что система кавалерийских набегов в революционизировании, например, Туркестана, никуда не годится. И только после этого левые внешне признали свои ошибки и признали необходимость отказа от идеалистического уклона.

Подробнее этих моментов мы, видимо, коснемся при обсуждений дальнейших пунктов повестки совещания. Коснусь лишь заявления Саид-Галиева, который сказал, что его в 1921 г. выгнали из Татреспублики в 24 часа, как ставленника Москвы. Такое заявление, конечно, можно встретить только с улыбкой. Ведь мы живем не в стране Керзона. Я расскажу, как обстояло дело фактически и что можно всегда проверить на основании документов в архиве Областного комитета Татреспублики. Дело в том, что Областной Комитет и партконференция констатировали неработоспособность состава правительства во главе с Саид-Галиевым и постановили из деловых соображений освежить этот состав, заменив некоторых. После этого тов. Саид-Галиев…

***Саид-Галиев***. Конференция сколькими голосами это констатировала?

***Мухтаров.*** Большинством.

***Саид-Галиев.*** 46 – против, 52 – за.

***Мухтаров***. Ваше дело собирать цифры. Так вот, тов. Саид-Галиев на другой день после решения областного комитета созывает коммунистов татар из обеих бывших группировок (и своей, которая называлась левой, и тех, которых называли правыми и ставит вопрос о необходимости блокированного выступления против русских коммунистов…).

***Саид-Галиев***. Ложь.

***Мухтаров.*** Я докажу это документами. Они говорили, нужно ополчаться против русских, потому что те хотят постоянной сменой работников татар сами управлять республикой. Согласитесь, можно ли быть человеком принципиальным и так бросаться из одной крайности в другую? Те, кого называли правыми, заявили, что это антипартийно и националистично и отказались от всякого участия в этом вопросе. Дальнейший ход был таков, что один из участников Саид-Галиева, тов. Касимов, кинулся в агитацию среди беспартийных делегатов съезда против указанного постановления ОК и тем самым уже выявил опасность такой беспринципности, какая была у Касымова и ему подобных. Тогда ОК приказал Саид-Галиеву выехать из Татреспублики. Где же тут, товарищи, снятие Саид-Галиева, как ставленника Москвы. В заключение, товарищи, я еще раз заявляю, что нам в Татреспублике не до басмачества и наше участие в этом вопросе всегда будет определяться высокой по качеству и количеству красной силой» [Шунда ук. С. 58–61].

Дүртенче утырышта, 11 июньдә, Рәүф Сабиров та статистик материалга бай һәм эчтәлекле чыгыш ясый. Ул, ачлык елларындагы авырлыкларга басым ясап, бары тик 1922 елда гына «удалось восстановить культурно-просветительные учреждения до уровня 1920 г… Нам удалось восстановить школы 1-й ступени. Теперь у нас на две деревни одна школа и на 20–25 деревень одно просветительно-культурное учреждение. Достижение, конечно, громадное по сравнению со старым дореволюционным временем… Сейчас мы имеем два педагогических техникума. Один татарский театральный техникум и один сельскохозяйственный техникум. Кроме того, через рабфаки мы сумели провести в высшие учебные заведения 1916 человек татар» [Шунда ук. Б. 137–138]. Аннан соң әйтә: «Работал также татарский театр, создавался восточный музей, госиздатом изданы за два года 156 названий [книг] на татарском языке, татарских газет – 4». Дәвам итеп ул күрсәтә: «В частности, для школ в республике надо было подготовить 15 тысяч школьных работников», – ди. Татар теленең роле буенча әйтә: «Население у нас: татар – 51%, русских – 40%,

Здесь уместно будет сказать, что большой вклад в изучение пословиц, фразеологизмов внес Н. Исанбет, но, к сожалению, его словарь до сих пор не издан в полном объеме (было издано два тома в сокращении). Уникальную работу провел ученый Р. Ягафаров, исследовав в свое время детский фольклор. По сути, Р. Ягафаров поставил на научную основу

детский татарский язык, но, к сожалению, в настоящее время этой сфере функционирования языка не уделяется должного внимания, а труд Р. Ягафарова до сих пор не оценен общественностью по достоинству. Государством выделяются большие финансовые средства на развитие татарского языка, но они распыляются по мелким мероприятиям. Пора серьезно и со всей требовательностью подойти к этому вопросу. В энциклопедии большое место должно быть отведено истории татарского языка, объяснены основные термины лингвистики, приведены данные о языковедах-татаристах, о развитии татарского языка в Белорусии, Румынии, Китае, Польше, Финляндии и др. зарубежных государствах. Известно, что татарский язык изучается и исследуется в некоторых государствах Европы – Румынии, Германии. Стилистическое богатство татарского языка, словарное богатство, пласт арабизмов и фарсизмов демонстрирует проза Гаяза Исхаки, Мажида Гафури, Амирхана Еники, Гумера Баширова, Аяза Гилязова, Ибрагима Салахова и др., поэзия Габдуллы Тукая, Шайхзаде Бабича и др., философские произведения Шигабутдина Марджани и Ризаэддина Фахруддина и др. деятелей культуры, религии и политики.

Татарский язык – это яркая жемчужина в ожерелье тюркских языков, занимающий центральное положение среди тюркских языков и, поэтому, охрана и развитие татарского языка – это почетная обязанность, как государственных органов власти Татарстана, так и интеллигенции, а также краеведов, всех, кто не равнодушен к состоянию и развитию родного языка. Татарский язык входит в сотню языков по распространенности в мире [Брук: 1981], это второй язык в Российской Федерации [Татары и Татарстан: 2007. С. 24]. По данным ЮНЕСКО, татарский язык входит в число 14 языков мира, зная который можно говорить со всеми носителями тюркских языков. Богатство татарского языка проявляется в наличие множества синонимов, «и можно одно и тоже понятие описать двадцатью или тридцатью словами» [Татарский путь: 2005. С. 17].

Коль речь заходит о словарях, то существует острая необходимость издания (естественно, это кропотливая работа) татарского топонимического словаря. В создании топонимического (географического) словаря (энциклопедии) также велика роль татарской интеллигенции и, прежде всего, краеведов. По просторам России, Белоруссии, Казахстана, Польши, Литвы, Украины, Молдавии и Румынии, Китая, Афганистана, государств Центральной Азии сохраняются, а где-то произошло переименование татарских населенных пунктов, географических названий (рек, озер, островов, городов, гор), и важно все это зафиксировать, сохранить и довести до потомков. Данный словарь будет востребован историками, географами, филологами и будет воспринят с интересом большинством

народа. Тайны географических названий есть ключ к истории народа. В этом вопросе исключительная роль принадлежит краеведам, которые могут собрать и систематизировать, записать мифы и легенды, версии о происхождении тех или иных населенных пунктов. Конечно, учеными Татарстана проводятся определенные исследования, но, в основном, результаты исследований опубликованы в статьях научных журналов или находятся в архивах, то есть недоступны широким массам (см., например, статью: [Хисамов, Закирова: 2018. С. 65–77]). Следует рассмотреть региональные топонимические и географические словари. Например, только на Урале сотни выявленных географических названий, истоки происхождения которых выводятся из татарского языка: населенные пункты: Кунгур, Кизел, Карагай, Барда (Пермский край), Карабаш (Челябинская обл); р. Ирень, Кондас (Пермский край), Тура (Свердловская, Тюменская области) [Матвеев: 1987]. Общеизвестны происхождение названий городов Курган, Саратов, Астрахань и др. В интерпретации происхождения географических названий присутствуют различные версии, но, к сожалению, среди них нет мнения татарских ученых. Например, касаясь истории Пермского края, многие географические названия авторы местных изданий производят из башкирского языка, хотя исторически Пермский край находился под влиянием Волжской Болгарии, впоследствии – Казанского ханства (торговое, миграционное, хозяйственное освоение), а в советский период миграционные процессы происходили из Татарстана, да и местное население разговаривает на татарском языке.

Однако, следует сказать, что даже в отношении территории Татарстана не проведена классификация и систематизация происхождения географических названий. Здесь уместно будет привести высказывание А. К. Матвеева: «Зеркало нашей истории и нашей жизни – вот что такое топонимия. Именно поэтому «язык земли» интересует многих – языковедов и историков, географов и топографов, краеведов и туристов, и вообще всех, кому дорог родной край» [Матвеев: 1987. С. 3]. До сих пор у нас это является уделом энтузиастов и носит характер эпизодический и случайный.

В заключение следует подчеркнуть, что методологически важно в краеведческой работе обращать внимание на мифы и легенды, версии и предположения местного населения, объяснительные модели происхождения названий родных сел, местностей, гор, озер, рек, домов, дорог. Следует записывать их и фиксировать. Важно не только собрать воспоминания и предания об этом, но и систематизировать и довести до широкой общественности.

## Литература


1. Брук С. И. Население мира. Этно-демографический справочник. М.: Наука, 1981.
2. Гхош А. Основы индийской культуры // Открытие Индии: философские и эстетические воззрения в Индии XX в.: пер. с англ., бенг. и урду. М.: Художественная лит-ра, 1987. (Б-ка индийской литературы).
3. Кликс Ф. Пробуждающееся мышление. У истоков человеческого интеллекта: пер. с нем. М.: Прогресс, 1983.
4. Матвеев А. К. Географические названия Урала: Краткий топонимический словарь. Свердловск: Средне-Уральское кн. изд-во, 1987.
5. Татарский путь: права народа и политкорректность. Казань: Магариф, 2003.
6. Татары и Татарстан в XX–начале XXI веков (этностатистика) / под науч. ред. Д. М. Исхакова. Казань: Институт истории АН РТ, 2007.
7. Хисамов О. Р., Закирова И. Г. Новосибирск өлкәсе татар авыллары // Туган жир. Родной край. № 3. 2018. С. 65–77.

***А. И. Бугарчев, О. В. Степанов***

УДК 737 (470) «9/12»

# АРХЕОЛОГИЧЕСКИЕ И НУМИЗМАТИЧЕСКИЕ НАХОДКИ ИЗ АЛЬКЕЕВСКОГО РАЙОНА РТ*

***Аннотация.*** *В статье описывается археолого-нумизматические комплексы, собранные у с. Нижнее Качеево и в Алькеевском районе. В состав первого комплекса входят одна монетовидная подвеска, датируемая X–XII вв., 11 обломков куфических дирхамов X в. и две монеты с именем Арыг-Буги середины XIII в. Второй комплекс содержит две подвески, шесть анонимных дирхамов 1266–1327 гг., два пореформенных дирхама с именем Узбека и один акче начала XV в. с именем Пулада.*

***Ключевые слова:*** *монетовидная подвеска, дирхам, Арыг-Буга, Менгу-Тимур, Пулад, Нижнее Качеево, Алькеевский район, Татарстан, X–XV вв.*

1. Первый нумизматический комплекс был собран в окрестностях с. Нижнее Качеево Алькеевского района РТ. Он состоит из одной монетовидной подвески, 11 обломанных или обрезанных куфических монет и двух монет середины XIII в. с именем монгольского каана Арыг-Буги (1260–1266).

Рассмотрим монетовидную подвеску (фототаблица 1, № 1). По внешнему виду она соответствует № 40 из статьи 2012 г. [Лебедев, Беговатов, Храмченкова: 2012. С. 165]. Топография находок монетовидных литых подвесок в наиболее полном виде была опубликована в той же статье 2012 г. [Лебедев, Беговатов, Храмченкова: 2012. С. 164, 167–169]. Если брать только территорию Татарстана, то здесь были представлены места находок 23 подвесок. Алькеевский район в данном списке представлен не был. Таким образом, можно говорить о новой точке обнаружения литых подвесок. Что касается веса нашего экземпляра – 3,03 г, то, с учётом обломанных краёв, он вполне мог соответствовать среднему значению 4,6 г, выведенному авторами указанной работы.

Обратимся к куфическим дирхамам. Из 11 экземпляров 9 представляют собой обломки прямоугольной и подквадратной формы (фототаблица 1, №№ 2–7), а две монеты – это обрезанные в кружок дирхамы с примерно одинаковым весом – 0,50 г (край обломан) и 0,56 г. Ни на одной монете не сохранились выпускные сведения, тем не менее, по нашему мнению, все они относятся к X в. и чеканились на монетных дворах Средней Азии.

---

* Работа выполнена при финансовой поддержке МО РФ.



*Фототаблица 1. Куфические монеты X в. из Ниж. Качеево*

Два дирхама с именем монгольского каана Арыг-Буги чеканились в 1260–1266 гг. на монетном дворе Булгар. Они являются самыми младшими по времени чеканки монетами этого небольшого, но очень важного с точки зрения топографии находок, комплекса.

Из археологической литературы известно о Нижнекачеевском (Шибашском) городище, семи селищах и четырёх поселениях [Свод памятников археологии Республики Татарстан: 2007. Т. 3. №№ 940–950]. О нумизматических находках, происходящих с территории Нижнекачеевского археологического комплекса, до сего времени ничего не было известно. На каком из перечисленных памятников был собран представленный комплекс – нам не известно, однако даже такая скромная информация очень важна для дальнейшего изучения истории всего Татарстана и конкретно Алькеевского района.

2. Кроме точного места находки монетовидной подвески и куфических монет, у нас есть сведения о подобных находках просто «на территории Алькеевского района». Разберём их по подробнее.




*Фототаблица 2. Нумизматический комплекс из Алькеевского района*

Две монетовидные подвески расширяют базу данных о находках подобного археологического материала в Алькеевском районе. Выявленный вес – 4,81 г и 4,59 г (фототаблица 2, №№ 1 и 2 соответственно) – соответствует среднему весу монетовидных подвесок 4,6 г [Лебедев, Беговатов, Храмченкова: 2012].

В целом, с учётом экземпляра из Нижнего Качеево, теперь можно говорить о трёх экземплярах монетовидных подвесок, найденных в данном административном районе.

Джучидские монеты, представленные в табл. 2, охватывают по хронологии полтора века – от 1260-х до 1407–1410 гг.

Первым по времени чеканки следует дирхам С/64, который чеканился в Булгарском вилайете в 1266–1272 гг., в начале правления первого золотоордынского хана Менгу-Тимура (фототаблица 2, № 3). Монета № 4

(фототаблица 2), была выпущена в самом начале XIV в., по нашему мнению – в 1300–1320 гг. Следующие монеты (фототаблица 2, с № 5 до № 8) чеканились при хане Узбеке в дореформенный период (реформа денежного обращения в Среднем Поволжье была проведена в 1330 г.) [Бугарчев, Петров: 2018]. Экземпляры №№ 4–8 являются анэпиграфными – их объединяют следующие факторы – отсутствие имени эмитента, название монетного двора, указание даты и в то же время на всех монетах помещена наследная тамга Менгу-Тимура.

Далее следуют два дирхама, чеканенных после реформы 1330 г. – на них помещены все информационные единицы: тамга, эмитент, монетный двор и дата – 733 г.х. (1332–1333).

Последним из этого списка идёт булгарский акче хана Пулада (1407–1410 гг.) (фототаблица 2, № 11). Находки монет XV в. как на территории Алькеевского района, так и на Болгарском городище и его окрестностях, чрезвычайно редки. Это свидетельствует о существовании единой зоны денежного обращения в XIII–XV вв. с синхронными периодами подъёма и спада экономической активности в данном регионе бывшей Волжской Булгарии.

*Приложение*

**Нумизматический комплекс из с. Нижнее Качеево**

*Таблица 1*

| № | Вес, г | Примечание |
|---|---|---|
| 1 | 3,03 | Монетовидная подвеска |
| 2 | 0,94 | Обрывки легенд |
| 3 | 0,38 | Обрывки легенд |
| 4 | 0,38 | Обрывки легенд |
| 5 | 0,41 | Обрывки легенд |
| 6 | 0,36 | Обрывки легенд |
| 7 | 0,49 | Обрывки легенд |
| 8 | 0,50 | Обрывки легенд |
| 9 | 0,56 | Обрывки легенд |
| 10 | 0,44 | Обрывки легенд |
| 11 | 0,23 | Обрывки легенд |
| 12 | 0,21 | Обрывки легенд |
| 13 | 0,62 | Арыг-Буга |

*Номера фототаблицы соответствуют номерам таблицы 1*

## Нумизматический комплекс из Алькеевского района

*(без точного места находки)*

*Таблица 2*

| № | Вес, г | Примечание |
|---|---|---|
| 1 | 4,81 | Монетовидная подвеска |
| 2 | 4,59 | Монетовидная подвеска |
| 3 | Не сохранился | С/64* |
| 4 | Не сохранился | С/128 |
| 5 | Не сохранился | С/173 |
| 6 | Не сохранился | С/179. Фракция |
| 7 | Не сохранился | С/185 |
| 8 | Не сохранился | С/194 |
| 9 | Не сохранился | Узбек, 733 г.х. |
| 10 | Не сохранился | Узбек, 733 г.х. |
| 11 | Не сохранился | Пулад [810–812 гг.х.] |

* Типология булгарских монет XIII–первой трети XIV вв. указана по монографии А.З. Сингатуллиной [2003].

## Литература

1. Бугарчев А.И., Петров П.Н. Монетные клады Булгарского вилайета XIII – первой четверти XIV вв. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2018.
2. Лебедев В.П., Беговатов Е.А., Храмченкова Р.Х. Монетовидные литые подвески Волжской Болгарии // Нумизматика Золотой Орды. Выпуск 2. Казань: Изд-во «ЯЗ», 2012.
3. Сингатуллина А.З. Джучидские монеты поволжских городов XIII в. / А.З. Сингатуллина. Казань: «Заман», 2003.
4. Свод памятников археологии Республики Татарстан. Т. 3 / Отв. ред. А.Г. Ситдиков, Ф.Ш. Хузин. Казань, 2007.

**Фәнни-популяр язмаларда төбәк тарихы**

**Краеведение в научно-популярных публикациях**

*Фәүзия Бәйрәмова*

## СӨЕМБИКӘ ХАНБИКӘНЕҢ ҖИҢҮЕ ҺӘМ ҖИҢЕЛҮЕ

Татар тарихына, милләт хәтеренә Сөембикә ханбикә фаҗигале язмышы белән кереп калган, моңа сәбәпче булып аның Мәскәүгә әсир итеп биреп җибәрелүе тора. Әйе, бу хак, татар тарихында андый фаҗигале хәл, хурлыклы гамәл булган, бәйсез дәүләт ханбикәсе, нәсел дәвамчысы белән бергә, Казан алынганчы ук дошман кулына тапшырылган. Моны хәзер гаепләргә дә, аклау өчен сәбәпләр табарга да була, әмма тарихта инде буласы булган, безгә хәзер гыйбрәт алырга һәм нәтиҗә ясарга гына калган. Сөембикә ханбикәнең җиңелүе – ул милләтнең дә җиңелүе, аның әсир ителүе – ул татар халкының да гасырларга сузылган хурлыклы коллыгының башы...

Югыйсә, Сөембикә ханбикәнең тарихта җиңелүе генә түгел, зур җиңүләре дә булган бит! Аның язмышында әсирлек фаҗигасе генә түгел, Казан өчен ана арыслан кебек сугышкан вакытлары да билгеле! Бу факт тарихта аз яктыртылган, нигәдер, Сөембикә ханбикәнең шәхси фаҗигасе алга чыккан, милләт өчен кылган батырлыклары онытылган. Тарихтан билгеле булганча, Явыз Иван Казанны алырга берничә тапкыр килә, әмма Сафагәрәй хан моңа ирек бирми, ул үлгәч, аның тол калган хатыны ире урынына баса. 1549 елның ноябрендә урыс гаскәре Казан өстенә зур яу белән килә, Казанны чорнап ала, 1550 елның 25 февраленә кадәр канкойгыч сугышлар бара. Бу сугышта урыслар хурлыклы рәвештә җиңеләләр, бик күп кешеләре үлә, исән калганнар качып котылырга мәҗбүр була. Казан өчен, татар дәүләте өчен изге сугыш белән Сөембикә ханбикә идарә итә, һәм урысларның бу сугышта зур җиңелүләрендә аның роле искиткеч зур булган!

Шул вакыйганың тере шаһиты булган Кол-Шәриф хәзрәтләре үзенең «Зафәрнамә-и вилаяте Казан» әсәрендә Казан өчен сугышның ни дәрәҗәдә куркыныч һәм каты булганлыгын язып калдырган. Ул урысларның Сафагәрәй хан үлеменә чиксез шатланып, Казан өстенә ябырылуларын тасвирлый, Явыз Иван турында «*...ул денсез кяфер, тәкәббер,*

*кинәле, ямьле көннәрне бозучы, дөньяга фетнә салучы ике шайтанның берсе иде»*, – дип яза. ***«...имансыз Иван, башта булган бөтен гаскәре, сансыз туплары, төфәңнәре, чама белән сигез йөз меңлек гаскәре белән килеп, Казан шәһәренең әйләнә-тирәсен сарып-чолгап алдылар. Кяферләрнең гаскәре кырмыска һәм саранчалардан да аз түгел иде. Алар, Яҗүҗ һәм Мәҗүҗ нәселеннән булып, Адәм нәселеннән түгелләр иде», ди*** [Кол-Шәриф: 2005. Б. 17].

Әлбәттә, урыс гаскәре монда бик күп күрсәтелгән, әмма аларның иксез-чиксез санда булуын тарихчылар да таныrга мәҗбүр. Моның өстенә урыслар кулындагы утлы корал, алманнар идарә иткән туплар, аларның Казан өстенә көне-төне утлар чәчеп гөрселдәп атып торулары... Казан кирмәне чолганышта, урыс гаскәре инде Болак һәм Черек күл буенда... Һәм Сөембикә ханбикә үзенең гаскәре белән шушы чиргүгә каршы торган, ул халкын дошманга каршы көрәшкә оештыра һәм күтәрә алган. Казанның һәр капкасында татарның батыр угланнары сакта торган, урамнарда ике гаскәр бугазга-бугаз килгән, «*кыскасы, ике гаскәр, тимергә чолганып, бер-берсенә каршы торып, сугыш һәм көрәш белән мәшгуль булдылар*», дип яза бу турыда Кол-Шәриф хәзрәтләре.

Кол-Шәриф Казан өчен бу сугыш «*уналты кичә һәм көндез туктаусыз өзелмичә дәвам итте*», дип яза, ахырда «*рухы төшкән кяфер кире ташланды һәм каһәрләнеп чигенде*», ди. Әлбәттә, сугыш булгач, ике яктан да югалтулар була, әмма Кол-Шәриф язганча, урыс гаскәре тулысынча кырып салына. «***Бәхете кара һәм җиңелгән дошманны казанлылар шулкадәр кырдылар ки, аларның барлык эзләре җир йөзеннән агып китте***», – дип, Кол-Шәриф изге Коръән аятьләрен китерә. – ***Тәңре явыз кавемне соңгы кешесенә кадәр юк итте, Тәңрегә мең шөкер булсын. Каланың ике тарафында кара кяфер үлесе кылыч һәм хәнҗәр ризыгы, кортларга ризык булып ятырлар иде. Аяк басарлык та җир калмады***» [Күрсәтелгән хезмәт. Б. 20].

Урыс тарихында кара канлы тап булган бу сугышка, бигрәк тә Сөембикә ханбикәнең батырлыгына, урыс язучылары да игътибар итә. Әйтик, 1779 елны Мәскәүдә М. М. Херасковның «Россияда» дип аталган тарихи поэмасы басылып чыга, ул тулысы белән Казан-Мәскәү мөнәсәбәтләренә, урыс-татар сугышларына, Явыз Иван һәм Сөембикә ханбикә каршылыгына багышланган. Әлбәттә, поэмада уйдырма да шактый, шул ук вакытта автор Сөембикә ханбикә образын иле, милләте, дине өчен утка да керергә әзер булган батыр хатын итеп сурәтли. М. Херасковның бу әсәрен махсус өйрәнгән татар галиме Фатих Урманче да моңа игътибар иткән: «***Ил куркыныч бер хәлгә калганда, Сөембикә казанлыларга махсус нотык белән мөрәҗәгать итә. Әйтергә кирәк: Сөембикәнең***

***патетик-трагик рухта яңгыраган нотыгы – поэманың иң көчле урыннарыннан***» [Урманче: 2001. Б. 94].

Менә ул Сөембикә ханбикәнең Казан өчен хәлиткеч сугышта үз халкына, яугирләренә мөрәҗәгате, моны урыс авторы аның исеменнән әйттерә, димәк, ул ханбикә сүзенең шулай булганына ышанган:

«***Безнең илаһи ата-бабаларыбыз булган Чыңгыз белән Атилла алдында бөтен дөнья калтырап торадыр иде, – ди ханбикә. – Безне Җиһан скифлар дип белә иде. Җиһандагы барлык халыклар алдында шөһрәт вә дан казанган шушы халыкның варисларымы сез? Кайчандыр тик безнең рөхсәт белән генә тәхеткә утырып, безгә һәрвакыт тугрылык сакларга ант итеп, ясак түләп торган коллар хәзер безгә каршы баш күтәрмәкче булалар. Хәзер инде Казанның көче бетүгә йөз тоткан. Тау ягы безнең ихтыярга буйсынмый. Дошманнар безне үзләренә буйсындырырга тырыша! Кем соң безгә яный, безне куркытмакчы була? Безгә әле күптән түгел генә ясак түләп торган халыклар! Әгәр сез алардан куркасыз икән, барыгыз көтү көтәргә! Онытыгыз данлыклы ата-бабаларыгызны! Онытыгыз ватаныгызны! Яисә уяныгыз, булыгыз скифлар кебек!***» [Күрсәтелгән хезмәт].

Әйе, 1550 елда Сөембикә ханбикә Казанны урысларга бирмәгән, саклап калган. Рус тарихчысы Михаил Худяков та «***Походы 1549 и 1550 годов потерпели полную неудачу, и русское правительство занялось пересмотром своей военной программы***», дип яза. [Худяков: 1991. С. 129]. Ягъни, алга таба руслар Казанда хан алыштыру белән мавыкмыйча, Казан ханлыгын тулысынча яулап алу һәм дәүләт буларак юк итү максатын куялар һәм 1552 елда шуңа ирешәләр дә. Әмма моның өчен башта юлдан ана арыслан кебек ханбикәне – Сөембикәне алып ташларга кирәк була, алар моңа татарларның үз куллары белән ирешәләр. Бу хакта Һ.Атласи менә ничек яза: «***Сөен-бикә Иванның дошманы булдыгы кеби, Иван да Сөен-бикәнең дошманы иде. Сафагәрәй ханның Русия өстенә еш-еш баскынлык итүендә вә шуның илә бәрабәр Русия кул астына кереп бармакта булган Казан ханлыгын ирекле бер ханлык итүендә Сөен-бикәнең бик зур катнашы булганлыгын Иван ачык беләдер иде. Сөен-бикәне ратмаучы Иван гына булмаенча, аны русларның барысы да яратмыйлар иде. Казанлылар Сөен-бикә теләгәнчә эш итсәләр, атасы Йосыф мирза ушандык нугай мирзалары Казан ханлыгына ярдәмдә булынсалар иде, Казанның беренче ханлык булып калачагы вә бинаән галәйһи русларны тетрәтеп торачагы билгеле иде. Ләкин эш Сөен-бикә теләгәнчә булмады***» [Атласи: 2009. Т. 1. Б. 203].

Әйе, эшләр Сөембикә ханбикә теләгәнчә булмый, 1551 елның маенда, Зөя елгасының Иделгә коя торган тамагында урысларның хәрби

кәлгәсе – Свияжски үсеп чыккач, Казанның хәле кискен рәвештә начарая. Башкала су юлыннан киселә, сәүдә туктала, шәһәргә ризык керми башлый, Тау ягы тулысынча дошман кулында кала, халык Казан ягында калган болынлыкларына, көтүлекләренә чыга алмый башлый. Сөембикә ханбикә урыслар кереп оялаган Зөя-Свижски кәлгәсенең Казан өчен ни дәрәҗәдә куркыныч булуын бөтен йөрәге белән тоя, сарай халкына да шуны аңлата, гаскәрен Зөягә сугыш белән барырга өндәп карый, әмма татар түрәләре бу адымга барырга куркалар. «***Казанлылар, Сөен-бикәнең сүзен тыңламаенча, руслар илә орыштан баш тарталар***, – дип яза Һади Атласи. – «***Без рус гаскәренә каршы тора алмыйбыз», дип, сугышка бармаячакларын белдерәләр***» [Күрсәтелгән хезмәт. Б. 208].

Ул гына да түгел, Казан түрәләре, Сөембикә ханбикәгә әйтмичә генә, аның артында урыслар белән сөйләшүләр алып бара башлыйлар, ханбикәне һәм аның улын Мәскәүгә әсир итеп биреп җибәрергә җыеналар. 1551 елның 6 июлендә Свияжскида урыс-казан килешүе төзелә, аңа Мәскәү дәүләте ягыннан Касыйм ханы Шаһгали кул куя, Казан ханлыгы ягыннан – мулла Кол-Шәриф һәм бәк Бибарс Растов имзалыйлар. Шушында Сөембикә ханбикәнең һәм улы Үтәмеш-Гәрәйнең дә язмышы хәл ителә, аларны Мәскәүгә биреп җибәрергә килешәләр. 1551 елның августында Мәскәүдә тагы бер килешү төзелә, монысында инде ике як та Казан ханы итеп Шаһгалине танырга, ә Сөембикә ханбикә белән Үтәмеш-Гәрәйне Мәскәү хөкүмәтенә тапшырырга, имзаларын куялар. Шулай итеп, Казан ханлыгы икегә бүленә, Тау ягы урыс хөкүмәте карамагына күчә, Казан ханлыгы тулысынча басып алынырга һәм юк ителергә бер ел вакыт кала...

11 август көнне Свияжскидан Казанга Сөембикә ханбикә белән улын алып китәргә көймә килә, Сөембикә шулчагында гына үзенең әсирлеккә төшүен аңлый, әмма инде соң була. Сарай халкы, татар түрәләре аны үз куллары белән урысларга коллыкка биреп җибәрәләр, моның өчен аклану да табарга тырышалар, имеш, шулай итеп, дәүләтне саклап калалар, әмма нәтиҗәдә дәүләтне генә түгел, хәтта үзләрен дә саклап кала алмыйлар. Бер елдан соң барысына да Сөембикә язмышы килә, барысын да коллык һәм үлем көтә, милләт үз ханбикәсе артыннан гасырларга сузылган фаҗигале тарихына аяк баса... Сөембикә ханбикә, су юлы буйлап коллыкка китеп барганда, Казаны өстенә карап, соңгы бәхилләшү сүзләрен әйтә...

Ханбикә Казанның көчле, мәгъруր, бәхетле чакларын искә төшерә, кат-кат әрнеп, «*кайда хәзер ул бәйрәмнәр, ул шатлыклар, кайда синдәге угланнарың, мирзаларың, матур кызларың*», – дип сорый да, – «*барысы да югалды, бетте*», – дип нәтиҗә чыгара. – «*Хәзер синең ул урыныңда халыкның ыңгырашуы, уфылдавы, еглавы, үксүе генә калды, хәзерендә*

*анда синең кешеләреңнең каннары агадыр, ачы яшьләре коеладыр, рус кылычы аларны бетергәнчегә чаклы кипмидер»*, – дип өзгәләнә. Сөембикә бу хәлләр өчен Шаһгалине һәм казанлыларны гаепли, үзенә килгән кайгылар алар башына да килсен, дип тели. Әлбәттә, тормышта бәлки алай ук та булмагандыр, мөселман хатыны кеше каргап утырмас, әмма урыс елъязмалары артыннан Атласи да шуларны кабатлаган. Сөембикә Казанда кечкенә генә җирдә яшәргә дә риза булуын әйтә, атасы йортына, нугай далаларына кайтып китәсе килүен дә сөйли. Әмма аның иң көчле теләге – «*Мәскәүгә баруга, Рус йортында мыскылланып, көлке ителеп яшәүгә караганда, ире янында булу артыграк, ачы үлемне тату яхшырак булыр иде*», ягъни, Сөембикә әсир булуга караганда, Казанында үлүне артыграк күрә.

«***Кызганыч син, канлы, кайгылы шәһәр!*** – ди ул, Казан белән бәхилләшеп. – ***Синең башыңнан таҗың төште. Син хәзерендә тол хатын кебек булып калдың. Син хуҗа түгел инде – кол булдың. Синең атаклылыгың барысы да китте. Син, башсыз арыслан кебек, хәлсез калып беттең. Һәрбер падишаһлык гакыллы падишаһ илә идарә ителә, көчле гаскәр илә саклана. Шулар булмагач, кем синең падишаһлыгыңны алмас? Синең көчле ханың үлде, башлыкларың көчсезләнде, кешеләрең боекты, башка падишаһлыклар сине якламады, аз булса да сиңа ярдәм бирмәде, шуңа күрә син җиңелдең***» [Атласи: 2005. Т. I. Б. 219].

Зөя-Свияжскида Сөембикә ханбикә бер кич куна, аны әсирлектән килеп коткаручы булмый, киресенчә, урыс яугирләре утлы корал белән саклыйлар. 12 август көнне көймәләр кәрваны Идел буйлап озын юлга кузгала, далаларда тәгәрәп үскән татар-нугай ханбикәсен билгесез язмышы каршына алып китә... Бу вакытта аңа 35 яшьләр тирәсе була. Аның өчен Казан капкалары ябыла, тәкъдирнең кара капкалары ачыла... Сөембикә ханбикәнең алдагы язмышы билгесез, улын анасыннан аерып алып, чукындыралар, үзен дә монастырьга ябып куйган булулары мөмкин, ул вакытта тәртип шундый булган. Кайда, ничек үлгәнлеге дә билгесез, кабере дә юк. Ул бары тик халык күңелендә генә саклана. Инде бу дөньяда күргән газаплары өчен аңа ахирәт көнендә җәннәт капкалары да ачылсын иде.

Сөембикә ханбикәнең үзе идарә иткән Казан ханлыгында соңгы аяк баскан урыны – Зөя-Свияжски каласы. Туган илендә соңгы намазлары да шунда укылгандыр. Димәк, аның милләткә яңадан кайтуы да шул Зөя каласыннан башланырга тиеш, Казан үз ханбикәсе өчен капкаларын япкан икән, ул биредә үз урынын табарга тиеш. Сөембикә ханбикә исемендәге мәчет тә нәкъ менә Свияжскида булырга тиеш бит! Татарның мөселманлык һәм дәүләтчелек билгесе булып, Свияжскиның уртасында мәгърур Сөембикә мәчете басып торса иде! Зөя каласы урынында элек-электән,

әле болгар чорларыннан ук мөселманнар яшәгәнлеге билгеле, археологлар анда Алтын Урда чоры мәчет нигезен дә таптылар.

Шулай ук Казанның үзәк урамы – Бауманны да Сөембикә ханбикә исеменә алыштырырга күптән вакыт. Моннан ике ел элек, 2017 елның 12 июнендә мин бу хакта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановка мөрәҗәгать тә юлладым, анда түбәндәге сүзләр бар иде:

***«Хөрмәтле Рөстәм әфәнде!***

Бу көннәрдә Казакъстан башкаласы Астана шәһәрендәге бер урамга Сөембикә ханбикә исеме бирелү хәбәрен татар җәмәгатьчелеге сөенеп кабул итте, моның өчен тугандаш казакъ халкына һәм Казакъстан җитәкчеләренә зур рәхмәтләребезне әйтәбез. Бу тантанада сезнең дә катнашуыгыз һәм Сөембикә ханбикә турында зурлап сөйләвегез дә күңелләргә хуш килде. Сез анда «Открытие в Астане улицы имени царицы Сююмбике – важное событие в истории наших братских народов. Хочу поблагодарить за этот замечательный подарок Президента Республики Казахстан Нурсултана Назарбаева и акима города Астаны Асета Исекешева. Образ царицы Сююмбике особенно дорог для нас. В нем отражается душа татарского народа. В то же время Сююмбике почитается и во всем тюркском мире. Мы рады, что именно она является объединяющим символом Татарстана и Казахстана», – дип чыгыш ясадыгыз.

Әйе, сез дөрес әйттегез – Сөембикә ханбикәне татар халкы гасырлар үткәч тә күңелендә саклый, аның турында җырлар һәм бәетләр, дастаннар иҗат ителгән, милли зыялыларыбыз үзләренең әсәрләрендә соңгы ханбикәнең якты һәм сагышлы образын тудырганнар. Әйе, Сөембикә ханбикәнең язмышы фаҗигале, әмма шул ук вакытта ул татар тарихында тирән эз калдырган шәхес. 17 яшьләрендә нугай далаларыннан Казанга килен булып төшкән Сөембикә биредә үзенең иң бөек һәм тетрәндергеч чорын кичерә, милләтнең яраткан ханбикәсенә әйләнә.

Сөембикә ханбикәнең сөргеннәрдә газап чигүендә һәм аннан соң вафат булуында, хәтта кабере дә билгесез булуында аны Казан алынмас борын дошман кулына биреп җибәргән татарлар үзләре дә гаепле. Һәм безгә бу тарихи хатаны төзәтергә, Сөембикә ханбикәнең исемен дәүләт дәрәҗәсендә яңадан халыкка кайтарыр вакыт җитте.

Революциягә хәтле бу үзәк урам «Проломная» дип аталган, чөнки урыс гаскәре шуннан җимереп Казан кирмәненә бәреп кергән. Революциядән соң бу урамга бомбист-террорист Бауман исемен биргәннәр, шул хурлыклы исем бүген дә саклана. Безнең милләт шушы җимерүчеләр исеменә генә лаекмыни соң инде?! Нигә ханнарыбыз һәм ханбикәләрнең исемнәрен үзәк урамнарга куймыйбыз, бу бит татар тарихын да мәңгеләштерү булыр иде! Казан Кремлендә Кол-Шәриф мәчете төзелү,

Сөембикә манарасы янында Казан ханнарының җәсәдләрен зурлап җиргә тапшыру шушы зур эшләрнең башы булды. Инде Сөембикә ханбикә шәхесенә карата да шушындый зур игътибар һәм хөрмәт булсын иде, ул моңа лаек бит! Казакъ дуслар безгә моның яхшы үрнәген күрсәттеләр, нугайлар да бездән милләттәшләре Сөембикәнең исемен мәңгеләштерүне көтә. Аны догалар һәм яхшы гамәлләр белән искә алсак, хаксызга рәнҗетелгән Сөембикә ханбикәнең дә рухы шат булыр иде».

Минем татарча мөрәҗәгатемә бер айдан русча тискәре җавап килде, аңа Казан шәһәре башлыгы урынбасары Любовь Андреева кул куйган иде. Ул Бауман исемен Сөембикәгә үзгәртүгә шул урамда яшәүчеләр каршы булачак, ди, киләчәктә берәр яңа урамга яки шәһәр бакчасына аның исеме бирелүе мөмкин икәнлеген әйтә. Хат ахырында Л.Н.Андреева, инде үз исеменнән: «В связи с вышеизложенным, переименование улицы Баумана в улицу царицы Сююмбике считаю нецелесообразным», – дип яза.

Инде форсаттан файдаланып, Сөембикә-Ханбикәнең тууына 500 ел тулу уңаеннан, мин бу мәсьәләне тагы күтәрәм. Шушы олуг юбилей датасына багышланган фәнни конференциянең (Казанда, 2019 елның декабрь аенда булды) резолюциясенә мондый тәкъдим керттем:

***Сөембикә-ханбикәнең исемен дәүләт дәрәҗәсендә яңадан халыкка кайтарыр вакыт җитте. Моның өчен түбәндәгеләрне эшләргә:***

***Казанның хәзерге Бауман урамын Сөембикә ханбикә урамы, дип үзгәртергә;***

***Казанда һәм Зөя-Свияжскида Сөембикә ханбикә исемендәге Хәтер мәчет комплексы төзергә;***

***Соңгы вакытларда матбугатта һәм мәдәниаттә Сөембикә ханбикә образын бозып күрсәтүләргә кискен рәвештә каршы төшәргә;***

***Сөембикә ханбикәнең якты образын, милли азатлык көрәшчесе, татарның дәүләтчелек символы буларак, матбугатта, мәдәнияттә пропагандаларга, мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында яшь буынга татар тарихын аның язмышы аша аңлатырга***.

## Әдәбият


1. Атласи Һади. Сайланма әсәрләр. 1 том. Казан, 2009.
2. Кол Шәриф һәм аның заманы. Кул Шариф и его время. Казан, 2005.
3. Урманче Фатих. М.М.Херасковның «Россияда» поэмасында – Сөембикә // Сөембикә ханбикә. Казан, 2001.
4. Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. Москва, 1991.

***Фарит Яхин***

# О СИБИРСКОМ ТАТАРСКОМ ПОЭТЕ XIV ВЕКА ШЕЙХЕ ИКАНИ

*В истории литературы о творчестве шейха Икани, одного из дворцовых поэтов татарских ханов Сибирского ханства, до последнего времени ничего не было известно. Лишь после 2000 г., после издания в Казани средневековой поэтической хрестоматии «Бакырган китабы» («Книги яссавидов»), появилась возможность исследовать и оценить его стихотворения [Бакырган китабы: 2000. 108–118 бб.]. Но данная работа литературоведами не была проведена. После изучения исторических материалов о шейхах Сибири, определения духовных чаяний шейха открылась возможность более широко охарактеризовать поэзию данного суфия в литературоведческом плане с использованием принципов герменевтики и текстологии.*

Шейх Икани жил в столице Сибирского ханства Искере, которая находилась на берегу на месте впадения реки Сибирки в Иртыш, и был похоронен там же. Он прибыл сюда из Средней Азии в составе 366 шейхов, направленных в Сибирскую землю в 1394 г., по преданию, главой суфиев, с целью распространения мусульманства среди местного населения [Ислам в истории и культуре Тюменского края: 2004. С. 40]. Главой суфиев, как указывается в самом предании, был шейх Бахаутдин Накшбанди.

На самом-то деле Бахаутдин Накшбанди жил в 1318–1389 гг. вблизи Бухары и в самом городе. Интерес к суфизму ему привил его дед, который придерживался учения знаменитого Юсуфа Хамадани (умер в 1140 г.), учеником и продолжателем которого был туркестанский мистик Ахмед Яссави (1091–1166), создатель суфийского братства «Бакыргани» (Яссавийа). Суфийская школа Хамадани называлась «ходжаган», а по-тюркски – «худжалар». Представителей этой школы сибирские татары называли «яхшылар», в значении «святые», «безгрешные». «Беспрекословный духовный авторитет Баха ад-Дина поставил его во главе школы Ходжаган, которая при нем приняла организационные формы, присущие суфийским братствам, и это братство было названо его именем Накшбандийа, хотя он после создателей этой школы ал-Хамадани и ал-Гиджувани был пятым ее руководителем» [Яковлев: 2002. С. 453]. Спустя 5 лет после смерти своего учителя, его мюриды, как святые воины ислама, прибыли в Сибирь. В свитках, в которых приводится список самых знаменитых из этих шейхов, географическим местом, куда они пришли, указывается река Абу-Джура. К сожалению, поиски реки с таким названием по старинным историческим и географическим источникам, по словарям и справочни-

кам не дали положительного ответа. Н.Ф. Катанов (1862–1922), исследуя один из свитков о шейхах, пришел к мнению, что «Абу-Джура» есть арабское название р. Иртыш [Катанов: 2004. С. 137–144. С. 137]. Данное мнение учеными было принято без критического осмысления.

На исторической местности городища Искер сегодня имеется действующее православное кладбище, которое с каждым годом расширяется в сторону археологического памятника. По утверждению старожилов, мусульманские святые были похоронены западнее данной местности, но эти могилы остались под водами Иртыша. Современные обелиски с именами святых, среди которых имеется отдельный обелиск шейху Икани, установлены в искерской земле общественными активистами и не отличаются научной точностью. Деятельность общественников достойна благодарности, ибо обелиски имеют туристическую привлекательность и служат проявлению чувства уважения к истории сибирских татар.

Содержание свитков о шейхах сибирских татар отличается от содержания свитков, разработанных духовным генеалогическим братством Накшбандийа, от «силсиля», «в соответствии с которой духовная преемственность в братстве восходит к Пророку духовно через первого халифа Абу-Бакра и физически – через четвертого праведного халифа Али, родственника Мухаммада» [Яковлев: 2002. С. 455]. Такие «золотые цепи» [Там же] нашли распространение у казанских татар и легли в основу генеалогического древа-шаджере. Отличие свитков о шейхах сибирских татар от «шаджере» и «силсиля» говорит об их уникальности. Данные свитки, возможно, были первым опытом составления духовного генеалогического древа братства Накшбандийа. Естественно, с годами они дополнялись новыми данными и личностями. Приведенный в них список шейхов, указание мест их захоронений имеют и культовую, и историческую значимость. В 1544 г. над могилой Бахаутдина Накшбанди был построен мавзолей, который «стал популярным местом массового поклонения, и, по преданию, трехкратное посещение могилы Баха ад-Дина заменяло паломничество в Мекку и Медину» [Там же]. В Сибири могилы святых называются «астана». Сибирские татары это слово переводят как «святое место», «могила святого». На них сооружают деревянные срубы со столбом в юго-восточном углу. По личной инициативе отдельных людей время от времени старые срубы заменяют на новые. Посещение могилы святого лишний раз считается дурным тоном.

В свитке шейхов место жизни и захоронения шейха Икани указаны конкретно. По данным нашего критического анализа текстов свитков, по результатам научных поисков, археографических командировок и экспедиций, река под названием «Абу-Джура» появилась в свитках из-за ошибки переписчиков. Один из притоков Иртыша называется Инжурка, название

которого и написали «Абу-Джура». Если провести графические и орфоэпические анализы текста, то становится ясно, что в арабо-графическом тюркском письме слово «инҗура» (татарский вариант произношения Инжурки) пишется как «аингжура», что означает «вниз идущая» река, то есть «быстротечная». В современном татарском языке слово звучит как «иңә җөри», то есть переводится на русский так же, как «вниз идущая». Таким образом, становится ясно, что ошибка переписчика породила ошибку чтения, а после и запутанные представления об Абу-Джуре.

Река Инжурка действительно быстротечная. Раньше по ней сплавляли лес на Иртыш. К югу, на месте слияния с Иртышом, находятся могилы святых. Культовым считается посещение могилы Хаким-ата. Место захоронения Икани такого значения не имеет.

Имя поэта Икани ученые прочитали по свитку по-разному. Одни – как «Айкани» [Ислам в истории и культуре Тюменского края: 2004. С. 40], а другие – как «Айказани» (например, знаменитый тюрколог Н. Ф. Катанов [Катанов: 2004. С. 140]). Понятно, что такая вариативность появилась из-за ошибки прочтения арабо-графического текста.

Другой достоверной информации, кроме конкретных упоминаний в свитках и «шаджаре», которые в науке известны в четырех списках [Бустанов: 2009. С. 159], об Икани нет. Еще не обнаружены биографические данные о нем. Ни в списках великих суфиев-шейхов, ни в энциклопедических словарях знаменитых ученых прошлых веков Востока, об Икани не упоминается. А его 18 стихотворений, которые вошли в хрестоматию произведений суфийских поэтов XII–XVIII вв., называющуюся «*Бакырган китабы*» («Книга яссавидов»), говорят о том, что поэт был одним из признанных творческих личностей своего времени. В его стихотворениях очень редки автобиографические данные, но при ознакомлении с ними появляется возможность понять думы и чаяния не только самого автора, но и тех 366 шейхов, которые были «вооружены» единым желанием и стремлением «покорить Сибирь».

Имя поэта шейха Икани переводится как «Верный шейх». Его можно представить как псевдоним. Но это было бы ошибкой, хотя слово «Икани» наводит на мысль, что оно образовано по такой же формуле, как Руми, Навои и т.д., то есть по месту рождения или жизни, или характеру поэта. В таком случае он должен был назвать и свое имя, ибо мы знаем Руми как Джалаладдина, Навои как Алишера. У Икани слово «шейх» относится к его общественному положению и не является именем.

В связи с тем, что произведения Икани включены в хрестоматию поэтов «джахристов», то есть «яссавидов», мы можем ошибочно назвать его последователем учений туркестанского поэта-мистика Ахмеда Яссави (1092–1166). Но необходимо отметить, что Ахмед Яссави был учеником

Ю. Хамадани и относился к суфийской школе Ходжаган. К этой школе относился и Бахаутдин Накшбанди [Яковлев: 2002. С. 453]. Он был таким же суннитом, как и Яссави. Среди татарского населения вплоть до советского времени популярным было суфийское братство Накшбандийа. Частое издание книг яссавидов говорит о том, что они пользовались спросом у населения. Б.Накшбанди писал на персидском языке. А. Яссави был тюркистом. Их идеи и идеалы не противоречили между собой. Это и дало возможность развиваться и распространяться принципам братства Накшбандийа среди татарского народа, представители которого, хорошо зная персидский язык, все же предпочитали писать стихи на тюркском.

В «Книгу яссавидов» включены 143 лирико-философских и лиро-эпических произведений 20 поэтов из Средней Азии, Кавказа, а также татарских. Среди них 18 стихотворений принадлежат перу шейха Икани. Они почти все подчинены принципам, разработанным самим шейхом Бахаутдином для братства Накшбандийа.

Основной принцип – «*зикр*», то есть «поминовение». Оно обращено к Всевышнему, является основой медитации и бытия суфия. Поэт размышляет о возможном достижении сердцем до Аллаха, которого, как и все суфии, называет словом «*Хак*» (Истина). Начинает утверждать, что достижение сердцем возможно только посредством чистой любви.

Другое стихотворение Икани в чувственно-философской форме изображает состояние души человека, ищущего Всевышнего. Поэт дает понять, что только с чистым и светлым сердцем можно найти Бога, который не может быть вне истины. В душе праведного человека и находится его жилище, «*бэйтел-Хак*».

Его другое стихотворение, посвященно необходимости постоянно помнить о существовании Всевышнего, ибо человеческая память коротка, только чистая любовь позволяет ощущать вечность. И потому Икани, противопоставляя душу памяти, ставит вечность выше сиюминутного, говорит о необходимости помнить Всевышнего душой, выдвигая идею о материальности ума и памяти.

Всевышний не может пребывать во временных «жилищах», то есть в памяти, место для «Абсолютной истины» – в душе человека, ибо только душа является вечной и бессмертной. Таким образом, Икани утверждает, что Всевышнего необходимо помнить не умом, а душой. И потому, в другом стихотворении Икани начинает призывать к пробуждению ото сна. Для него материальный мир с его возможностями и является местом сна, и только духовный мир есть истинное богатство.

В стихотворении «*Көлли гөлзари*» («Все цветущие сады») Икани пишет, что как осень приходит в цветущие сады, так и к человеку приходит

смерть. Не денег своих надо считать, а вести счет грехам своим, утверждает он. «Счет грехов» поэт понимает как раскаяние в совершенных грехах.

Далее в данном стихотворении Икани упоминает воду Туркестана: «*Бу Төркестан суыны эчсә канә*» («Смогу ли досыта напиться водой Туркестана») [Бакырган китабы: 2000. С. 117]. Из этих строк становится ясно, что он был родом из Туркестана.

Поэзия шейха Икани полна мистических представлений, стремлений к отчуждению от мира. Его лирический герой находится в постоянном духовном поиске. Он совершает внутреннюю борьбу против Зла и Невежества, ибо понимает, что любовь к Всевышнему есть стремление к Добру, Просвещению. Как представитель суфийского братства Накшбандийа, Икани хвалит трудолюбие, честность и порядочность. В его воззрениях праведным человеком может быть только суфий, в душу которого поселился Всевышний.

Читая стихотворения шейха Икани, можно понять, чем жили сибирские татары в средние века. Он прибыл к ним в составе религиозно настроенных шейхов для внедрения суфийских представлений братства Накшбандия. Его поэтический мир, освященный идеалами Добра, Света и Просвещения, а также стремление к справедливости, оказались привлекательными и ценными для того времени. Икани стал приближенным хана, и народ знал его как чистого душой святого человека. Написанные им стихотворения не забылись, а продолжали служить новым поколениям в течение столетий.

## Литература

1. Бакырган китабы: XII–XVIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре / Текстны әзерләүче, искәрмәләр язучы Фәрит Яхин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.
2. Бустанов А. К. Ранняя версия сочинений об исламизации Сибири // «Сулеймановские чтения»: Материалы Всероссийской научно-практической конференции с международным участием. Тобольск: ТГПИ, 2009.
3. Ислам в истории и культуре Тюменского края (в документах и материалах) / Автор-составитель И. Б. Гарифуллин / Ред. А. П. Ярков. Тюмень: ИПС «Экспресс», 2004.
4. Катанов Н. Ф. О религиозных войнах учеников шейха Багаутдина против инородцев Западной Сибири // Тобольский хронограф. Сборник. Вып. 4. Екатеринбург: Уральский рабочий, 2004.
5. Яковлев Л. Шейх Баха ад-Дин Мухаммад ибн Бурхан ад-Дин Мухаммад ал Бухари Накшбанд // Суфии: Собрание притч и афоризмов. М.: Эксмо, 2002. (Серия «Антология мысли».)

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

## КУРГАН ТАТАРЛАРЫНДА САКЛАНГАН ДАСТАННАР*

Бүгенге көндә Урал арты татарлары – бу якта яшәүче халыклар арасында саны буенча иң зур күпчелекне тәшкил итүчеләрдән. Бөтен Россия буйлап таралган татарларның биредә дә компактлы яшәүләре табигый. Урал арты татарлар өчен берничә буын элегрәк күченеп килгән җир генә түгел, бу тирәләр – борынгы скиф-һун-төрки-татар җирләре, татарларның тарихи ватаны. 2010-нчы елгы халык санын исәпкә алу нәтиҗәләре буенча, Курган өлкәсендә яшәүче милләттәшләребезнең саны – 17 мең, ә башкортларныкы 12 меңне тәшкил итә, бу исә өлкәдә яшәүче 900 меңнән артык халыкның 3,3% дигән сүз.

Бүгенге Курган өлкәсе татарлары турында тарихта иң беренче мәгълүматлар XI гасырга ук барып тоташа. Ул чордагы фарсы галиме Әл-Гардизи Урал арты территориясенең, шул исәптән бүгенге Курган өлкәсенә карый торган җирләрнең, урта гасыр төрки дәүләтләренең берсе булган Кимак каһанлыгына керүе хакында язып калдырган. Кимак каһанлыгы составына җиде үзара якын кардәш кабилә кергән, шулар арасында татар һәм кыпчак кабиләләре дә бар. Татарлар каһанлыкта идарә итүче йорт исәбендә торганнар [Исхаков, Измайлов: 2000. С. 77], аның көнбатышын, ягъни хәзерге Чиләбе, Курган өлкәсе урнашкан территорияне биләгәннәр. XIV йөз тарихчысы Ибн-Халдун шулай ук кыпчаклар арасында татарларның аерым этногенетик тармак тәшкил итүләре турында яза. Бүгенге көндә Санкт-Петербургта Эрмитаж кунсткамерасында саклана торган матди кыйммәтләр – скиф хәзинәләренең Курган якларыннан, Тубыл, Исәт елгалары буена урнашкан татар авылларында табылган булуын да исәпкә алсак, бу якларда төркиләрнең тамырлары тагын да борынгырак чорларга барып тоташканлыгы ачыклана.

Этнослар ныгып формалашу чорында Курган өлкәсе җирләренең данлы һәм шанлы Алтын Урда территориясе булганлыгы билгеле факт. Бу чорда биредә батырлар дан алган, нигезләр корылган, төрки нәсел дәвам иткән. Алтын Урда чорында хәзер Курган өлкәсенә керә торган җирләр аша кәрван сәүдә юллары үткән, бу исә мондагы татар һәм башкортларның әле урта гасырларда ук сәүдә-икътисад мөнәсәбәтләрендә актив катнашкан булуы турында сөйли. Бүгенге көндә Курган

* «Исследование выполнено при финансовой поддержке РФФИ и Республики Башкортостан в рамках научного проекта № 18-412-020006 р_а «Межрегиональные контакты и диалог культур в материалах фольклорно-археографических экспедиций в регионах РФ».

өлкәсендә Алтын Урда чоры кайтавазы булып төрки шәһәрлекләр, борынгы төрбәләрнең, курганнарның табылып торуы, боларның төзелеш архитектурасы, күлләр, урманнар белән әйләндереп алынган басуларда XIII гасырларда ук калкып чыккан нык һәм биек каланчаларны төзүдә кулланылган материаллар – болар бар да элгәрләребез мәдәнияте эзләре, төркиләр тормышының урта гасырлар катламына карый торган ядкарьләре.

Алтын Урда таркалгач, бу җирләрнең Себер ханлыгына керүе мәгълүм [Долгих: 1960. С. 62]. Курган өлкәсенең эчкен татарлары яши торган Шадрин һәм Шатровский районнарында археологлар тарафыннан Алтын Урда һәм Себер ханлыклары чорына караган тарихи һәм мәдәният объектлары табылып тора.

Регионны Рус дәүләте тарафыннан үзләштерү чорында – XVI йөз ахыры–XVII йөз башында, биредә чыгышлары Себер ханлыгыннан булган җирле төрки кабиләләрнең яшәве һәм аларның татар ханлыклары сәяси элитасы белән тыгыз бәйләнештә булулары мәгълүм. Курган өлкәсе туфрагының Казан ханлыгы яулап алынганнан соң ханлыктан көнчыгышка таба качып китәргә мәҗбүр булган кан кардәшләребезне сыендырган урын икәнлеген дә беләбез. Себер ханлыгы алынганнан соң, XVII йөздә, бу территорияләр рус дәүләте колонизацияләгән биләмәне тәшкил итә. Соңгырак чорда – XIX–XX йөзләрдә – хәзерге Курган өлкәсе территориясенә Оренбург, Уфа губерналарыннан татар һәм башкорт мигрантлары агыла, алар да биредә төпләнеп гомер итәргә дип, Урал арты санала торган әлеге җирләрдә утырып кала.

Шул рәвешчә, биредә татар-башкортларның тупланып яшәүләре мең еллык тарихны тәшкил итә. Курган өлкәсе – кимендә унлап гасырны эченә алган төрки тарихлы җирләр. Сакланып калган матди һәм матди булмаган мәдәният үрнәкләре арасында монда яшәүче җирле халыкның бик борынгы төрки тамырларын раслый торган кыйммәтләр, чыннан да, күп.

Бүгенге көндә Курган өлкәсенә кергән районнарда яшәүче татар һәм башкорт телле төрки халык тарихи яктан төрле этник компонентлар кушылмасыннан гыйбарәт. Биредә борын-борыннан шушында көн күргән җирле татарлар һәм башкортлар, XVI гасырлардан алып төрле чорларда бирегә күпләп агылган Казан арты кешеләре, Идел буеннан яисә башкорт далаларыннан күченеп килгән мөселманнар һәм башкалар бүгенге көндә халкыбызның гаять үзенчәлекле бер катламын тәшкил итеп яшиләр, борын-борыннан татар һәм башкортлар үзара никах бәйләнешләре булдырып, кыз алып, кыз бирешәләр. Шуңа күрә биредә яшәүче татар һәм башкортларның мәдәнияте, аерым алганда, фолькло-

ры бер-берсе белән нык керешкән, гаять кызыклы, бай һәм төрле яклап өйрәнүне сорый.

Административ территория буларак, Курган өлкәсенең 1943-нче елда оешканлыгы мәгълүм. Тарихтан билгеле булганча, 1917-нче елгы инкыйлабка кадәр Тобол губернасының Курган, Ишим, Ялутор өязләре, Пермь губернасының Шадрин, Камышлы өязләре, Оренбург губернасының Чиләбе өязләре хәзерге Курган өлкәсе террриториясен тәшкил иткән. Совет чорында бүгенге Курган өлкәсе Төмән, Чиләбе губерналарының, соңрак Урал өлкәсе Курган, Шадрин, өлешчә Чиләбе, Ишим округларының, шуннан соң Чиләбе өлкәсенең состав өлеше булып тора. Ә 1943-нче елның февралендә СССР Югары Советы Президиумы Указы белән составына 32 район кергән Курган өлкәсе оеша.

Бу як кешеләре фольклорны теркәп һәм теркәтеп калдыруга үзләреннән өлеш керткәннәр. XX йөздән башлап татарларда яисә башкортларда халык иҗатының кайсы гына жанры буенча нинди генә җыентык чыкса да, аларда Урал артында гомер итүче халык вәкилләреннән язып алынган яисә аларда саклана торган язмалардан күчерелгән фольклор әсәрләрен очратырга мөмкин.

Мәсәлән, 1978–1979-нчы елларда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре бу якларда фольклор экспедициясендә булып, шактый зур багаж белән кайтканнар. Төгәлрәк әйтсәк, 1978-нче елның июлендә Котдус Хөснуллин (җитәкче), Рәшит Ягъфәров, Асия Садыйкова, Камәрия Ямалетдиновалардан торган төркем, 1979-нчы елның июнендә Илбарис Надиров (җитәкче), Ленар Җамалетдинов, Асия Садыйкова, Сәлим Гыйләҗетдинов, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Рәшит Ягъфәровтан торган алты кешелек төркем, 1983-нче елда Ленар Җамалетдинов (җитәкче), Айсылу Садекова, Рәшит Ягъфәровлар, Урал арты татарлары фольклорын туплау максаты белән, бу якларга экспедициягә чыккан. Ул чорда Институтта экспедицияләр аерым бер юнәлеш буенча үтә торган булган. Галимнәр, татар авылларында йөреп, халык белән әңгәмә корганнар. XXI йөздә дә бу өлкә белән кызыксыну кимемәде: 2010-нчы елда Институттан бер төркем галим Курган өлкәсендә комплекслы экспедициядә булып кайтты. Шулай ук Казан федераль университеты профессоры Фәрит Йосыпов төрле елларда Курган, Чиләбе өлкәләренә оештырылган фәнни экспедицияләрдә катнаша килә. Биредә шактый берәмлектә халык җырлары, бәетләр, табышмаклар, риваять, мифологик хикәятләр, әкиятләр, дастан вариантлары җыелганлыгы турында мәгълүмат бар. Шунысы куанычлы: Курган һәм аңа якын төбәкләрдә тупланган фольклор материалларының күбесе бүгенге

көнгәчә чыгып килгән җыентыкларда, академик томнарда урын алган. Кулъязмалар Казан фәнни үзәкләре архивында, шул исәптән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә [ТРФА Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИның Язма һәм музыкаль мирас үзәге] яхшы хәлдә саклана.

Урал арты татарлары, шул исәптән Курган өлкәсендә яшәүче милләттәшләребез иҗаты, галимнәр игътибарын эпик фольклор, аерым алганда эпос-дастаннар җәһәтеннән гаять нык кызыксындыра торган төбәк. Мәгълүм ки, Урал территориясе, татар авыз иҗаты хәзинәсе өчен «тере» эпос доноры булган Себергә барып тоташа, бу җәһәттән Курган өлкәсе татарларында дастани эпосның үсеш үзенчәлекләре шактый кызыклы. Рухи мәдәният үсеше өчен иң төп шарт – төбәктәге стабильлек. Идел буенда гомер кичергән татарлар тарихы белән чагыштырганда, Себер һәм аңа якын территорияләрдә яшәгән халыкларның мәдәни үсешендә кардиналь үзгәрешләргә бәйле өзеклекләр кимрәк, бу исә борынгы тамырлардан ук килә торган милли-мәдәни традицияләрнең сакланышын ныграк тәэмин иткән. Дастан – халык тормышын эпик планда чагылдыра торган жанр, телдән-телгә күчеп башкарыла торган мондый истәлекләрнең буыннан-буынга күчүендә сәяси һәм икътисади шартларның чагыштырмача стабильлеге хәлиткеч роль уйнаган булу гаҗәп түгел. Бу җәһәттән Урал арты төбәге гаять үзенчәлекле урын, биредә очрый торган эпик истәлекләр шушында гомер иткәннәрнең тарихы, тормыш рәвеше хакында бихисап мәгълүмат бирә ала, күпьяклап гомуми нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек тудыра.

Үз чорында бу төбәктә «Сәйфелмөлек», «Кузы Көрпәч белән Баянсылу», «Йосыф китабы», «Таһир белән Зөһрә», «Бүз егет» дастаннары, шушы ук һәм башка дастаннарның эпик җырлары, фабула характерындагы хикәятләр табылган һәм теркәлгән, алар беренчел фәнни әйләнешкә кертелгән.

Мәсәлән, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә «Кузы Көрпәч белән Баянсылу»ның Рәшит Ягъфәров тарафыннан магнитофонга язып алынган язмасы [ТРФА Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге, Кузы Көрпәч белән Баянсылу, кассета № 1] һәм аның күчермәсе [ТРФА Г. Ибраһимов ис.ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге, Кузы Көрпәч белән Баянсылу, 90 колл., 2 папка, 19 сакл. бер.], Асия Садыйкова язып алган «Кузы Күрпәс белән Майсылу» варианты [ТРФА Г. Ибраһимов ис.ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге, Кузы Күрпәс белән Майсылу, 91 колл., 1

папка, 33 сак. бер.] саклана. Шушы язманың «Кузый Курпас белән Майсылу» исеме белән бирелгән тексты беренче мәртәбә 2004 елда «Татар эпосы. Дастаннар» җыентыгында басылып чыкты [Кузый Курпас белән Майсылу: 2004. Б. 187–193]. Шушы ук Үзәктә дастанның 1966-нчы елда «Кузы-Көрпәс һәм Маян Сылу» исеме белән Фәрит Йосыпов язып алган варианты да бар [ТРФА Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге Кузы-Көрпәс һәм Маян Сылу, 99 колл., 7 – 15 сак. бер.]. Әлеге текстны соңгырак чорда Фәрит Йосыпов бастырып чыгарды [Кузы-Көрпәс һәм Маян Сылу: 2006. Б. 246–247]. «Кузы Көрпә белән Баян Сылу» дастаны – төрки эпоста борынгылыгы белән данлыклы, татар фольклорында да киң таралган, барлыгы ике дистәдән артык татарча варианты мәгълүм әсәрләрдән. Дастан Казан китап нәшриятларында моңарчы 1878, 1890, 1896, 1909-нчы елларда дөнья күргән. Сюжет сызыгы һәм сәнгатьчә үзенчәлекләре буенча вариантлар бер-берсеннән артык аерылмыйлар, бер версияне тәшкил итәләр. Татар версиясе вариантлары тугандаш халыклар иҗатындагы (казакъ, алтай, бигрәк тә башкорт) версияләре белән шактый охшаш. Татар телле версиянең егерме өч вариантының берничәсе Урал арты информантларыннан язып алынган булу – игътибарны җәлеп итәрлек факт.

Эпос жанрында популярлыгы ягыннан иң алдынгы урынны «Йосыф – Зөләйха» сюжеты били. «Йосыф – Зөләйха» сюжетлы дастаннар – татарлар арасында бик киң таралган әсәрләр. Бу сюжетның безнең халыкта популярлыгын Библиядән үк килүче Ягъкуб һәм Йосыф пәйгамбәрләр образының исламда, Коръәндә киң яктыртылышы тәэмин иткән булса кирәк. Әмма Йосыфка багышланган дастан кулъязмаларының нәкъ менә Идел-Урал буе татарларында күпләп табылуы һәм саны 160тан артып киткән кулъязманың һәркайсы шушы төбәк татарлары тарафыннан башкарылган булу факты төп игътибарны нәкъ менә Идел буе Болгарының мәшһүр шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ына юнәлтә. XIII гасыр башында иҗат ителгән бу поэманың татар әдәбиятына һәм фольклорына XIII–XVI йөздән алып әле бүгенгәчә тирән йогынты ясавы мәгълүм. Шәрык, бигрәк тә исламның бай традицияләре нигезендә барлыкка килгән бу гүзәл әсәр шушы ук сюжетка халыкта өр-яңа вариантлар туууга һәм, мондый әсәрләргә ихтыяҗ зур булу нәтиҗәсендә, аларның тиз генә популярлашып китүенә сәбәпче була.

Поэманың халыклашкан вариантлары татарларда да, башкортларда да «Йосыф китабы» дигән исем белән йөртелгән, «Йосыф» дип бирелгән очраклар да бар. Яшәү һәм таралу ягыннан язма формалары да, сөйләмә дастаннар да очрый. «Йосыф китабы»ның моңа кадәр табылган

һәм табыла торган күп санлы кульязмаларының шактые – шулай ук халыклашкан вариант. Мәсьәләнең бу ягы һәм гомумән поэманың татар фольклорына ясаган тәэсире Кол Гали иҗатына багышланган махсус хезмәтләрдә җентекләп яктыртылган һәм алар бу хакта тулы мәгълүматны җиткерәләр [Хисамов: 1984]. Фольклор әсәрләреннән «Йосыф китабы», «Сәйфелмөлек»тән генә калышып, иң тәүгеләрдән булып, Казан типографияләрендә китап булып басыла башлый һәм саны белән барлык дастаннарны да узып китә: 1841-нче елдан алып 1915-нче елгача 80 мәртәбә басылып чыга.

Әсәр бик күп таралган, һәрбер вариантны исәпкә алып бетерү дә мөмкин түгел. Алар арасында тулылыгы һәм үзенчәлекле булуы белән аерылып тора торганнарыннан алып, «Йосыф китабы» фабуласын йә берничә эпизодын сөйләп бирә торган кыска язмаларга кадәр очрый. Халыкта күбрәк «Кыйссаи Йосыф»ның китаптан уку, китап эчтәлеген сөйләп чыгу, билгеле сюжетка ияреп, яңа вариантта сөйләү кебек формалары киң таралган булган.

Әсәрнең кырыктан артык варианты арасында икесе XX йөзнең 70-нче еллар азагында татар фольклорчылары тарафыннан Курган, Чиләбе өлкәләре информантларыннан язып алынган. Болар – Сабира Гайнетдиновадан (1907 елгы) Рәшит Ягъфәров язып алган вариант [ТРФА Г. Ибраһимов ис.ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге, Йосыф-Зөләйха, кассета № 2] һәм Фаизә Гобәйдуллинадан (1877 елгы) «Йосыф» дигән исем белән Асия Садыйкова язып алган текст [ТРФА Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге, Йосыф, 91 колл., 1 папка, 21 а сак. бер.]. Болар икесе дә шактый төзек вариантлар булуы белән әһәмиятле.

Яисә «Сәйфелмөлек» – безнең халыкта кульязма булып та, китап рәвешендә дә, шулай ук сөйләмә формада һәм эпик җыр рәвешендә дә күпләп таралган, яратып укылган әсәр. Аның сюжеты атаклы язма чыганакка – «Мең дә бер кичә»гә барып тоташа. Гарәптән фарсыга, фарсыдан төрки телгә күчеп таралган әлеге сюжет татарларга бик борынгыдан мәгълүм булган. Төрки шагыйре Мәҗлисинең XVI гасыр башларында шушы сюжетка күләмле бердәнбер әсәр иҗат итүе мәгълүм. Шагыйрь үзе «Сәйфелмөлек» дастанын фарсы телле язма чыганактан алуы турында әйтә [Мәҗлиси: 2007. 8 б.]:

*Вә ли ул нөсхә фарсы вә нәсер,*
*Ирер садә хикәят сәррәхум кыср.*
*Кылыптыр Мәҗлиси бу сүзе пордаз.*
*Укысаң, кылыр җан кошыны пәрваз.*

Ягъни: «Фарсыча прозада гадирәк кенә яңгырашлы ягымлы хикәятне Мәҗлиси бизәкле ясады, укысаң, җан кошын канатлы итәр».

Дастанның Мәҗлиси варианты – фольклор белән тыгыз бәйләнгән, әмма әдәбилеккә дәгъва итә торган гүзәл, гаҗәеп камил шигъри әсәр. Аның борынгы язуы белән бергә хәзерге әдәби телгә күчерелгән тексты бездә китап булып дөнья күрде [Мәҗлиси: 2007]. XIX йөз башы – татарларда милли әсәрләр ныклап торып басма китап рәвешен ала башлаган чор. «Сәйфелмөлек» шушы процесста иң әүвәл катнашып китүе белән әһәмиятле, ягъни татар телле беренче дөньяви басма китап булып Казанда 1807-нче елда нәкъ менә «Сәйфелмөлек» дөнья күрә [Сәйфелмөлек: 1807]. Бу вакыйга татарларда гына түгел, гомумән төрки дөньяда «Сәйфелмөлек»нең тәүге мәртәбә басылып чыгуы була.

«Татар халык иҗаты. Дастаннар» академик басмасына (1984, 151–158 бб.) «Сәйфелмөлек»нең Ф. Әхмәтова Түбән Новгород өлкәсендә Ләйлә Алимовадан (1924 елгы) язып алган вариант кертелгән. Шушы ук текст «Татар эпосы. Дастаннар» җыентыгында да урын алган (2004, 110–118 бб.). Дастанның мәгълүм татар телле вариантлары дистәдән артып китә. Барысының да сюжетында Сәйфелмөлеккә багышланган Мәҗлиси әсәре йогынтысы, шулай ук XIX йөз башыннан Казанда китап рәвешендә чыгарыла килгән басма вариантлары белән якынлык сизелә. Мәҗлиси дастаны татар халкында «Сәйфелмөлек» сюжетының популярлашуына бик нык йогынты ясый. XIX гасыр башыннан бу әсәр, Мәҗлисинеке белән чагыштырганда кайбер үзгәрешләр кичереп (кыскартылган вариантта яисә нindидер өлеше төшереп калдырылып), әмма күп очракта шактый тулы килеш Казан типографияләрендә каткат басыла. Аның 1807, 1838, 1840, 1841, 1849, 1858, 1864, 1880, 1883, 1888, 1895, 1898, 1902, 1903, 1909 елларда «Гимназия», «Университет», «Коковин», «Чиркова» һәм башка типографияләрдә нәшер ителүе мәгълүм.

XIX йөз башыннан алып XX йөз башынача басыла килгән бу дастанны «Сәйфелмөлек»нең Мәҗлиси вариантына якын, әмма шактый дәрәҗәдә халыклашу кичергән вариантлары дип санарга тулы нигез бар. Боларда авторлык күрсәтелмәгән, әсәр «Сәйфелмөлек китабы», «Сәйфелмөлек кыйссасы», «Сәйфелмөлек хикәяте» исеме белән басылган. Күләме төрлесенеке төрлечә – 31, 52, 54, 64, 72, 115, 125 битлек. Болар – сюжеты белән «Әлфе ләйлә вә ләйлә» («Мең дә бер кичә») әкиятләренең 756–778-нче төннәренә барып тоташа торган шигъри дастаннар. «Сәйфелмөлек» – басма формадагы китаби дастанның яңадан халык сөйләменә күчеп, авыз иҗаты буларак яши башлавының янә бер үрнәге буларак кыйммәтле ис-

тәлек. Татар версиясе текстының XIX гасырның беренче чирегендә формалашкан булу ихтималы зур.

Әсәрнең билгеле вариантларыннан берсен Институт тарафыннан Урал якларына оештырылган фольклор экспедициясендә 1979 елда Фаизә Зәбир кызы Гобәйдуллинадан (1877 елгы) Асия Садыйкова язып алган [ТРФА Г. Ибраһимов ис.ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге, Сәйфелмөлек, 91 колл., 1 папка, 21 сак. бер.]. Сюжеттагы кайбер үзенчәлекләре, өстәмә образлар һәм текстта очрый торган морфологик-синтаксик аермалыклары булуга карамастан, дастан нигездә моңа кадәр басылган вариантка шактый якын. Әмма ике вариантны янәшә куеп тикшерү эпос белгечләре тарафыннан әлегәчә башкарылмаган, дастанны киләчәктә мондый махсус өйрәнү галимнәр өчен перспективадагы эш буларак әһәмиятле.

Болардан тыш Урал арты – күп кенә төрки халыклар бик яратып иҗат иткән, бүгенге көндә үзбәк, дүрт – уйгыр, ике дистәдән артык – азәрбайҗан, берничә – төрек, казакъ, төрекмән версиясе, башкорт телендәге төрле күләмдәге текстлары мәгълүм, татар вариантлары исә дистәдән артып китә торган, Таһир белән Зөһрә турындагы популяр сюжетка корылган дастан вариантлары табылган өлкә. Әсәрнең татар вариантлары шактый. Г. Тукайның мәгълүм сүзләре белән әйткәндә, «татарның бик искедән бирле укылып килгән әдәби китабы»на Курган өлкәсе татарларының да бик борынгыдан ук битараф булмавы күп нәрсә хакында сөйли. Бу төбәктә 1966 елда Сабира Шәфикъ кызы Гайнетдиновадан (1907 елгы) Ф. Йосыпов [ТРФА Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге, Таһир-Зөһрә, 99 колл., 7–15 сак. бер.], 1978 елда Сабира Гайнетдиновадан (1907) Рәшит Ягъфәров әлеге дастанның фабула характерындагы берәр вариантын язып алганнар [ТРФА Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге Таһир белән Зөһрә, 91 колл., 1 папка, 21 сак бер.]. Моннан тыш Институт архивында Фаизә Гобәйдуллинадан Асия Садыйкова язып алган вариант та саклана [ТРФА Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге Таһир белән Зөһрә, 93 колл., 1 папка, 21 сак бер, кассета № 1].

Уртак дастани сюжеттан боларда Кормаши вариантында да очрый торган баласызлык, бер алманы икегә бүлеп бирү мотивлары, багучы карт, гарәп, Таһирның апасы, ырымчы карчык образлары, сәхрәгә чыгу, мәктәптә уку, сандыкка салып диңгез суына агызу, тәрәз астына килеп җырлау эпизоды һәм башкалар очрый. Информантлар эпик җырларны да игътибарсыз калдырмаган. Вариантларның Рәшит Ягъфәров тарафыннан язып алынганында ике урында тезмә юллар китерелгән. Аның беренчесе – Зөһрәнең кызларына әйткән җыруы:

*Әйдәң, кызлар, йөгерешик,*
*Таһир каберенә җитешик,*
*Энҗе-мәрҗән сибешик.*

Ә икенчесе исә, Таһирның үлеме турындагы хәбәрне ишеткәч, Зөһрәнең җырлаган җыруы:

*И татарсыз, татарсыз,*
*Бер-береңә ук атарсыз,*
*Базарда ит беткәнме,*
*Таһир итен ашарсыз.*

Фаизә Гобәйдуллинадан Асия Садыйкова язып алган вариантта исә тезмә юллар бераз үзгәрәк һәм түбәндәгедән гыйбарәт:

*И ата, миңа салган сараеңның*
*Эченә ут сал инде, ди.*
*Ялкын итеп бер яндырып,*
*Бер кызынып кал инде, ди.*

*Эт зәйтүнен китерерсең, ди,*
*Аны кунак итәрсең, ди,*
*Миннән башка кызың булса,*
*Аны кияү итәрсең, ди.*

«Бүз егет» – төрки халыклардан татар, башкорт, нугай, казакъ, кумык, балкар халыкларында версияләре мәгълүм фольклор әсәре. Татар халкы аны кулъязмадан да, басма китаптан да укыган, язма «Бүз егет» тәэсиреннән кабат халыклашканмы, я булмаса элгәрләребез телендә актив яшәгән булганмы, халкыбызда аның сөйләмә вариантлары да очрый. Күбрәк өлеше шигъри юллардан гыйбарәт гаҗәеп матур, күләмле әсәр. «Бүз егет»нең татар фольклористикасында шартлы рәвештә «Баһави варианты», «Кормаши варианты» дигән исемнәр белән атала торган дастаннарында йола җыры – «Яр-яр»ның үзенчәлекле текстлары китерелү факты әһәмиятле. «Яр-яр» – татарларда ханлыклар дәверендә үк актив кулланылышта йөргән үрнәкләр. «Бүз егет» дастанының татар телле һәр варианты – татар дастаннарының тел-стиленә, хикәяләү рәвешенә, шигъри үлчәменә һәм рухына туры килә торган, борынгылыкны саклаган гүзәл әсәрләр. Фольклорчы Р. Ягъфәров 1978 елда хәзерге Курган өлкәсенә керә торган Сафакүл районында Нәгыймә Мөстәкыймовадан (1906) «Бүз егет»нең бер вариантын магнитофон тасмасына язып алган [ТРФА Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге, Бүз егет, кассета № 2], аның күчермәсен биргән [ТРФА Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас

үзәге, Бүз егет, 90 колл., папка №2, 19–22 сак. бер.]. Күчермә чәчмә тексттан гыйбарәт. Информант Кормаши вариантының кыскача эчтәлеген сөйләгән. Түбәндәге эпик җыр өлеше биредә үзенчәлекле көй белән әйтелгән:

*Карлыгач карлыгачка җим бирде,*
*Карендәш карендәшкә дим бирде.*
*Ялгызлыкка төшептер моңлы башым,*
*Мин ятып йөргәнемне кем белде?*
*Уйлыймын җанымны монда аласыңмы, дип,*
*Моңлы башым бу җирләрдә каламы, дип,*
*Кем үлмәкин калма, ди яраткандин соң* (ягъни: җиргә яратылган берәү дә үлми калмый),
*Куркамын гүр-кәфенсез калам, дип.*
*Ходайга тәкъдиремдин калганым юк,*
*Борылып качарга һич дәрманым юк,*
*Каһһәррәхим әйләсәң, Кадир алла,*
*Синдин башка һичкемгә егъларым юк.*
*Агачның башын киссәң, төбе калыр,*
*Икәүнең бере үлсә, бере калыр,*
*Ялгызның үзе үлсә, нәрсәсе калыр?*
*Менәр аты, кигән киеме, юлы калыр.*
*Әйтәем, дисәм, бу илләрдә сүзем сынык,*
*Булмас ахры гарубәттән (горбәт: гарәп сүзе, мосафирлык, туганнарыннан аерылып, чит илдә булу) күңелем тынык,*
*Аллага нә кыйлсаң да чарамыз юк,*
*Котылмас йиргә очрады гарип башым.*

Югарыда телгә алынган, үткән гасырда экспедиция вакытында туплап алып кайтылган материаллар, барысы да бик пөхтәләп Мирасханәгә – Институтның архив фондларына тапшырылганнар. Алай гына да түгел, ул чактагы экспедицияләрдә халыктан җыелган фольклор үрнәкләре бик күп җыентыкларга кертелгән, шул исәптән 1989 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган 12 томлык академик «Татар халык иҗаты» җыентыгының «Әкиятләр», «Дастаннар», «Риваятьләр һәм легендалар», «Табышмаклар», «Мәкальләр», «Җырлар», «Мәзәкләр», «Бәетләр» томнарында лаеклы үз урынын тапканнар яисә теге я бу фольклор әсәренең варианты буларак күрсәтелгәннәр. Бу төбәктәге информантлардан язып алынган эпик әсәрләрнең бер өлеше басылып чыккан, әлегәчә язып алып кайтылган хәлендә беренчел кульязмада саклана торган истәлекләр дә шактый. Аларның һәркайсы белән бүгенге көндә Татарстан Республи-

касы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондларында танышырга мөмкин. Бу чорда Урал арты татарларыннан язып алынган «Сәйфелмөлек» дастаны да, «Кузы Күрпәч белән Баянсылу» да шушы ук сюжетка моңа кадәр дөнья күргән вариантларыннан үз үзенчәлекләре белән аерылып тора; «Йосыф-Зөләйха» сюжетлы дастан вариантында исә «Китабы дәдәм Коркыт»тагы сюжет килеп кергән, биредә Йосыф пәйгамбәрнең Кәнган белән Мисыр арасында казылган кабергә кереп ятуы турында сөйләнә. «Таһир белән Зөһрә» дастаннары Кормаши вариантының фабуласы характерында, күп өлеше чәчмә тексттан тора, әмма чорына күрә аерым информантлар авызыннан язып алынган эпик сюжет чагылышы булулары белән кыйммәт. Дастан текстларыннан тыш югарыда телгә алынган эпос-дастаннарның күпчелек вариантлары музыкаль нотага да төшерелгән. Ноталы текстлар Ф. Ваһапова төзегән «Татар халык иҗаты. Дастаннар» (1984) томында теркәлгәннәр. «Кузы Көрпәч белән Баянсылу» дастанының көй үрнәге, «Сәйфелмөлек», «Йосыф китабы», «Таһир белән Зөһрә» (ике вариантта) дастаннарындагы эпик җыр, «Бүз егет» дастаннарының көй үрнәкләре – эпос һәм музыка белгечләре өчен әһәмиятле чыганак. Дастанның фольклористикада эпик җыр дип атала торган мондый өлеше, ягъни «тере» музыкаль фольклор ул – бүгенге көн белгече өчен аеруча кадерле мирас. Бүгенге көндә «тере» эпос-дастаннарга юлыгу сирәк күренеш, әмма бурычыбыз берничә ел элек теркәлгәннәрен популярлаштыру. Курган өлкәсендә һәм аңа якын территориядә яшәүче яисә яшәгән милләттәшләребез белгән, үз иткән дастаннар – гомумкешелек кыйммәтләрен алга сөргән идеяләр белән сугарылган милли эпик ядкарьләребез. Алар узган гасырның алтмышынчы–җитмешенче еллар фольклор экспедицияләре кайтавазы буларак мөһим. Шушындый истәлекләрнең Урал арты информантлары авызыннан язып алынган булуы әлеге төбәк белән бәйле төркиләрнең уртак тамыры, бердәй мәдәнияте хакында сөйли.

### Әдәбият

1. Исхаков Д.М., Измайлов И.Л. Этнополитическая история татар в VI–первой четверти XV века. Казань: Иман, 2000.
2. Долгих Б.О. Родовой и племенной состав народов Сибири в XVII веке. М.: АН СССР, 1960.
3. Кузый Курпас белән Майсылу // Татар эпосы. Дастаннар / Төз., кереш сүз һәм искәр. язучы, сүзлекне әзерләүче Ф.В.Әхмәтова-Урманче. Казан: Раннур, 2004.

4. Кузы-Көрпәс һәм Маян Сылу // Юсупов Ф. Ю. Сафакүл татарлары: тарих, тел, халык иҗаты. Казан: ООО «Татполиграф», 2006.
5. Мәҗлиси. Сәйфелмөлек: дастан / Төз. һәм кереш сүз авт. Ф. Яхин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.
6. ТРФА Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәге, фольклор фонды, 91 колл., 1 папка, 1–12, 13, 14, 15, 16–18, 18–21, 30–35, 36–37, 38 сакл. бер.; 2 папка, 19–65 сакл. бер.; 90 колл., 1 папка, 1–2, 19–65 сакл. бер.; 99 колл., 7–15 сакл. бер.
7. Сәйфелмөлек. Казан: Гимназия тип., Йосыф Исмәгыйль улы Апанаев нәшере, 1807.
8. Хисамов Н.Ш. Бөек язмышлы әсәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

***Илсөяр Закирова***

# ВАГАЙ РАЙОНЫ ХАЛЫК ИҖАТЫ

*(2002-нче елгы экспедиция материаллары буенча)*

*Бу мәкаләдә Төмән өлкәсенең Вагай районында урнашкан Казанлы, Тугыз авылларында тупланган халык иҗаты үрнәкләре белән таныштырырга телибез. Әлеге авылларда яшәүче информантларыбыздан авыл тарихы, себер татарларының ислам дине кабул итүе, аучы-мәргәннәр, ислам изгеләре, түбәнге мифология персонажлары турында риваять-легендалар, бик күп ышанулар, истәлек-сөйләкләр язып алынды. Бу як фольклорының берничә үзенчәлеге күзгә ташлана. Беренчедән, һәр вакыйганың конкрет урыны, вакыты, герое бар. Информант борын-борында булган вакыйганы түгел, ә шул авылдагы фәлән абый яки фәлән мама (апа) белән булган вакыйганы бәян итә. Бу мифологик хикәятләр өчен мәгълүм алым. Әмма Себер информатлары еш кына үзләре дә шушы мифологик хикәятләрнең героена әверелә яки аларда аның әнисе-әтисе, бабасы белән булган хәлләр тасвирлана. Информантлар үзләре биргән материалга тулысынча ышана. Бер үк әсәрнең вариантларын һәр информант үзенеке итеп сөйли. Икенчедән, аерым жанрлар бик популяр, халык хәтерендә яхшы саклана, аларны яше-карты белә. Бу – мифологик хикәятләр, гыйбрәтле хикәяләр, ислам изгеләре, ислам кабул ителү һәм аучы мәргәннәр турындагы риваятьләр.*

Себер татарлары ислам динен XIV-нчы гасыр ахырында кабул итә, 1394-нче елда бу якларга Бохарадан 366 шәех килеп чыга.... Миссионерларга үзенең коралланган 1700 батыры белән Урта Азия далалары ханы Шаһбани да ярдәмгә килә. Халык ислам динен үзе теләп кабул итмәгән очракта зур канлы бәрелешләр булган. 366 шәехнең өч йөзе һәлак була. Өчесе генә Себердә яшәп кала. Әмма ислам дине кабул иткән халыкны укыту-өйрәтү өчен Бохарадан шәехләр, дин белгечләре күпләп килә башлый. Күпләре шунда яшәп тә кала. Менә шушы шәехләр күмелгән урыннар – *астаналар* дип атала. Алар кайбер очракларда авыл, ә кайвакыт күмелгән шәехләрнең исеме белән атап йөртелә. Астаналарны карап, чистартып торган кешеләр бар. Бу җирләрдә агач сындырырга, җиләк өзәргә дә ярамый. Нәзере, берәр теләге булганнар астананы карап торучыларга сәдака бирә, кайбер очракларда сәдакаларны кызыл чүпрәк кисәгенә бәйләп юлчылар артыннан астаналарга җибәрәләр. Казанлы астанасының изге хайваны – *каз*, ә күрше Тугыз астанасының – *үгез*. Төшендә астана хайванын күргән кеше дә, моны кисәтү дип аңлап, үзе-

нең эшләгән эшен искә төшерә, сәдака бирә. Астаналар олы һәм кечегә бүленә. Олылары – Бохарадан килгән шәехләрнең каберләре, ә кечеләре соңрак чорларда, мәсәлән, Гражданнар сугышы елларында һәлак булган дин әһелләре, муллалар каберләре. Астаналар турында бик күп ышанулар һәм риваятьләр сакланган.

Хызыр Ильяс турындагы риваятьләр дә шактый язып алынды. Хызыр Ильяс начар гына киенгән карт кыяфәтенә кереп урманда, сазлыкларда юл сорый яки авылда юлчы булып кунарга кертүләрен үтенә. Үзенә ярдәм иткәннәргә рәхмәт әйтә, андый кеше баеп китә, баласызларның баласы туа, ә ярдәм итәргә теләмәгәннәр бик авыр хәлдә калалар. Бу – үзләренең эчтәлекләре белән гыйбрәтле хикәятләргә якын дидактик эчтәлекле әсәрләр. Аларның төп идеясе – яхшылыкка яхшылык белән җавап бирү, начар эшләр өчен җәзалау.

Себер татарларының бай иҗат фантазиясе аларның әйләнә-тирә дөньясын күптөрле фантастик персонажлар ярдәмендә тулыландыра. Түбәнге мифология персонажлары турындагы хикәятләр бик популяр. Аларның берсендә мифологик персонажлар турында мәгълүмат тупланса, икенчеләрендә шулар белән аралашкан кешеләр тасвирлана. Бу затларны явыз һәм зарарсызларга бүлеп карап була.

Информантлар белән сөйләшкәндә бу яклардагы иң популяр персонаж – *Еш* һәм *Еш ияләр* икәнен белдек. Ешлар безнең Шүрәлеләрнең якын туганы булып чыкты. Безнең Шүрәлеләр, «аларны асрап ятарлык» кап-кара урманнар булмау сәбәпле, юкка чыгу алдында булса, Ешлар бик матур гына яшәп яталар икән. Ешлар – хатын-кыз персонажлар. Өйләнмәгән аучы мәргәннәр аларны урманда адашкан хатын-кыз дип белеп, авылга алып кайтып, өйләнгән очраклары да булгалаган. Әмма, берничә балалары туса да, Еш үзенең ешлыгын онытмый, кем икәнлеге ачылгач, ул тәрәзәдән чыгып китә, ди. Әмма, алар кешедән туган балаларын алып китә алмыйлар, алар әтиләре белән яшәп калалар. Авылларда Еш ияләр белән кеше никахыннан калган нәселләр әле дә бар икән. Еш ияләр – ир-ат затыннан. Алар аучы-мәргәннәрне, җиләк-гөмбә җыючыларны адаштырып үтерәләр. Еш ияләр сунарчыларны берәр кеше тавышы белән урман эченә чакырып кертәләр икән. Гадәттә Ешлар турында сөйләгәндә, вакыйганың вакытын, урынын, кешесен конкрет күрсәтеп сөйлиләр. Бу – мифологик хикәятләр өчен мәгълүм алым. Бу хикәятләрдән Ешларның зарарсыз булулары аңлашыла. Ә Еш ияләр исә кешеләргә зыян китерүче явыз затлар буларак күренәләр.

*Йилбегән* – бик борынгы персонажлардан, әле М. Кашгариның «Дивание лөгат ет-төрк» сүзлегендә (XI г.) үк «Йетү башлы Йелбүкә» дигән гыйбарә сакланган. Шамратова Гөлҗамал ападан «Җиде башлы Йилбегән»

дигән әкият язып алдык. Бу әкияттә Йилбегән, кеше канын эчеп, кеше ашап яшәүче явыз зат булып гәүдәләнә. В. Радлов язып алган «Кадым Мәргән» әкиятендәге Йилбегән исә безнең әкиятләрдәге диюгә күбрәк охшаган. Әмма ул әкият герое – Батыр Егет тарафыннан җиңелә. Бу образ себер татарларына Алтай мифологиясеннән кергән булырга тиеш. Алтайлыларда Йилбегән кешеләргә һөҗүм итүче персонаж, кайвакыт батырларга аларны җиңәргә Ай белән Кояш та булыша, Йилбегәннәр бер, өч, җиде, унике башлы, кара һәм сары төстә булалар.

Себер татарлары мифологиясендә явыз затлар шактый. Шуларның берсе – *Купкан*. Ул – үлгән кешенең, гадәттә, дөньядан, яшәүдән туймаган кешенең җаны. Купкан төннәрен җирләнгән гәүдәсеннән чыгып йөри. Башта кечерәк хайваннардан, аннары сыер, үгез кебек олыраклардан кан эчә. Үзе дә башта мәче, эт, аннары сыер, үгез булып күренә. Шуннан кеше канын эчә башлый. Үзенең кыяфәтендә йөри. Кеше кыяфәтендәге Купканны җиңүе кыенлаша. Бу образ татар мифларындагы Убырга якын тора. Купканның кабер өсте иләнгән төсле була, ул үз кабереннән түгел, ә үзеннән соңгы җиденче кабердән чыгып йөри икән. Әмма Купкан никадәр куркыныч булса да, муллалар аларны җиңә ала, кире каберенә кайтырга мәҗбүр итә.

Купкан – үлгән кешенең җаны. Шулай ук тере Купкан, ягъни Мәцкәй, турында хикәятләр, ышанулар да күп. Мәцкәй – убырга әверелгән кешеләр, алар да кеше каны белән туклана. Кече Уаттагы *Дәүләтали тухы, Меткә авылы Купканы, Тирәнаер авылы Мәцкәйе* турында хикәятләрнең күптөрле вариантлары бар.

Себер Алыплары *Полваннар* дип атала. Полван – пәһлеван дигән сүздән. Алар зур гәүдәле, көчле кешеләр, еш кына аучы-мәргәннәр буларак сурәтләнәләр. Гомумән, аучылар-мәргәннәр турында риваятьләр бик күп. Аларның төп персонажлары – аю. Аю кеше кебек акыллы итеп тасвирлана. Легендаларда аюга карата мөнәсәбәттә тотемизм элементлар да күзәтелә. Еш очраучы сюжетның берсендә аю белән хатын-кыз никахы турында сүз бара.

Табигать күренешен җанландыруга юнәлдерелгән мифологик персонаж – *әләмәче* (*әләмәце*) турындагы ышану да кызыклы. Әләмәче – җил-буран белән йөрүче явыз рух. Ул көчле бураннар, өермәләр вакытында очып йөри, балаларны урлый, кешеләргә зыян сала дип ышанганнар. Әләмәченең күңелен күрү өчен аңа икмәк, ризыклар калдыра торган булганнар.

Мифологик хикәятләрдәге тагын бер образ, ислам дине аша кергән – *җен*. Җеннәргә – параллель дөньяви халкы итеп карап, халык «конфликтлы ситуацияләр тудырмыйча» яшәргә омтыла. Кич белән мунча кергәндә ишек шакып рөхсәт сорыйлар, чыкканда рәхмәт әйтәләр. Кояш баеган вакыт мунча җеннәренең юына торган вакыты, бу вакытта мунча-

га керергә ярамый. Кич белән өенә кайтучы кеше: «Мин хәзер фәләннәргә барам», – дип сөйләнә. Җен тизрәк шунда ашыга икән. Җеннәр үзләре дә кешеләрдән ярдәм сораган очраклар булгалый. Мәсәлән, бер риваятьтә Мәймүнә исемле хатынның җен хатынына *инәлек* (*кендек әбисе*) булуы турында сүз бара.

Себер татарларының фольклоры гына түгел, йолалары да шактый үзенчәлекле. Мәсәлән «*Чәч туе*» дигән йола монда гына очрый. Ир баланың 40 көн тулгач, беренче чәчен алып, «Чәч туе» уздырганнар. Ат чабышлары, *ат-мәҗлес* белән зур бәйрәм булган. Ә *сөннәт туе*, ир бала шактый үскәч, 5 яшьтән 14 яшькә кадәр үткәрелгән.

Гомумән, себер татарларының фольклоры, аның образлар системасы бик кызыклы һәм ул хәзерге вакытта фәнни нигездә өйрәнүне таләп итә.

***Кушымта***

## *ЕШ ИЯ*

Еш ия – ир затыннан. Бер мәргән төскә чыккан. Еш ия белән урманда очрашкан да бер избушкада кунган болар. Икесенең дә мылтыгы булган. Бер-берсеннән сораганнар болар, мәргән:

– Сез ничек йоклыйсыз? – дигән.

– Без йоклаганда авыздан очкыннар чәчри. Ә сез ничек йоклыйсыз? – дигән Еш ия.

– Без йоклаганда үлгән кеше төсле, – дигән мәргән.

Бер-берсенең йоклаганын көткәннәр. Еш ия йокыга киткән. Мәргән бер бүрәнә алып үз урынына куйган, толыбы белән каплаган. Үзе чыккан. Еш ия уянган да, бүрәнәне мәргән дип белеп чапкан. Мәргән, мылтыгын төзәп, агач артына качкан. Еш ия чыккач, аны аткан. Еш ия:

– Тагын бер ат! – дигән.

Мәргән:

– Егетнең – бер, ирнең – өч, – дигән. Тагын атса, Еш ия тереләсе булган икән.

## *ТӘҮЛӘТАЛИ ТУХЫ*

Борын-борын заманда Малай (Кече) Уваттан Тәүләтали дигән кеше урыслардан әйбер урлаган. Аннары урыслар аны сихерләгән. Ул авырып үлгән. Хәзер ул төстә йөри. Без аны белмибез, шуңа күрә, күрсәк тә, танымыйбыз. Чиягә барсак, төнлә өскә шалашны аудара. Ул, көрәк белән бәрә-бәрә, агач исәпләп йөри. Авылда аны белүче кешеләр үлеп беткәч, кайтачак.

*Тугыз авылында яшәүче Бахметова Сөлҗамал Ситдыйк кызыннан язып алынды. 1926 нчы елда туган.*

### *ИЯРТЕП КИТҮ*

Төстә Еш ия, берәр кеше булып кычкырып, ияртеп китә. Андый кешенең, аңына килсен өчен, куып җитеп аркасына сугарга кирәк. Тырнакүзгә барган ханым-кызларны ияртеп китә. «Флера, бу якка кил!»–дигән тавыш килә, берәр кеше тавышы белән чакыра. Андый чакта урыныңнан кузгалмаска кирәк. Аннары: «Фәлән апа, мин шунда, килеп ал»,–дип кычкырасың. Алар кешенең исен-акылын алалар.

Г. Гыйльмановның «Казан утлары»нда «Албастылар» дигән әсәре басылды. Ул фантастика түгел, язучы булган хәлләрне, шушы ешлар турында язган.

*Тугыз авылында яшәүче Сибгатуллина Флүрә Кинчә кызыннан язып алынды. 1938-нче елда туган.*

### *ҖИДЕ БАШЛЫ ЙИЛБЕГӘН*

*(йомак)*

Җиде башлы бер йилбегән булган. Башында җиде мөгез булган икән. Өч туган булган. Икесе–ир туган, берсе–кыз туган. Ир туганнары мәргәннәр булган икән. Зур абыйсының исеме Пайгана булган икән. Сеңелләрен калдырып алар төскә чыгып китәләр. Алар төскә чыгып киткәч, җиде башлы йилбегән килә. Кереп кызны куркыта: «Абыйларыңа әйтмә»,–ди икән. Инә-без белән уйнаган булып, кызның табанын тишеп канын эчә икән. «Абыеңа әйтсәң, мин сине йотам»,–ди икән. Өч көн канын имгән. Хәле беткән. Дүртенче көн, каны беткәч, яткан. Абыйлары сораса да, әйтми икән. Абыйлары үзләре өйдә калган дүртенче көн. Урамда берзаман давыл чыгып киткән. Башка җирдән керә алмаган, морҗага менгән. Морҗадан бер мөгезен төшергән, абыйсы мөгезне чапкан. Җидесен дә берәм-берәм төшергән, җидесен дә абыйсы чапкан. Җиденчесен тыкканда, йилбегән әйткән: «Бүген ашап чыга торган көнем иде»,–дигән.

Кыз яхшырган. Абыйлары белән яшәгәннәр. Мөгезләрендә көче булган, көче беткәч, йилбегән үлгән.

### *НУГАЙ АЛТЫНЫ*

Олы Күлдә, Күл читендә Нугай дигән авыл булган. Анда бер килендәш килеп төшкән була. Ул килендәш кырга чыккач, зур бер чүлмәк белән алтын күргән. Ул аны кулына алып уйнаткан. Икенче көнне дә барып уйнаткан. Өченче көн баруына–алтын булмаган. Килендәш бик саран булган. «Үземә генә булыр», дип уйлаган. Алтын шуңа күрә өченче көн баруына юкка чыккан. Аннары, алтын югалгач кына, иренә дә, халыкка да әйткән: «Шундый хәл булды, мин әйтмәгән идем»,–дигән. Бер мулла

карт палтар (фал) караган. Әйткән: «Котык (кое) токымнан бер кыз туар. Ап-ак чәчле, күк күзле, күз иясе кызыл булыр,–дигән.–Алтынны ул табар, унсигездә табар»,–ди.

Минем әтием 25 яшьтә сугышка китә. Әтием сугышта үлә. Кайтмый. Мине алып баручы булмый. Кырга мине алып чыгарга тиеш булганнар. Мин, пычак алып чыгып, алтын чыккач, «Мин шундый хайван суярмын, бу алтынны бөтен кардәшкә, ил-миргә бүләрмен»,–дип әйтергә тиеш булганмын. Пычак белән җиргә кадарга.

Әгәр мин ала алмасам, 60 елдан соң безнең токымнан тагын шундый ук бала туарга тиеш була. 60 елдан, 1997-нче елда туды, Тимурның да минем төсле чәче ак, күзләре күк, күз иясе кызыл. Хәзер аңа биш яшь.

### *КАРАКЧА (Карак)*

Элек Малай Уаттан (Кече Уват авылы) бер карт күршесенә ирмәккә кергән. Аннан чыгып килгәндә, төнге уникеләрдә, аны бер каракча күтеп торып, алып киткән. Карт бик курыккан. Мине үтерә инде бу, дип. Каракча күл итәккә (янына) алып төшкән. Көймәгә утырткан картны. «Мине Агытбаш Семегә (Агыт елгасы башындагы упкын урын) алып бар»,–дигән. Карт алып киткән. Каракча мылтыклы булган. Семегә алып барган. Картны, көймәсе белән өстерәп, кырыйга чыгарган. Карт юлны Вершинга (авыл исеме) күрсәткән. Каракча картка: «Кәпәцеңне салып көймәгә утыр!»–дигән. Кәпәцкә тулганчы алтын койган, юл күрсәткәнгә рәхмәтен әйткән. Аннан соң картны этеп җибәргән. Карт кайтып җиткән. Корткасы (карчыгы) белән бай яшәгәннәр.

*Тугыз авылында яшәүче Шамратова Гөлҗамал Ситдыйк кызыннан язып алынды. 1937 елгы.*

### *ХЫЗЫР ИЛЬЯС ТУРЫНДА*

Безнең авылда Хәким бабай дигән мәргән яшәгән. Җиде тапкыр өйләнгән, баласы булмаган. Берзаман соңгы бичәсе белән яшәгәндә, боларга бер карт керә. Төссез (начар киенгән), картайган кеше. Каршы алалар, ашаталар, эчертәләр. Бу карт болардан хәл-әхвәлләрен, ни белән шөгыльләнүләрен сораша. Хәким бабай әйтә: «Күптәннән бирле йөрим, бернәрсә эләктерә алмыйм. Ничә ел яшибез, балаларыбыз да юк». Гомумән, ярлы яшәүгә зарлана.

Иртә торып ашап-эчеп алгач, бу карт боларга теләк теләп чыгып китә. Баскычлары начар булганга озата чыгалар. Ишекне ачып карасалар, бер кеше дә юк, карда эз дә юк. Болар моның Хызыр Ильяс икәнен аңлый. Бер ел тулмый, ир балалары туа.

### *МЕТКӘ КУПКАНЫ*

Меткә авылында бер кеше купкан. Ул хайваннардан кан имә, аннары кешенең канын имә. Хайван канын имгәндә ул башта мәче, эт, үгез, сарык булып йөри. Аннары үзе булып йөри. Йөргәндә җиргә басканы күренми. Кешегә әйләнгәч, мулла аны җиңә алмый. Меткәнең купканы шулай йөри башлый. Ул кешенең каберен ачалар, үлгән кеше кып-кызыл булып шешенеп ята икән. Моның башын чабып, култык астына салып куйганнар. Бу башын култык астына кыстырып йөри башлаган. Яңадан казырга курыкканнар, Казанлы авылыннан Муска (Муса) дигән кешене чакырганнар. Ул каберне казып усак казык каккан, әмма кәпәцен кабердә онытып калдырган. Өендә исенә төшә, кәпәц юк. Төнлә барып кәпәцне алып, яңадан күмгән. Бу вакыйга сугышка кадәр була.

### *ТИРӘНАЕР МӘЦКӘЙЕ*

Тирәнаер дигән авыл булган. Бу авылда бер сәбәпсез кешеләр үлә башлаган. Нидән икәнен белмәгәннәр. Бер көнне бер аучының тәрәзәсенә бер әйбер кулын тыга. Аучы теге кулны балта белән чаба. Кеше кулы була. Бу вакыт кояш байый торган була. Бу тере купканы була, ягъни Мәцкәй. Хәзер уйлыйлар, кем кулы бу? Конторга халыкны җыялар. Яше-карты килә. Авылда бер корткаяк күптән ятып авырый, ул гына килми. Бу корткаякның өенә киләләр. Кулын күрсәтми. Мылтык белән куркытып, карчыкның кулын күрәләр. Шуннан бу корткаякны яндыралар. Ул тере купкан, яки Мәцкәй була. Бу хәл революциядән соң була. Хәзер бу авыл юк, халык күчеп киткән.

### *ЕШ*

Ауга баргач бер аучы урманнан бер хатын ияртеп кайткан. Яши башлаганнар. Балалары булган, дүрт балалары. Ире ауга йөргән. Кунып та калгалаган. Беркөнне ауга киткәч, өйдә нәрсәдер онытканы исенә төшкән. Борылып, өенә кайткан. Аның хатыны әйткән булган:

– Аудан кайтсаң, ишекне шакымыйча кермә, – дигән. Шакымый керсә, хатыны бетен чүпләп, шуннан аш пешереп утыра. Хатыны моны күргәч:

– Ишектән кердем, тәрәзәдән чыктым, – дип, тәрәзәдән чыгып киткән. Балалары калган. Әйтәләр, аның токымы бар, диләр, чәчләре саргылт, күзләре кызгылт икән. Аучы күчеп киткәч, ул урында берәү дә яшәмәгән. Өй салып караганнар, яши алмаганнар. Ул урын әле дә утыра, буш.

### *МӘРГӘННӘР*

Күптән булган бу хәл. Дүрт мәргән шушы авылныкы ауга киткәннәр. Ауга бер атнага, ун-унбиш көнгә азык белән барганнар. Икесендә аю-мылтык булган, икесендә тиен-мылтык, ягъни кечкенә мылтык булган. Барып җиткәч, берәүләре өйдә аш әзерләгән, берәүләре йөк йөрткән. Тора-бара

азыклары беткән. Беркөнне берсе төш күрә. Бер энеләре дә төш күрә. Ул телсез була. Иртә торгач, телсез энеләре нәрсәдер аңлатырга тели, әйтә алмый. Олы Мәргән торгач, әйтә: «Бүген Көек кабырганың (эт кушаматы) артыннан калмаска кирәк, ди. Болар ауга барысы да чыга. Көек Кабырганың тавышын ике чакрымнан таныйлар. Өрә башлый. Барсалар, юан агачның тамыр астына өрә. Бу аю өне була, җир өне. Ике аюны аталар. Аткан аюлар, яраланып, өннән чыга, берсе ераккарак китә. Этләр куалар. Берсе якында гына егыла. Болар аю ата торган мылтыкларын уклап (корып) өлгерәләр. Телсез энеләре ояга башын тыгып карый. Өннең түр ягында дүрт ут күрә. Телгә килеп, ут дип кычкыра. Аюларны чыгара алмагач, этләрне чакыралар. Берәүләре Көек кабырга этне өнгә төшерә, аюларны чыгарсын, дип. Өн бик тирән була. Эт сикереп чыга алмый. Аю аны сугып чыгара. Эт үлә. Этне төшергән кеше мәргән улы була. Атасы әйтә, этнең күзе чыкканчы, синеке чыксын иде», – ди. Аюларны аталар.

* * *

Монда килгән яхшылар токымыннан Корманали дигән кеше баласына мулла яллап, белем биргән. Абушаһман исемле баласына. Баласы үскәч, Казанга «Галия» мәдрәсәсенә алып бара. Анда белеме җитәрлек булганга, аны Казанлы авылына кире кайтаралар. Ул авылына кайтып мәчет салдырган. Мәчетне эшләүче оста Сәмка (Сәмигулла) исемле була. Мәчет бик матур, биек булганга күрә, манараның аен, күз тимәсен, дип, урынына төнлә утырткан. Мәчет шулкадәр биек булган, ерактагы күлләр, авыллар күренгән. Оста үз гомерендә унике мәчет салган. Абушаһман мулла үлгәч, баласы Вәлиш мулла булган. Революциядән соң Ташкентка сөргәннәр, шунда үлгән.

*Казанлы авылында яшәүче Сәгыйдуллин Хәлим Харис улыннан язып алынды. 1949 елгы.*

## АУЧЫ ЧАҢГЫСЫ

Аучы-мәргәннәрнең чаңгысын эт өргән агачтан ясыйлар. Эткә каршы өрә ул агач. Ул агачны еллар буе эзләгәннәр. Ул агачны тапкач, аны башта бәйлиләр, югыйсә, ул кеше өстенә егыла. Балта белән чапкач, тапчыгы (йомычка) читкә очып юкка чыккан. Шул агачтан ясалган чаңгыда йөргән вакытларда, аны туктату өчен, алдына эт тиресеннән тегелгән бияләй ташлаганнар. Шуның өстенә менеп кенә туктаган. Мәргәннәр ул чаңгыда очкан кебек йөргән. Аңны (пошины) куып җиткәннәр.

* * *

Тугыз авылында Нигъмәш дигән карт булган, бичәсе Хәтирә. Әле алар сиксәненче елларда гына үлделәр. Элек кеше күлдә туенган. Картның җиде яшьлек улы була. Бервакыт улы белән күлгә китә. Юлда көймә-

не туктатып, үзе корыга чыккан. Баласы көймәдә утырып калган. Төшсә, бала көймәдә булмаган. Баланы тапмаганнар. Китап ачтырганнар муллага, мулла әйткән: «Балагыз унсигез яше тулгач кайтыр, – дигән. –

Тик кеше кыяфәтендә түгел, кош булып кайтыр. Әгәр барлык ишекләрне бикләп өлгерсәгез, балагыз кеше кыяфәтендә үзегездә калыр. Әгәр ишек-тәрәзәләрегезне ябып өлгермәсәгез, бүтән күрмәссез», – ди. Болар бу әйберне онызалар. Бәлки, ышанмаганнардыр да.

Бервакыт, җәйге эссе көндә, өйгә кош очып кергән. Өйдә очып йөри. Болар авыз ачып карап утырган, оныткаearлар. Кош очып киткән. Болар кешеләр белән сөйләшкәч кенә исләренә төшергәннәр. Мулла әйткән булган, баланы су иясе ияртеп киткән, дигән.

* * *

Кыр якта бер хатын адашкан. Кыш җитә башлагач, кышлар өчен өн ясарга теләп, агач төбен казыган. Бу аю өненә туры килгән. Аю белән кыш үткәргән. Яз көне 2 баласы туган. Бу гел үзенең туган авылын уйлап йөргән, юл эзләп тапкан да, балаларын алып качкан. Кайтып бераз торгач, аю эзләп килгән. Кайберәүләр аю кире алып киткән, тагын балалары булган, дип сөйли. Аюны этләр талап үтергән, дип сөйләүчеләр дә бар.

## *ӘЛӘМӘЦЕ (Әямәце)*

*Әләмәце* – кар-буран, көчле җил белән йөргән. Кыен (пәри туе) төсле булып, бөтерелеп йөри икән. Аңа баскыч алдына чыгарып, икмәк, башка ризыклар куя торган булганнар, куймасаң, кешеләргә зыян салган.

*Казанлы авылында яшәүче Сәгыйдуллина Нера Бәхмәт кызы. 1952 елгы.*

## *ИНӘЛЕК (Кендек әби)*

Минем Мәймүнә картинәм Убадан була. Ул 110 яшенә җитеп үлә. Ул бөтен тирә-юньгә инәлеккә йөргән. Агыт елгасы, Вагай елгасы, Иртеш елгасы ягына да, Пәри бичәсенә дә инәлек була. Төнлә белән пәринең ире килеп алып китә. Бала туа, юындырырга су булмый. Пәри хатыны: «Сөт булса ярыймы?» – дип сорый. Яраганны белгәч, ире сөт китерә, крынка белән. Баланы юындыра инәлек. Инәлек крынканың үзенеке икәнен күрә, баланы югач, сөткә үзенең көмеш йөзеген сала. Өенә кайткач, крынкасын караса, эченнән йөзеге чыга. Пәри хатынының йонын йолкып кайткан була. Пәри тәрәзәгә килеп сорый: «Бир инде, инәлек, мин сезгә зарар салмам», – ди. Ә картинәм бирмәгән. Ул инәлек булган бер хатын да үлмәгән. Пәри йонын такъясына (бүрегенә) теккән була. Картинәм әйтә иде: «Авыруның дүрт үз сәбәбе бар: салкын тисә, куркудан, кайгыдан, көченнән тыш эш эшләсә», – дип.

### ЧӘЧ ТУЕ

Татарлар, хәлле кешеләр, балага 40 көн булгач, «чәч туен» үткәргәннәр. Чәч туе – ир балага гына үткәрелгән. Беренче тапкыр чәч алгач. Балага төрле бүләкләр алып килгәннәр, ат чабышлары булган.

Минем бабай 1896-нчы елгы. Ул сөйли торган иде. Без урыслар белән дус яшәгән. Журавлево авылыннан килеп, бер урыс үзенең чәч туен үткәргән. Чәчен алдырган. Чәч туенда ат чабышлары, зур табын сый-хөрмәт булган. Бу урыс ат чабышында беренче килгән кешегә өч яшьлек тай бүләк иткән. Атның колагына алтын тәңкәләр киерткәннәр, алка итеп.

*Казанлы авылында яшәүче Шәрәфетдинова Алия Әйтмөхәммәт кызы. 1935 елгы.*

***Р.И. Вострякова, Н.С. Худякова***

## ОЛЕКМИНСКИЕ ТАТАРЫ

*На территории Олекминского района Республики Саха (Якутия) проживают представители разных народностей: русские, якуты, татары, белорусы, украинцы. Большую прослойку составляют татары и башкиры. История появления татар и башкир в Олекминском районе, их культура изучены мало. В настоящее время наблюдается тенденция возрождения некоторых традиций, обрядов через создание татарской общины. Потомки башкир и татар, проживающих в Олекминском районе, пытаются сохранить связь поколений, возродить татарские национальные обычаи, язык, праздники «Сабантуй», «Курбан-байрам», привлечь к этому детей и внуков.*

*Предпринята попытка изучить этот малоизвестный отрезок истории олекминских татар. Для этого была проведена большая исследовательская работа, которая была представлена на Поволжскую научную конференцию им. Н.И. Лобачевского в Казани и заняла первое место в секции «История и культура татарского народа». Этот проект защищала ученица МОУ СОШ № 3 Анна Ермолаева. Руководителем проекта является Р.И. Вострякова, составитель данной работы.*

*Собранный материал вызвал большой интерес, как и у старожилов-татар и башкир Олекминского района, так и у их поволжских сородичей. Прибывшее из центральных районов России татарское население оказало большое влияние на развитие культуры населения Олекминского района. Ими была открыта первая татарская школа, создан народный клуб, местным населением перенимались культура, обычаи и традиции татарского народа. Мы надеемся, что данные материалы помогут потомкам олекминских башкир и татар восстановить историю своих семей, возродить и сохранить многие национальные традиции и обычаи, и занять достойное место в культуре многонационального Олекминского района.*

*Выражаем огромную благодарность татарской общине, а также З.Я. Рыбниковой, Т.Г. Иксанову, Г.Г. и Д.Г. Акимбетовым, М.С. Мухамбаевой, Х.С. Еникееву, Р.А. Сардаровой, Г.Ш. Имашевой, семьям Тахватуллиных, Сафаргалеевых, Шафеевых. и др., предоставившим свои воспоминания, фотографии, архивы.*

## Из истории появления татар в Олекминске

*«И когда совсем готовый, населенный и просвещенный край, некогда темный, неизвестный, предстанет перед изумленным человечеством, требуя себе имени и прав, пусть тогда допрашивается история о тех, кто воздвиг это здание, и также не допытается, как не допыталась, кто поставил пирамиды в пустыне…»*

*И.А. Гончаров (о Якутии)*

Олекминский район имеет свою давнюю и славную историю. Здесь проживают представители различных национальностей. Значительную прослойку составляют татары и башкиры. Составителя заинтересовала проблема появления татар на олекминской земле, так как многие олекминчане имеют глубокие татаро-башкирские корни.

В процессе изучения архивного материала выяснилось, что существует ряд версий о появлении татар и башкир в Олекминском районе. После взятия Казани и ликвидации Казанского ханства (1552 г.) русский царь Иван IV обратился к народам, жившим на территории Казанского ханства, в том числе к башкирам, с «жалованными грамотами», в которых призывал их принять русское подданство и платить ясак Русскому государству. К 1557 г. большая часть башкир добровольно вошла в состав России. В конце XVI – начале XVII вв., после завоевания и ликвидации Сибирского ханства и присоединения Западной Сибири к России, усилился приток русских крестьян и других народов в Поволжье.

Татары принимали участие в войне со шведами (1700–1721 гг.). Среди них были прославленные воины с титулами и званиями. В боях, защищая Отчизну, они отличались бесстрашием и храбростью. Но после войны Петр I изгоняет татар с насиженных мест, заявив: «… нам татары не нужны». Татары с семьями вынуждены были покинуть родные места и поселиться на башкирских землях, взяв землю в аренду. Однако растущий гнет местных феодалов, а также захват земель русскими помещиками и злоупотребления чиновников при взимании ясака во второй половине XVII – начале XVIII вв. привели к крупным восстаниям башкирских крестьян, которые жестоко подавлялись царским правительством. Все это приводило к усилению борьбы народных масс с угнетателями. В Крестьянской войне под предводительством Емельяна Пугачева активно участвовало 85 тысяч татар и башкир. По приказу Екатерины II самые активные из них – несколько тысяч татар и башкир, вместе с семьями, были сосланы в Якутию на поселение.

После реформы 1861 г. началась русификация татар и башкир. Несогласные с насильственной христианизацией, они выражали недоволь-

ство, протест и за это царское правительство ссылало их за пределы родных мест. Таким местом для водворения ссыльных башкир и татар в Восточной Сибири Министерство внутренних дел указало генерал-губернатору Восточной Сибири выбрать Якутскую область. А в области для них предназначались три южных округа – Якутский, Олекминский и Вилюйский.

Первое упоминание о появлении татар и башкир на территории Олекминского улуса встречается в архивных документах, датированных 1816 г. [Ревизские сказки: Ф. 349. Д. 583]. Среди них татар было – 377, башкир – 35. Особенностью при подсчете численности ссыльных татар и башкир является то, что в статистических данных сосланными указывались только главы семей. Первая всеобщая перепись, проведенная в 1897 г., дает такую картину о национальном составе населения г. Олекминска. В Олекминском округе численность башкир составляла – 256, татар – 1083, в январе 1899 г. в Олекминской инородческой волости находились 248 семей ссыльных башкир и татар и 21 человек детей ссыльных башкир, всего численностью в 717 человек; в Олекминской волости 34 семьи, всего 74 человека. Однако не все башкиры и татары жили на месте причисления. Из причисленных к волостям семей 81 семья вначале 1899 г. (220 мужчин и 208 женщин, всего 428 человек) жила в городе Олекминске. Если сопоставить численность сосланных в административном порядке – 331 человек и численность семей, во главе которых стояли ссыльные (очевидно, что это не только мужчины) – 329, то всего ссыльных татар и башкир, вместе с членами семей, было 1139 человек, что превышало численность города Олекминска того времени.

## Первые годы ссылки

Жестоко расправлялось царское правительство с теми, кто протестовал против усиления эксплуатации. Их отправляли на вечное поселение в Сибирь, в далекую Якутию. Бесстрашные и лихие наездники, умельцы на все руки, они навсегда покидали родные края, не покорившись угнетателям. Следом за ними в повозках ехали их старые родители, невесты, жены и маленькие дети. Это была унылая дорога, политая потом и кровью колодников, слезами их матерей.

Что ждало их в неведомом краю, на чужбине? По указу местные власти рассылали политических переселенцев по разным уголкам Якутии, а там по разным деревням, где им предстояло начинать новую жизнь. Переезжать в другие деревни им запрещалось, как и посещать город.

Ссыльные были в основной массе крестьянами. Главным источником их существования была земля. Первое время они, не имея своей земли, нанимались на работу к зажиточным русским крестьянам. Часть татар

занималась торговлей, разведением лошадей. И только когда местное население обратилось к генерал-губернатору Восточной Сибири о выделении переселенцам земельных наделов, у них появились свои земли. На отведенных им участках они разводили огороды, занимались хлебопашеством, выращивали овощи. Земля распределялась лишь мужскому населению и обрабатывалась самыми примитивными орудиями: плугом (сабаном), сохой. Посев производился вручную из ведра или из свернутого фартука или подола рубашки. Заделка семян производилась деревянными боронами с железными зубьями. Лишь в начале XX века у зажиточных крестьян стали появляться конные сеялки. Хлеба убирали серпами, косами. До появления конных молотилок обмолот производили цепами (*чыбагач*), накатыванием телег. Хлеба сушили обычно в банях. Чистили примитивным способом: в ветреную погоду намолоченное зерно деревянной лопатой подбрасывали вверх и ветер уносил легкий сор. Иногда люди посвистывали, считалось, что свистом призывается ветер. Позднее появились висячие на треноге большие решета. Диаметр обруча такого сита был более метра. С помощью таких орудий просеивали хлеба и отделяли зерно от сорных примесей. Чуть позже стали появляться в крепких семьях веялки, жатвенные машины. Излишки хлеба зимой обозами вывозили в Алдан, Сунтары, Якутск и другие населенные пункты, продавали или обменивали на продукты питания, одежду, различную утварь, необходимую в хозяйстве.

Ссыльные татары неоднократно подавали прошения в Олекминское окружное полицейское управление, а те писали Иркутскому губернатору, о выделении земель и о причислении их к крестьянам, о чем свидетельствует архивный документ, письмо, подписанное Тахватуллиным Файзуллой и Иксановым (имя не разборчиво).

В 1894 г. татары и башкиры узнали о манифесте его императорского величества, самодержца Всероссийского от 14 ноября 1894 г. «О помиловании». Появилась надежда вернуться на родину, но это было не просто, начиналась длительная переписка, где необходимы были сведения об образе жизни, благонадежности, требовалось много других документов, ходатайств, справок. Прошения уходили вначале в Якутск, за 600 километров, на лошадях зимой, а летом на лодках или пароходе, а затем из Якутска за тысячи километров этими же видами транспорта до Петербурга и обратно. Не многие смогли дождаться положительного ответа. Зачастую были отказы. Согласно архивным документам, почему-то отказывали конокрадам. А почти все сосланные, несмотря на происхождение, причислялись к конокрадам. Было дано разрешение на выезд только Шакирьяну Сайфутдинову. Причем выезд осуществлялся

за счет государственной казны (имеется документ с надписью с просьбой о визе).

Кеше хәсрәтсез яшәми шул. Гадилә абыстай 1919-нчы елда һич көтмәгәндә вафат булгач, ул Чирмешән районы Әмир авылыннан Зыя мулла кызы Хәдичә белән никахлаша. 1921-нче елда уллары Әхмәтнәҗип туа. Коммунистик инкыйлабның ачы җилләре Кыязлыга да килеп җитә. Мәчеткә йөрүчеләрне көн саен куркытып тордылар. Кешеләр мәдрәсәләргә йөрмәс булдылар. Гарәпчә укырга-язарга баручыларның кулларына богау салып урманга алып китәләр, тиздән элекеге заманнардагы кебек муенга тәре тагып урыс әлифбасы белән генә укытачаклар икән, дигән тагын әллә нинди имеш-мимешләр халыкның җан тынычлыгын дәһшәтле ялкын кебек көйдерә. Төннәрен коралланган 2–3 кешелек «жуликлар шайкасы» йортларга бәреп керә. Сораганнарын бирмәсәң, күкрәккә көпшә төзиләр, атып үтерү белән яныйлар. Бандитлар өйнең астын-өскә әйләндереп акча, алтын-көмеш эзлиләр. Табалмасалар, сүгенә-сүгенә, йодрыкларын күтәреп кеше кыйныйлар. Гатаулла хәзрәткә дә берничә тапкыр керделәр. Кечкенә Әхмәтнәҗип каты тавышлардан сискәнеп уянып китеп, куркып, әнисенә

сыенып елап җибәрде. Бала тавышыннан соң, төнге кунаклар озак торрмады, нәрсәдер күтәреп, канәгатьләнеп, чыгып киттеләр. Авыл Советында да кулак хәзрәтләрнең шикаяте игътибарсыз калды. Җирле Советлар бу хакта яхшы белсә дә, белмәмешкә-күрмәмешкә салышты.

– Нигә сез талауга юл куясыз, Ленин вәгъдә иткән тәртип, яңа хөррият шулмыни? – дигән сорауга аларның җавабы әзер иде.

– Йортларыгызга беркемне дә кертмәгез, без сезнең малны сакларга ялчы түгел, – дип җавап бирделәр Советта. Жуликлар тынычлангач, Мәскәүдә утырган ата коммунистлар кушуы буенча, Совет түрәләре үзләре талауга күчте. Хәерче илгә – мал, заводларга эшче коллар кирәк иде. Барлык кулак байларны, муллаларны өйләреннән чыгарып, буш калган йортларга ярлы гаиләләрне урнаштырдылар, кайберләрен сүтеп, амбарлар, терлек абзарлары төзеделәр. Котыртылган, акылы томаланган комсомолчы яшьләр, гармунда такмак уйнап, кызык ясап, урам буйлап җырлап йөриләр:

Югары очта – ак балчык,
Ак балчыктан атлап чык.
Гафият байның түшәгендә
Аунап-аунап ят, карчык.

Гатаулла хәзрәт күңеле белән сизеп торды. Кыязлыда аңа көн булмаячак. Шикләнүләргә урын калмады. 1931-нче елның көзендә иртә таңнан өйгә кораллы кешеләр кереп тулды.

– Мулла абзый, юлга әзерлән, сез авылдан сөреләсез!

– Кайда алып барасыз соң? – дип сорады Гатаулла хәзрәт, бернигә гаҗәпләнмичә.– Без приказ башкаручылар гына, берни белмибез, тизрәк җыенсагыз, үзегезгә әйбәт булыр, – диде командирлары караңгы йөз белән. Хәдичә абыстай үксеп елап җибәрде. Хәзрәт аны юатырга сүз табалмады, тамагына ачы төер утырды. Коралды кешеләрнең берсе, гаиләне кызганып, әйтеп куйды: «Елама абыстай, илдә чыпчык үлми ул, хәзрәтнең барачак урыны, бәлки, начар да булмас әле». Инде Әхмәтнәҗип тә киенергә өлгергән, үзеннән дә зур киез итекләргә аяк тыгасы гына калган. Әти-әнисеннән кая барабыз, дип күпме генә сораса да, кара кайгыда янган ата-ана малайның сорауын ишетмәде. Шулай да Әхмәтнәҗип, аркаларына мылтык аскан абзыйларның кунакка алып бармаганлыкларын яхшы аңлый иде. Юлга ашык-пошык җыелган өс-баш киемнәрен, юрган-мендәрләрне, капчык белән ризыкны арбага чыгарып салдылар. Командир ишекне күгәргән олы бер йозакка бикләп, ачкычын кесәсенә салып куйды. Җигүле атлар авыл Советы каршындагы мәйданга атлады. Монда мәхшәр иде. Мәйдан халык белән кайнап тора, бик күп атлылар, сакчылар, авыл кешеләре җыелган.

Бөтен тирә-як авылларның «кулак»ларын бирегә мәҗбүриләп китергәннәр. Хатын-кыз, бала-чаганың күз яшьләре, авыл агайларының рәнҗүле карлыккан тавышлары, кемнәрнеңдер кычкырып дога кылулары, их, Аллакаем, тәмуг утына ташламасана, диюләре, кычкырып каргаулар Гатаулла хәзрәтнең бәгырьләрен өзгәләде. Муллаларны озатырга бөтен авыл чыкты. Халыкның хәзрәтне җибәрәсе килми иде. Хушлашырга килгән шәкертләрен дә янына җибәрмәделәр сакчылар. Мылтыктан берничә тапкыр һавага атып алдылар. Командир, каушап, арлы-бирле йөгереп тәмам хәлдән тайды, тирләп пеште. Фәлән авылдагы кебек халык һөҗүм итмәсен, дип курка иде ул. Халык аны-моны абайлап берәр төрле хәйләгә килгәнче дип, атлы арбаларны озын бер чылбыр кебек хасил итеп, сафка тезеп, Утыз Имән ягына (Чирмешән районы Яңа Кади авылы) кузгалып киттеләр. Арбада Кыязлы ягына борылып карап баручы хәзрәтнең күзләреннән чыккан яшь бөртекләрен салкын җил киптереп барды. Авылда хатыны Хәдичә яшь балалары Фазыл (1910), Камил (1927), Халисә (1930) белән елап калды. Ул, пышылдап: «Йә раббым, заманны әгъмале кабихадән сакла, төрки татарны диннән мәхрүм итеп инкыйразга дучар итмә, синең мәрхәмәтеңә ирешү өчен әзме бабаларыбыз дин юлында туфрак булды»,–диде кат-кат Ходайга ялварып.

Сакчылар да, арбадагылар да озак вакыт берни дәшми барды. Кичкә урман буена туктап, тамак ялгап, хәл алып, атларны ашатып ут ягып кундылар. Икенче көнне Кармышка килеп җитеп, шунда туктап торганнан соң Шушма елгасы буендагы Әшәлче (Яшәүче) поселогына килеп җиттеләр. Барысын да вакытлыча аерым йортларга тараталар. Соңыннан алар шундагы Кирлемар тау башында яшәргә тиеш булалар.

Менә зәһәр суыклар башланып кыш җитте. Күп итеп кар яуды. Беркөнне мәхбүсләрне Себергә җибәрәләр, дигән хәбәр тагын күңелләрне борчуга салды. Яңалыкны Кыязлыда да ишеткәннәр. Авылдашлары хәзрәтне бәладщн йолып калу чарасын эзли. Ничек кенә үтенеп сорасалар да, авыл Советы мулланы яклап белешмә бирми. Нәфис язу-сызу остасы, тәвәккәл холыклы Әхмәт Сәйфуллин әмәлен таба, Совет исеменнән үзе белешмә яза. Вәлиәхмәт Вафиннар ике ат җигеп, шул белешмәне тотып Әшәлчегә киләләр. Ләкин поселоктан беркемне дә чыгармыйлар, белешмәнең дә файдасы юк. Инде нишләргә? Кыюлыгың җитсә, чарасы табыла икән ул. Төнлә белән чана төбенә яткырып, өсләренә печән каплап, хәзрәтнең гаиләсен шыпырт кына хәвеф-хәтәрсез Әшәлчедән алып китәләр. Бу 1932-нче елның февраль ае. Бәлки шул сәбәпледер, ул Архангельск өлкәсенә сөрелгән, дип документларга теркәлеп калган. Хәзрәтнең кинәт кенә ярты юлдан әйләнеп кайтуын авыл Советы ошатмады. Улы этисе өчен җавап бирми, дисәләр дә, Әхмәтнәҗип тә репрессия ел-

ларының кимсетелү көннәрен үз йөрәге аша кичерде. Онытылып дәрес тыңлаган вакытта Советтан тикшерү белән бер бәндә килеп керде. Малайны күрүгә акырырга тотынды: «Нишләп утырасың Совет мәктәбендә, сыптырт моннан», – дип, партага ябышкан Әхмәтнәҗипне кулыннан өстери башлады. Укытучы апасы арага төшмәсә, малайны нәрсә эшләткән булыр иде Совет вәкиле, билгесез. Укытучының: «Нигә сабыйны җәберлисең» – дигән сүзләре аны тагын да үртәде. «Ә-ә-ә, әле син кулакларны, контраларны яклыйсыңмы, барыгызны да иртәгә үк авылдан сөрдерәм», – дип ачуланып, янап чыгып китте вәкил. Ул мәктәпкә килсә, Әхмәтнәҗип парта астына төшеп утыра торган булды.

Гатаулла мулланы тагын Советка чакырдылар. «Мәчетне бирәсеңме, юкмы, әллә Себер китәсеңме?» – диделәр. «Мин сезгә ничек итеп мәчет бирим, ди, ул минем шәхси малым түгел ич, әнә халыктан сорагыз».

Кич белән мәчеттә мәхәллә җыены уза. Анда район Советы җитәкчеләре дә катнаша. Беренче сүзне хәзрәт башлый: «Җәмәгать, кардәшләрем, сезгә мөрәҗәгать итәм, миңа үз ихтыярым беләм мәчетне бирергә кушалар. Гыйбадәтханә – Аллага табыну йорты, минем кулда түгел ул. Мәхәллә мөселманнары ничек хәл итсә, шулай булсын». Бигрәк тә картлар мәчетне Советка бирүгә каршы чыга. Партия вәкилләре теләкләренә ирешә алмауны Гатаулладан күрәләр. Димәк, гаеп тагарга сәбәп бар, мәхәлләне Советка каршы ул котырта. Янә кулга алынгач, аны Чистай төрмәсеннән Казанга озаталар. Зинданда акылдан шашмас өчен, ул гел догаларын укып ята. Азат итүләренә дә өметләре өзелә. Көн саен мәхбүсләрне иртәнге якта алып китә торалар, берсен дә кире китермиләр. Димәк, бу кешеләр инде атылган. Менә берзаман кораллы сакчылар Гатаулла мулланы да бүлмәсеннән этеп-төртеп алып чыктылар. Атарга алып киттеләр, авылда балаларымны нишләтерләр, Аллакаем, каберемә килеп дога кылучы да булмас инде, дип уйлап барды ул караңгы коридорларда. Җылыйсы килде, әмма күзләренә яшь килмәде, бәгырьләре таш булып катты. Сталинның зур портреты эленеп торган бүлмәгә алып керделәр. Монысы подвал түгел икән, баштан «приговор» укыйлардыр, дип уйлады Гатаулла хәзрәт. Аның каршында таныш йөз, ул кайчандыр аклардан коткарып калган Григорий басып тора. Гатаулла хәзрәт шул кеше ярдәме белән Кыязлыга кайта алды. Аңа 1936-нчы елда Уфа диния нәзарәтеннән имамлыкны дәвам итәргә дигән указ килә. Бу елларда рәсми төстә бөтен авылларда да дин эшләре туктатылган була инде. Әхмәтнәҗип Үзбәкстанга китеп педагогия техникумында укый, укытучы, мәктәп директоры булып эшли. Ватан сугышында башыннан ахырына кадәр катнышып, Кыязлыга кайтып балалар укыта. Аңа монда адым саен аяк чалып, мулла малае икәнен исенә төшереп мәсхәрәләп торалар. Әхмәтнәҗип әтисен алып Үзбәкстанга чыгып китә. Үз авылына

сыймаган Гатаулла хәзрәт бу дөньяның вәхшилегеннән, денсез усал телләрдән котылып чит-ят җирдә, Кыязлыдан бик ерактагы Ургут шәһәрендә соңгы сыеныр урын табып, 1949-нчы елда вафат була. Әхмәтнәҗип исә 50 елдан артык гомерен Үзбәкстанда балалар укытуга багышлый. СССР күләмендә танылган мәктәп музее оештырып, «Жигули» автомашинасы белән бүләкләнә. Ул Үзбәкстанның атказанган укытучысы. 2006-нчы елда Казанда мәрхүм булды. Хакимиятнең генә түгел, үз янәшәбездәге маңкорт татарларның чамадан тыш куштанланып, власть каршында изге булып кыланулары, аннан бер кимерерлек сөяк, мәһәр өмет итеп яшәүне өстен күрүләре аркасында да күп милләттәшләребез чит кавемгә хезмәт итәргә дучар ителде. Әлеге вазгыять бүген дә дәвам итә (мәгълүматлар, язмалар Иске Кыязлы авылы туган якны өйрәнү музее җитәкчесе, атказанган мөгаллим Әхмәтзыя Моратшиннан алынды һәм эшкәртелде, төзәтелде. 2005 ел).

«...Әле аннан да куркынычы була бу төбәкләрдә. Әшәлче авылы янындагы тауга куа торган булганнар сөргенгә озатыр алдыннан сәяси тоткыннарны. 30–35 градуслы эсседә бер тамчы суга тилмереп, янып үлә кайбер бәхетсезләре. Тау астыннан чишмә ага, ә монда – тәмуг. Бу газапларга чыдый алмый акылдан язучылар да була. Тугызынчы дистәне тутырып килгән Саҗидә апа сөйләгәне хәтердә. Югары Кәминкәдән Миңнеәхмәт дигән сукыр карт кереп йөргән аларга. Кияве белән кызын, улларын да уяттырмыйча, җәһәннәм тавына алып менеп киткәннәр. Шул китүдән ник бер хәбәр булсын. Яшь хәзрәт тә (Лашман авылы мулласы Касыйм) качкан җиреннән чыгарга мәҗбүр була. Кадерлеләренә Әшәлче михнәтен күрсәтәсе килмәгәндер, әлбәттә». (Мөхлисә Нәгыймова, «Лашман түгелме» дигән язма, «Әлмәт таңнары» газетасы. 1998 ел, 9 июль).

*Безнең искәрмә: Бу язмада телгә алынган Миңнеәхмәт бабайның кызы Закирә абыстай (1888) булырга мөмкин. Ул – Югары Кәминкә мәчетләренең азанчысы Гыйләҗ хәзрәт Мөхетдинов (1881) җәмәгате. Ирле-хатынлы Мөхетдиновларны авыл советы рәисенең йортын яндыруда гаепләгәннәр. Алар да бер уллары белән Әшәлченең зәхмәтле тавына вакытлыча куылган булып чыга. Гаиләнең бар мөлкәтен совет талап ала. Хәзрәтне 10 елга, абыстайны 5 елга хөкем итәләр. Гыйләҗ 1934-нче елда төрмәдән азат ителгән. Аларның икесен дә 1937-нче елда, колхозга каршы эшчәнлекләре һәм дини өндәмәләре өчен янә кулга алып, Бөгелмә шәһәрендә атып үтергәннәр. Касыйм хәзрәт Исхаковка килгәндә, инде укучы беләдер, ул татарның мәшһүр мәгърифәтчеләре Һади Атласи, Кәбир һәм Фазыл Туйкиннар белән бергә, барысы 9 кеше, Казанда ерткычларча атып үтерелгәннәр.*

Мәсләхетдин кызы Сания апа (1937) сөйләгәнннәрдән: «Иске Ибрайда яшәгән бабам Мотыйгулланың (1876) чәчү җирләре һәм чәчү корал-

лары, җилгәрчеге, терлекләре, умарталары булган. Җәмәгате Фатыйма (1876) белән алты бала тәрбияләгәннәр. 1930-нчы елда Мотыйгулланы, улы Минзакирны (1907) Советка каршылык күрсәтүчеләр дип кулга алып, Чистай төрмәсенә утырталар. Бар мөлкәтләре колхоз милкенә күчә. Төрмәдә Мотыйгулла байның бер яхшы танышы күреп ярдәм итә. Бәладән котылып, Түбән Новгород өлкәсе Горбатовка авылының Пролетарск поселогына килеп гади игенчеләр булып урнашалар. Йорт салып керәләр. Авылда калган Зәйнәп исемле кызын, сөргеннән коткару өчен, чирле, фәкыйрь бер кешегә кияүгә биргәннәр. Уллары Миннегата (1918) белән Миңнеәхмәт детдомга бирелгән булырга тиешләр. Әнием Һаҗәр (1916), абыйсы Харис (1909) Сәйфуллиннарны Әшәлче поселогындагы Кирлемар тауына песи балаларын адаштырган кебек китереп ташлыйлар. Авылдашлар балаларны үз канатлары астына алып калырга тырышса да, аларны беркем тыңлап тормаган. Шул тауда бер еллап салкын землянкада яшәгәннән соң, аларны Бөгелмә тимер юлы аша туп-туры Магнитогорскига озатканнар. Юлда тәүлеккә бер тапкыр гына тышка чыгаралар. Ерак китеп тә булмый, күзләрен тырсайтып сиңа мылтык төбәп торалар. Качарга йөрәкләре җитүчеләрне утлы кургаш тота. Тын җитмәүдән, кайберәүләр юлда ук җан тәслим кылган. Мәрхүмнәрнең гәүдәләрен кайда нинди чокыр бар, шунда ташлап калдырганнар. Соңыннан күмелде микән ул бичаралар? Магниткада ике бертуганны гомуми баракка билгелиләр. Төннәрен бик салкын, бараклар аша җил үтә. Барысы өчен дә бер аш пешерү урыны. Баштан аларны беркем дә яратмый, шул ук коллар аларны төрлечә мәсхәрә итәләр. Әнинең пешерергә куйган әйберләрен мичтән алып ыргыталар. Олы яшьтәге апалар, ятимнәрне яклап, мәрхәмәтсезләрне үз урынына куя. Харис, лычма суга батып, көн саен урман кисәргә йөри. Әни баракка яланаяк су ташый, абыйсының юеш киемнәрен аркасы белән ятып киптерә, иртәгә тагын аңа ачлы-туклы килеш урман кисәргә барасы бит.

Мотыйгулла бай балаларының Магнитогорскида җәфалануларын кемнәндер ишетеп белгән. Минзакир абыйлары шунда барып аларны Пролетарскига алып кайта. Әниебез Иске Ибрайныкы Мәсләхетдин дигән кешегә кияүгә чыккан. Ул сугыштан кайтмаган. Дүрт балалы әниебез сугыш елларында Новгород тирәсендәге госпитальләрдә эшләгән. Иренең сеңлесенең ятим калган кызы Рәхимәне, иренең сугыштан гарипләнеп кайткан энесе Фәссахетдинне тәрбияли. Гаиләне туйдыру өчен вактөяк, чүпрәк-чапрак сатканы өчен төрмәгә эләгә. Мотыйгулла бабай һәм Харис абый туган илдән еракта Пролетарск мөселман зиратында җирләнгәннәр. 1955-нче елда әни һәм мин, Минзакир абый гаиләсе белән яңа төзелүче Әлмәт шәһәренә күчеп кайттык. Әнием Кирлемар сөргененнән

башланган дөнья газабын гомеренең соңгы көннәренә кадәр йөрәгендә саклап, 2001-нче елда вафат булды» (2006 ел).

Кармыш имамы Габдрахман Бикколовның җәмәгате Мөгаллимә абыстайның сөргеннән авылга язган хаты. Кайдан һәм кайсы вакытта язылганын ачыклап булмады. Хат Әшәлче поселогы имамы Нурулла абзыйда сакланган иде: «Мөхтәрәм Харрас агай һәм дә Мөхтәрәмә кызым, Бибигайшә сеңел! Безне искә алган Кармыш кардәшләргә һәркаюсына сагынычлы сәлам һәм хәер-дога үтенеп калабыз, һәм дә Шиграләдән, Сәүбәннәрдән һәм барча күргән белгәннәрдән сәлам. Үзебез шулай ята-тора булса да тәндә җан яшәтеп ятабыз, әлһәмделлиләһ. Үзегезнең җибәрелмеш мөбарәк хатыгызны 27 апрельдә алдык, ләкин гафу итегез, элек җибәргән хатларыгызны да алдык та, җавап язалмадык. Гафу итәрлек сәбәпләре булды. Менә мин сезгә башыннан сөйләп бирим. Мин эштән кайтканда Шигралә стансада Мәскәүдән киләсе профессорны көтеп ята иде. Чөнки өч операция берьюлы буласы иде. Иң авыры – уникеле эчәктә язва һәм үт куыгы ташланган, өченчесе – эчәкләрендә дә табалар. Шигралә ничек уздырыр икән, дип торганда уйламаган зур кайгы килеп чыкты. Ул да булса киявебез Илсур эшләгән җирендә кайнап торган тозлы дарулы базга килеп төшкән. Төнге эштә актык сәгатьтә. Өч метрлы чаннан Аллаһының ярдәме аркасында үзе чыга алган, 87 процент пешкән. Ике ай һушсыз булып, үлек кебек ятты. Врачлар күңелегезгә авыр алмагыз, торса торыр 7–8 көн, барыбер үлә, диделәр. Аллаһы Тәгалә ташка җан кушса да кадир, диләр, дөрес тә шулай булып чыкты. Өч ай больниста ятып чыкты, дүртенче ай өйдә ята. Хәзер йөри башлады. Бер елга икенче группа инвалидка чыгардылар. Шиграләгә операция ясауны киләчәккә калдырдылар.

Октябрь бәйрәмендә Сафуат, Мирфатыйх, Әхмәт кияү белән Шәфкать хәл белергә килеп киттеләр. Алардан соң Акмулладан (элекеге Целиноград, бүген Казакъстан башкаласы Астана – автор искәрмәсе) Сәгыйть каенатасы кирәк нәрсәләрне алып, хәл белергә килгән иде. Рузаның уннарында Шәрига килеп бәйрәм үткәреп китте. Бөтен агай-эне гөр купты. Кайсы телефонга чакыра, сораша, кайсы телеграмм биреп хәл-әхвәл сораша. Үзем дә чирлим, давлением 200гә җитә. Бик куркам, кеше кулына калдырмасын инде бер Аллаһ. Каршы хатыгызны көтәбез, хат артыннан үзегезне дә көтәбез. Мондагы агай-энеләр дә, якын күргән күршеләребез дә, барысы да көтеп калалар (2006 ел)».

*Безнең искәрмә: Хат репрессия елларыннан шактый вакытлар узганга охшый. Хат кыскартып бирелде. Мулланың Сафуат исемле кызы соңгы көннәрен Бөгелмә шәһәрендә яшәп, Кармыш ягына борылып та карамаган, дип ишеткәнебез бар.*

Сәрвәр хәзрәт Хәйретдинов кызы Мәүфәкә апа (1920–2012) сөйләгәннәрдән: «Әтием Сәрвәретдин хәзрәт 1871 елда Бәркәтә авылында туган. Бик яшли әти-әнисез кала. Аның чаялыгын, зиһенле бала булуын ил агайлары да күреп ала. Анда сугылып, монда төртелеп йөргәч, кардәшләре гаиләсенә сыймагач, ятим малай мәдрәсәдә йомышчы хезмәтен үти. Самовар куя, утын кертә, кая кушсалар шунда йөгерә, кыскасы, мәдрәсә аның үз өенә әйләнә, ул шунда яши, эшли һәм укый. Аны авыл муллары бик ярата. Диннең бөтен кагыйдәләрен дә яттан белә, һәр җомгада аннан азан әйттерәләр, егетнең яшь мулла дигән даны тарала. Сәрвәрне авылның хасталыктан интеккән бер бае акча түләп үзе урынына Мәккәгә хаҗга барырга үгетли. Егет, шатланып, риза була. Мөхәммәт пәйгамбәр яшәгән ерак җирләрне күрү аның күптәнге хыялы бит. Ул гарәп иленнән икенче төрле, җитди фикерле хаҗи булып кайта. Яшь булса да олыларча сөйләшә, үзен чын дин әһеле итеп тота. Гыйлемен артыру өчен мәдрәсәләрдә укый, гарәпчә аралашырга өйрәнә. Барлыгы өч тапкыр хаҗ кыла. Бер баруында аны гарәп агае оста мөгаллим икәнен күреп ала да, улын гыйлемгә өйрәтүне сорый – бер еллап гарәп балаларын укытып йөри. Өченче баруында күрше авылдан Түбән Кәминкә мулласы Әгъзаметдинне (Кармыш авылында туган) очратып дуслашып китәләр. Хәйләкәр Әгъзаметдин туган илгә кайткач та гади булмаган бу егетне күз уңыннан ычкындырмый. Үзенең 16 яшьлек Җүввәйрә (Җәүһәрия) исемле акыллы кызын Сәрвәргә кияүгә бирә. Әтиебез Иске Кади авылына указлы мулла булып килә. Яшь гаиләдә бер-бер артлы Хаҗимәхмүт, Мәүфәкә, Оркыя, Вазыйх, Вагиз исемле балалар туа. Әти ир балаларны, әнием кыз балаларны укыта. Гел дин генә дә өйрәнеп ятмаганнар. Казан ханлыгының бөек шагыйре Мөхәммәдьяр шигырьләрен укыганнар, ятлаганнар, хәтта мөнәҗәт итеп дини мәҗлесләрдә башкарганнар. Казан университеты галиме, заманында гарәп илләренең берсендә совет вәкиллегендә эшләгән гарәп филологы, тәрҗемәче Җәмил Габделхак улы Зәйнуллинның әти-әнисе дә алардан өйрәнә. Ә алар Җәмилдә гарәп теленә, гарәп культурасына мәхәббәт тәрбияли. Әнисе Магбәдәр апа – әнинең иң яраткан шәкерте булган. Магбәдәр апа балаларына Җүввәйрә абыстайның хәлен белеп торыгыз, дип васыять әйтеп калдырган.



Сәрвәр хәзрәт.

Сәрвәр хәзрәтне 1927-нче елдан ук эзәрлекли башлыйлар. 1931-нче елда Коръән укыган җиреннән кулга алынып, биш ел утырып, амнистиягә эләгә. Күрәмсең, авылга кайтырга рөхсәт булмагандыр, ул Мәләкәс (Дмитровград) шәһәрендә эшче булып көн күрә. 1937-нче елларда атып үтерелергә хөкем ителгән.

Әтинең гаиләсен гыйнвар аеның бер көнендә Әшәлче поселогы янындагы котсыз Кирлемар тавына сак астында атларга төяп куып, тибеп китерделәр. Бу кешеләргә Аллаһының каһәре төшсен! Гаилә кар өстендә кыш чыгып булмасын аңлый, әлбәттә. Янәшәдәге бер авылдагы кардәшләргә вакытлыча килеп сыендык. Моның өчен коммунистлар һәрдаим кисәтеп, куркытып тора. Кирлемар тавына Чәтрәннән (Яңа Ибрай авылы) Әхмәтвәли хәзрәт һәм аның җәмәгате Маһруй абыстай да сөрелгән. Менә шуларга авылдашлары, кыюлык күрсәтеп, мунча сыман өй, гади бер куш салып куйганнар. Алар халык таләбе белән туган авылларына кайтып киттеләр. Рәхмәт төшкереләре, шул өйгә әнине, мине, Оркыя туганымны кертеп калдырдылар. Шунда ике еллап яшәдек. Ир туганнарым бу вәхшилектән Кытай янындагы Чита якларына качып киттеләр. Бөтен булган нәрсәләребезне ризыкка алыштырып бетердек. Әнием, соңгы истәлеген, ире хаждан алып кайткан муенсасын икмәккә алыштырды. Оркыя туганым да бик күп михнәтләр кичерде. Аны кулга алган булып НКВД начальнигы Чирмешәнгә, үз йортына, хатыны өстенә алып кайта. Ул аннан кача, хурлыктан батып үлмәкче була. Оркыяны, тимәсеннәр дип, игелекле кешеләр, туган-тумача озак вакытлар үзләрендә яшереп тордылар. Соңыннан гомере буе колхозда бил бөкте. Аның улы, Сәрвәр хәзрәт оныгы Җәүдәт Фәтхелислам улы Иктисамов, озак еллар Әлмәт районы Габдрахман авылының мәдәният йортын җитәкләде, Атказанган мәдәният хезмәткәре. Бүген Ислам дине юлында.

Кыен булса да, Кирлемар тавыннан Кармышка Албут исемле этем белән укырга йөрдем. Ул елларда бүреләр бик әрсезләр, тәрәзә төбеннән үтеп китәләр иде. Алар күздән югалгач кына базга салынган бәрәңгене барып ала идек. Күңелсез хәлләр ишетелмәде, бүреләр безгә тимиләр иде, Ходайның рәхмәте. Безнең кулаклар поселогында Чәтерәннән Мәгъсүм хәзрәт яшәгәнлеген хәтерлим. «Алатор» кушаматлы гаилә яшәгәнлеген беләм. (Кармыштан Госман Мижнегуловның кушаматы «алатор» булган). Монда конвой торганын белмим. Күрше авыллардагы татарлар булышмаса, без монда үлгән булыр идек. Әлбәттә, бу ярдәм властька күрсәтелми иде. Аларның нәселләренә изгелекләре өчен Аллаһы Тәгалә рәхмәтләр җиткерсә иде.

Рөхсәт ителгәч, без Иске Кадига кайттык. Монда да «мулла кызы» дип адым саен кычкырып торалар. Түзәр хәл булмаганга, без Иркутск якларына чыгып киттек. Оркыя туган авылга әйләнеп кайтты. Тәкъдирдә шулай

язылган булгандыр. Мин Совет Армиясе офицеры, хәрби төзүче, украин кешесе, Полтава өлкәсе Бабайковка авылында туган Хурдей Афанасийга (1915–1962) кияүгә чыктым. Сугыш вакытында Чита шәһәрендә яшәдек. Читадагы татар мәчетенә карап, әтиемне сагынып, елый идем. Бернишләп тә булмый шул, безнең язмышларны коммунистлар үзләренчә хәл итте, ата-баба җирен алар туздырып ташлады. Авыр сугыш елларында ашханәдә мөдир булып эшләдем. Без 50 градус салкында зур мичләрне ягып, бозга каткан ит-балыкларны эретеп, солдатларга аш пешердек. Мондагы салкыннарга Әшәлче поселкасында туңуларым да өстәлде, гомерем буе ревматизм җәфалады. Вәгыйзь туганым сугыштан кайталмады. Хаҗимәхмүт (тимер юл мастеры) Халхин Голда японнар белән сугышта катнашты. Вазыйх тимер юллар төзәтеп йөрде. Үзебезне яратмасалар да, без, Сәрвәр мулла балалары, бу ил өчен барысын да эшләдек...



Мәүфәка апа, кызы Рәйсә, ире Афанасий Хурдей. 1960 ел.

Ирем фамилиясендә йөрсәм дә, мине бик тиз эзләп таптылар, ирем эштә чакта килеп алып та киттеләр. Ярый әле, йөк ташучы берәү күреп калып, иремә әйткән, ул килеп җитте. Мулла кызы булуымны, совет дошманы булган әтиемнең кулга алынуын кисәтә-кисәтә иремә аңлаттылар. Ирем яхшы аңлады. Минем хакта чит илгә чыгу өчен юллар бикләнүен дә, башкасын да яхшы төшенде. Ирем чын кеше иде. Замана авырлыгы аны өркетмәде, вакытлы тормышның арзан матурлыгына да алданмады, гаилә бәхетен дә сатмады ул. Мондый сорау алулар Сталин үлгәнчегә кадәр дәвам итте, һәрдаим нәрсәдер тикшерделәр. «Чит илдә туганнарыгыз бармы, алар белән нинди элемтә тотасың»,–дип, теңкәләргә тиеп бетәләр иде. «Юк»,–дип кырт кисә идем. Бу чын күңелдән бирелгән җавап иде. Еллар узгач кына

белдем. Әнинең әтисе Түбән Кәминкә мулласы Әгъзаметдин хаҗи – күршедәге Кармыш авылы кешесе. Аның абыйсы Кыяметдин революциягә кадәр егерме еллар элек үк Төркиягә китеп урнашкан икән.

Без озак еллар Грузиядә яшәдек. Ирем юлда фаҗигале төстә һәлак булды. Бүген Казанда яшим. Кызым Рәйсә Сәгиева (1939–2009) А. С. Пушкин исемендәге Тбилиси педагогика институтын тәмамлап, балаларга 45 ел математика укытты. Оныгым Розалия Мәскәүдә автомобиль юллары институтын һәм чит телләр институтын бетереп, аспирантурада укып йөри.

Мин 2007 елда Кирлемар тавы белән тагын бер кат очраштым. Монысы инде соңгы тапкыр. Ярты гасыр вакыт узса да, хәтердән бернәрсә дә сызылмаган, йөрәк яралары да төзәлмәгән. Бер кат авылларыннан куылып Кирлемар тавында мунча-өйләр ясап урнашкан кешеләрне, икенче тапкыр ташказаннары буйлап яңадан сөргеннәргә алып киттеләр. Барысы да күз алдында. Монда хәзер ул вакыйгаларның эзе дә калмаган. Бирегә Истәлек билгесе куйсагыз иде (2009 ел)».

«Хөрмәтле Дамир әфәнде! Сезгә Читадан хат язучы Тәнзилә Вазыйх кызы Коренева (1941). Бабаебыз Сәрвәр Хәйретдиновны искә төшерүгез өчен зур рәхмәт. Әтием Вазыйх (1916–1997) Забайкальск тимер юлының Яблоновая станциясендә мастер булып эшләде. Ул Әшәлче кулак поселогы турында сөйләргә яратмый иде. Әниебез Җәләтдинова Хәлимә Мәсләх кызы. Үзем – медицина хезмәткәре, 47 ел кешеләр дәваладым, әле һаман да эшлим. Ике улым да – табиблар. Энем Мансур (1952) – тимер юл инженеры, хәзер инвалидлыкта. Улы белән кызы – юристлар. Кыз туганым Әлфия (1944) – педагог, Яблоноваяда мәктәп директоры булып эшләде. Улы вакытсыз һәлак булды (2009 ел)».

«Исәнмесез Дамир! Мин Сәрвәр мулланың улы Хаҗимәхмүтнең (1909) кызы Рәкыйбә Хафазова (1944) Чита шәһәрендә туганмын. Әнием Сәлимә (1913) исемле иде. Кадрлар бүлегендә эшләп, пенсиягә чыктым. Гаиләдә өч бала үстек. Хәзер инде алардан үзем генә калдым, ирем Алмаз шулай ук мәрхүм. Әти авырлыклар күргән, туган җиреннән яшьли сөрелгән, сугыш һәм хезмәт ветераны. Безне ерак Татарстанда искә алуыгыз өчен рәхмәт. Улым, киленем һәм яраткан оныгым бар (2009 ел)».

«Хөрмәтле Дамир! Бу хатны Казаннан Асия апа яза. Минем турында сезгә Мәүфәка апа сөйләгәндер, дип беләм. Мин дә – Сәрвәретдин оныгы. Әтием Вәгыйзь (1913) туганнары белән Кармыш авылы янындагы Кирлемар тавына сөрелгәннәр. Әтием 1940-нчы елда Читадан кайтып, Иске Кади авылының Тукай поселогыннан әнием Зәйтүнәгә өйләнеп китә. Икесе дә тимер юлда эшлиләр. Апам Гөлсирә туа. Әти бик тырыш кеше булган. Аның хезмәт кенәгәсен ачып карау да җитә. Эш нормасын Стахановлар кебек 200 процентка арттырып үтәгәне өчен костюм белән бүләкләнә, икенче юлы

50 сум премия бирәләр. Болар барысы да бу илнең никадәр хәерче булуы турында сөйли. Әти 1942-нче елда Ватан сугышына чыгып китеп, берничә айдан соң Калинин өлкәсендәге Осиновка авылында батырларча һәлак булган. Әни имчәк баласы белән берьялгызы кала. «Баланы бишеккә салдырып калдырам да тимер юлга эшкә чабам, төшке ашта кайтып имезәм дә, тагын эшкә йөгерә идем», дип сөйли иде әниебез. Әни авырлыкка түзә алмыйча авылга кайтырга чыга. Товарный поезд белән бер ай кайталар. Балага йогышлы авыру эләгеп, үлеп китә, берничә айдан мин туам...

Мин Чирмешән районы Лашман урта мәктәбендә укып, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кердем. Завод китапханәсендә эшләдем. Бу елларда милли кадрларга игътибар юк иде. Кем кайда эш таба, шунда эшләде. Хәзер дә шулай ул. Арча районы егетенә кияүгә чыктым. Ике кызыбыз бар. Үзебез – пенсиядә. Әниемә 91 яшь, безнең белән яши. Кирлемар тавына ниндидер истәлек таштакта, яки ярымайлы төрбә, манара кую киләчәк буыннарга тарихның михнәтле бер көнен искә төшерү булыр иде (2010 ел)».

Дамир энем! Мин Сәрвар хәзрәтнең кызы Оркыяның баласы Тәхсинә Фәтхелислам кызы, Иске Кади авылыннан. Бабай кулга алынып берничә ел үткәч, әбине һәм тагын башка гаиләләрне яшь балалары белән, өсләрендә булган киемнәреннән генә Кирлемар тавына озаталар. Бу гыйнвар аеның чатнама суыклары. Әнигә ул вакытта 6 яшь кенә була. Еллар узгач, туганнарым белән Кармыш белән Әшәлче авыллары арасындагы Кирлемар тавындагы лишуннар поселкасы урынын барып карадык. Монда әниләребезнең күз яше тамган җир. Бу биеклекне кем уйлап тапкан, диген. Сталин шунда сөрегез, дип әйтмәгәндер. Моны үз халкыбыз шулай эшләгән. Берничә бала салкыннан өшеп тә үлә, хәтта аларны җирләргә урын булмый. Алар түбәндәге Әшәлче поселогы зиратында җирләнгәннәрдер, мөгаен. Кармыш һәм Әшәлче кешеләре бичараларга төннәрен землянкалар казырга булыша, җылы киемнәр алып килә. Үзләрендә дә чамалы гына булган ризыклары белән бүлешә. Әлеге авыллар халкына әбием гомере буе рәхмәтле булды. Без шушы урынга баргач, баш очыбызда очып-очып кечкенә бер кош сайрады. Аның якында гына оясы булып: «Әй, кешеләр, минем нәниләремә тимәгез», дип балаларын саклавы идеме, әллә инде әниләребезне искә алып, күз яшебезне тыя алмыйча елавыбызга, эчтән генә Коръән сүрәләре укып, игелекле бәндәләргә рәхмәтле булганыбызга кинәнә идеме...? Сөбеһаналлаһи, шуны сизгән бит кошкаем (2012 ел).

*Өммегөлсем Вафина хатирәләреннән*: «Репрессия елларында Ибрай авылының кайсыннандыр бер гаиләне «лишун тавы»на китергәннәр. Тау башында ышыкланырлык бер куышлары да булмаганга, аларны башта Әшәлчегә Әхмәткәрим бабай Вәлиевларга китереп бушатканнар. Ул

вакытта Әбелвафа бабай кызына җиде яшьләр тирәсе булгандыр, мөгаен. Шул сөйли: «Уйнап-көлеп йөргәндә шунда бер савыт кебек кечкенә әрҗәдә көмеш чулпылар, беләзекләр күрдем дә, берсен алып тактым. Инде кемгәдер мактанасы да килә. Мәрзия әби күрде дә, кызым бу әйбер безнеке, дип чәчемнән сүтеп алды». Алар «лишун тавы»нда ике кыш чыкканнар, дип сөйлиләр. Гаиләдәге бабайлары салкын тиеп шул тауда үлгәннән соң, аның җәсәден безнең авыл зиратына алып төшкәннәр. Бабайның каберен зиярәт итәргә туганнарымы, әллә балаларымы алтмышынчы елларда берничә мәртәбә килгәннәр. Әбелвафа бабай аларны чәй эчәргә безгә алып килгән иде (2016 ел, август, Кармыш авылы)».

*Безнең искәрмә: Монда сүз Әшәлче зиратына күмелгән Иске Ибрай авылы мулласы Вәлимөхәммәт Мостафин турында бара, дип аңларга кирәк.*

*Бибисара:* Мөхәммәт Гыйльметдин улы Бәширов (1858–1930?) Самара губернасы Янховская (Елховская) волостенда (олыс) туган (Мәләкәс районы Тубестан авылы). Ул Кизләү мәдрәсәсендә укыган булырга тиеш. Яңа Ибрай (Аксубай районында) авылының өченче мәхәлләсенә имам-хатыйп, халык телендә «бозау очы мәчете»нә мулла итеп билгеләнгән. Балалары Мәхмүт, Фәрбизә, Мәрзия (Елховой авылы кешесенә кияүгә киткән). Башка балалары билгеле түгел. Совет чорында кулак муллалар төркемендә катнашкан, сәвиткә каршы вәгазь сөйләгән, дип, авылдашлары ярдәме белән 1929-нчы елның 21 июнендә, олы яшьтәге аксакалны оятсызларча кулга алганнар. Мөхәммәт бай авылда кибет тоткан, үз заманы өчен бик хәлле, тырыш кәсепче дә булган. Ул күбрәк дин эшләрен кайгырткан. Элек авылда муллалар начар яшәмәгән, гореф-гадәтләрне башкарудан кесәләренә нинди дә булса табыш, гошер кергән. Мулланы 5 елга концлагерьга хөкем итәләр. ОГПУ аны законның иң куркыныч 58–10 маддәсе белән гаепләгән. Хәзрәт анда үлгән яисә атып үтерелгән, дигән хәбәрләр бар.

Улы Мәхмүт үз авылыннан бер кызга өйләнгәч, уллары Вәлиәхмәт туа. 1930-нчы еллардагы күмәк хуҗалыклар төзү сәясәте бу гаиләгә санап бетергесез бәла-казалар алып килә. Булган малларын, җыйган мөлкәтләрен совет талап ала, хәтта йортларыннан да куып чыгара, үзләрен мәсхәрә итеп, сүгеп-кыйнап авылдан куалар. Мәхмүт, хатыны һәм кечкенә улы белән бергә сөргенгә куылмасын дип, гаиләсеннән аерылган итеп яздыра, бөтен газапны үз өстенә ала. Үз әнисе һәм бер хезмәтчесе белән Кармыш авылының Саклык дигән 36 йортлык авыл янына килеп утыра (бәлки, үзегенәдер дә). Саклык авылы – Яшәүче (Әшәлче) авылы кебек ук Кармыш авылыннан мәҗбүри көчләп күчерелгән бер торлак. Авылның яшәү еллары 1926–1978 еллар, аннан ятим калган мөселман зираты гына бар хәзер.

Саклык авылында иң беренче туган балаларның берсе Зәйтүнә апа Хәммәдиева әйтүенчә, Кирлемар тавында яшәгәннәр, җан асрар өчен башка «лишун»нар белән бергә өй сымак бер гади генә корылма ясаганнар. Мәхмүт, Кирлемар сөргененнән котылу өчен, Саклыктагы бер гади кешенең кызына өйләнүне һәм, җае чыкса, инде матур гына яңа нигезләнгән Саклык авылында тамыр җибәреп, шунда төпләнеп калу турында хыялланганга охшаган. Хәсәнша бабай Хәммәдиевнең олы кызы Бибисараны никахлап ала. Хәсәнша бабайның иленнән, җиреннән куылган кешегә, һәрдаим артыннан күзәтелүче кулакка кызын бирүе зур табышмак. Бәлки, ул да, бу эшләр шулай җиңел генә узып китәр, эшлекле кияү кызым белән Саклыкта калырлар, бәхетле булырлар, дип уйлагандыр. Бибисараның бәхетсезлеге кияүгә киткән вакытыннан башлана. Күп тә үтми Мәхмүтне башка «мәхбүс»ләр белән бергә 1934-нче елларда Себергә озаталар, Бибисара да китә. Әмма ул анда калалмый, качып кайта, 1935-нче елның 15 июнендә кызы Фатыйма туа. Тамак хакына колхозда эшли.

Бәхетсезгә гел җил каршы, дигәндәй, монда да рәхимсез язмышы чабуыннан ук эләктереп ала, басудан ач-ялангач кайтканда кесәсенә салган бер уч арыш бөртекләре аны бу каһәрле дөньяның дошманы иткән. Бер авылдашы, кемнәрнеңдер кушуы буенча тиешле җиргә барып, бу хәлне яхшы итеп әләкли. Аның белән бергә авылдашы Фәсхетдин һәм Мөсәвәрә Шәрәповлар кызы Зөләйха да «капкын»га эләгә.

Саклык колхозы рәисе Степан Шишкин эшне зурга җибәрмичә, шелтә белән генә йолып калмакчы була Бибисараны. Кулак хатынын яклаган өчен аңа да бик каты эләгә. Бибисара һәм Зөләйханы конвойлар төрмәгә алырга килгәндә, авыл халкы аларны Иншар (Батрак) авылына кадәр елый-елый озата барган. Иншар авылы – Түбән Кәминкә авылыннан аерылып чыккан кечкенә хуҗалык, авыл 1975–1976-нчы елларда таралып беткән.

Өч яшьлек Фатыйманы да әнисе артыннан күтәреп барганнар. Соңгы васыяте: «Баламны ташламагыз! Ятим итеп какмагыз, урамда очраса, башыннан булса да сыйпап үтегез», – дигән. Яңадан Саклыкка әйләнеп кайтмаячагын күңеле белән сизеп торган. Бу вакыйга – 1938-нче елларның кара көзе. Нәкъ шул көйсез, пычрак, юеш карлар яуган вакытта Казан изоляторында Бибисараның хәсрәткә түзмичә йөрәге шартлаган, диләр. Әмма шулай гына микән? Бибисара соңгы серләрне үзе белән мәңгелеккә алып киткән. Кызларның икесен дә бишәр елга хөкем иткән булганнар. Зөләйха тоткынлыктан «досрочно» котылган, әмма бервакытта да Саклык авылына аяк басмаган. Фатыйма исә бабасы Хәсәнша, әбисе Шәмсенәвар тәрбиясендә үсә…

Түбәндә Бибисара әбинең оныгы Рафикъ Шәүкәт улы Госманов чыгарган бәет.

Кармышларда туып Бибисара әби,
Саклыкларда үткән яшьлеге.
Сиңа да бит бәхет теләгәннәр,
Җитсен, дип матур картлыгы.
Ни өметләр баглап, Хаши бабай,
Мәхмүт байга бирдең кызыңны?
Ләүхел Мәхфузләрдә язылган шул,
Үзгәртепләр булмый язмышны.
Мәхмүт бай «кулак», – диеп,
Ерак Себергә сөрелгән.
Сагынуларга түзә алмый, Сара әби
Туган нигезенә кайтып егылган.
Урак урган Саклык кырларында,
Яшь баласын асып иңенә.
Арыш салып кайткан кесәсенә,
Тәгам кылырмын, диеп өендә.
Шул бөртекләр,чикләп гомерен,
Язмышына нокта куйдылар.
Кулак хатынын богаулап,
Зинданнарга алып киттеләр.
Киткән чакта ияреп барды,
Иншарларга хәтле озатып, кызчыгың.
Аерылышканда ничек түздең икән?
Өзелепләр калды бәгырең.
«Баламны какмагыз ятим итеп», –
Соңгы сүзең әйттең ачынып.
Җаның сизгәндер, әй, әбием,
Соңгы туең килә ашыгып.
Ятим кызың кысып күкрәгенә
Күз яшьләрен күпме түккәндер?
Шәмшүәр әби сорап Раббысыннан
Төннәр буе дога кылгандыр.
Тарих тәгәрмәче алга бара,
Таптап-изеп күпме язмышны.
Ник язам соң, ник актарам
Төзәлепләр килгән яраны?
Башым иеп торам басу кырыенда,
Әче әрем сарыла битемә,
Әбиемнең истәлеге итеп, –
Арыш сибәм Саклык кырына.

*А. Һ. Казаков*

## «АЛТЫНМЫ, ИМАНМЫ?»

Туган як тарихында «ак тап» булып торучы бер мөһим мәсьәлә безнең авылда хәзер дә өлкән кешеләр арасында бәхәс тудыра. Көек авылы халкы чукындырылганмы, әллә юкмы, булса, кемнәр безнең авылдан мондый каһәрле язмышка дучар ителгәннәр? Бу сорауга җавапны мин ТР МА фондларыннан таптым, дисәм, дөрес булыр иде.

Әмма бераз риваяти якны да тикшереп китик. Шул риваятьләрнең берсе буенча чукындыручылар Кыркапка ягына кадәр килеп җитмәгәннәр, чөнки Актай елгасында көчле ташу булып, күперне су алып китә. Чынбарлыкта исә туган авылымның кешеләре көчләп чукындырылган, һәм XIX гасырның беренче яртысында күп кенә кешеләрнең исемнәре күрше Базяково, Лебедино (Кызыл Су), Бураково һәм Николо-Пичкасскийның чиркәү метрикаларында теркәлгән. Шуңа да карамастан, кире исламга кайту теләге шулкадәр көчле булган ки, бернинди репрессияләр дә моны туктата алмаган. 1850-нче елны үткәрелгән ревизия язмасында «Григорий Миронов, и его жена Евсинья, и мальчик его Иосиф и его брат Абдрахман переселены в село Ивановское Лаишевского уезда, Дмитрий Степанов и Евфим Григорьев сосланы в Сибирь в 1838 г.», – диелә. Бу хәлләрнең туган авылымда булуын Көек старшинасы Миркәй Миңневәлиевнең мөһере белән шәхси имзасы да раслый. Кире исламга кайтучыларны керәшен һәм рус авылларына күчерү, рекрутлыкка озату, «кире христианлыкка кайт», дип үгетләү һәм судка бирүне дә авылым халкы үз башлары аркылы кичергән. 1843-нче елның 8 октябренә караган рапорттан күренгәнчә, Казан Хәрби Губернаторы Рухани Консисториясенә түбәндәге сүзләр белән мөрәҗәгать итә (лексикасы үзгәртелмичә бирелде): «Губернское правление просит Духовную Консисторию со своей стороны докладывать об обращении крещеных татар Спасского уезда села Каюковъ Абдулхака Елдашева, Исая Ибраева и Даута Данилова в христианство, ибо какъ видно изъ прошения поданного на имя Его Первосходительства Казанского Военного Губернатора они называют себя татарскими именами». Моңа җавап итеп, Пичкас рухание Валентин Ястребов Казан һәм Зөя архиепископы Владимирга түбәндәге рапортны яза: «Его Высокопреосященству. Высокопреосвященнейшему Владимиру Архиепскопу Казанскому и Свияжскому и разных орденов кавалеру. 27 генваря 1845 г. Спасского уезда с. Пичкасс от священника В. Ястребова».

***Покорнейший Рапортъ***

*«Имею честь донести Вашему Высокопреосвященству, что 7 декабря 1847 г. мной присоединены к православной церкви, крещеные татары*

*деревни Каюковъ казенной ведомости татарин Иаков Данилов от младенчества находящийся в магометанском заблуждении и от православия, уклонявшегося. При сем, прилагаю обязательство, взятое от него в непосредственном пребывании в недрах православной церкви. Генваря 20-ого дня 1848 г.».* Бу обязательство кәгазенең чиста татар кешесе тарафыннан язылуы мөмкин түгел, чөнки аңарда түбәндәге юллар бар: *«1847 г. 7-го декабря. Я, нижеподписавшийся, Казанской губернии Спасского уезда деревни Каюковъ из татар крещеных казенного ведомства крестьянин Яков (по ревизским сказкам Степан Данилов) от младенчества до сего времени находившийся в магометанском заблуждении обязуюсь, навеки отказаться от такого заблуждения как от противного для души и никогда не впадать в оное заблуждение. Обязуюсь присоединиться к Святой, Апостольской Церкви Христовой, поклоняться и славить только оную церковь».* Спас өязенең благочинные Люстрицкийга Рухани Консисториясе аның чиркәүгә йөрүен күзәтү астына алырга дигән 339 номерлы указ җибәрә. Бер ел узганнан соң, Ястребов түбәндәге белешмәне язып бирергә мәҗбүр була.

***Справка***

*«1848 годъ №5777 Записано от сентября 8ого от Казанской Палаты Государственных Имуществ о том, что присоединенный к православию от магометанства крестьянинъ деревни Каюков Яковъ Даниловъ живет в деревне Каюки при семье своего отца Данилы Иванова».* Мәҗбүриләп кенә калмыйлар ә күп кенә кешеләрне, шул исәптән Көектән 15 ир-атны, 8 хатын-кызны, көч ярдәмендә керәшен яисә чиста рус авылларына күченергә мәҗбүр итәләр. Түбәндәге географик исемнәр арасында Чистай өязенең Ак Тау, Чебоксар өязенең Помары, Мамадыш өязенең Предтеченское (Ахмылово тожъ), Лаеш өязенең Ивановское авылы атамалары очрый. Күчерелгәннәр арасында түбәндәге кешеләр бар: бу исемлек *«Переселенные изъ, Спасского округа из деревни Каюковъ по причине отвращения от христианской веры и обращения в магометанство»*, дип атала һәм 1840 елга карый.

В село Ивановское Лаишевского уезда приход села Ключи:

Григорий Михайлов – 42 года.

Анастасья – жена его 25 лет.

Логинъ – 5 лет.

Татиана – 3 года, были ли крещены, неизвестно?

Анна – 2 года.

Некрещеная по-татарски Бадигуль-Замал – 1год.

Вдова Татиана – 57 лет.

Его сыновья Михаил Лукатов – 22 года, Марфа его жена, 2 бракъ.

От первого брака Анна.

От второго мужа Семен Михайлов – некрещеный – по-татарски именуемый Хамитъ, 2 года.

Умершего Бориса Егорова вдова Анна Александрова – 32 года.

Давид – 15.

Ефим – 10 – были ли крещены, неизвестно.

Егор – 2 1\2 года.

Гайнетдин – 5 лет.

Иванъ Исаевъ – не известно к какому семейству принадлежит.

В Чебоксарский уезд в село Помары:

Семен Ефимов 60 лет – по-татарски – Хамитъ Махмутовъ.

6 1\2 года приемный сын его Хайбулла Махмутовъ – при крещении Алексей Петров – был ли крещен неизвестно.

Архипъ Романовъ – 45 лет Ибрай Абрахимов.

Жена его Матрона – 44 лет по-татарски Канафея.

У них сын Иванъ по-татарски Файзетдин – 18 лет.

1840 елны исемлек тагын да тулыландырыла, чөнки Григорий Михайловның үзбаш булып яшәүче ике абыйсының да гаиләсен күчерәләр.

1 братъ – Герасим.

Евдокия – жена его.

Феодосья.

Елена.

2 братъ – Егор.

Варвара – жена его.

Степан – сын, жена его – солдатка.

Иванъ – сын.

Анна – дочь».

Егорның ике кызын да чукындыралар, Бәдигол исемлесенә – Аграфена, Җамал исемлесенә Акулина дигән исемнәр кушалар, һәм Егорның үзен 1853-нче елны рекрутлыкка саталар. Кире кайту хәрәкәте Спас өязенең Урта Тигәнәле, Урта һәм Иске Биктимер, Иске Салман, Чуваш Кичүе, Түбән һәм Югары Әлморза кебек зур авылларны да үз эченә ала. Һәм мин, тулы бер нигез белән, «Көек Зөләйхасы» булган, дип әйтә алам. Аның исеме Галия була. Әлеге персонаж тулысынча Гаяз Исхакый персонажының язмышын кабатламый, үзенчәлеге шунда ки, ул Ислам диненә туры калганы өчен эзәрлекләнелә, аны туган апасы Важиһә (Фетинья) үзе яшәгән Ташбилге (хәзерге Әлки районы) авылында суд тикшерүеннән яшереп, 3 ел дәвамында тота. Туган авылымның зиярагында 1865-нче елны дәфен ителә (ягъни күмелә). Күргәнегезчә, туган авылым Көекнең үткәнендә фаҗигаләр күп булган, бу халкым фаҗигасенең бер сәхифәсе генә.

*Батулла*

## МӘҢГЕЛЕК «САК-СОК»

Татар халкының иң борынгы һәм үлмәс әсәре – «Сак-Сок бәете», дип уйлыйм мин. Аңа иң кимендә ике мең яшь, эзләнә китсәң, бәлки, өч-дүрт мең ел да бардыр.

Бәетнең Исламга кадәр үк халык арасында таралган булуына дәлилләр әсәрнең үз эчендә ята. Ислам дине пәйда булганга мең дүрт йөз егерме, Идел буендагы бабаларыбызның Исламны рәсми кабул иткәненә мең өч йөз җитмеш җиде ел гына. Әгәр дә «Сак-Сок бәете» моннан сигез йөз яки мең ел элек кенә иҗат ителгән булса, без анда «бисмилла, Алла, Коръән» сүзләрен очраткан булыр идек. Ислам кергәч, бер генә әсәр дә бисмилласыз башланмаган. Ә бу әсәрдә Исламның тәэсире сизелми. «Мәдрәсәләрдә пыяла ишек» сүзе бер караганда, әсәр Ислам кабул ителгәннән соң язылган, дип уйларга да форсат бирә кебек. Ләкин әсәрнең сюжеты, темасы, чишелеше «мәдрәсә, мәчет» сүзләренең соңгы нөсхәләрендә генә куллана башлаган, дип уйларга җирлек бирә. Мәгълүмдер ки, көе борынгы булып та, сәяси мохит үзгәргәннән соң җырларның сүзләре үзгәрә килгән, яңа сәясәткә кулай текст барлыкка килгән. Сүз өчен җавап бирәсе була, музыкада исә сәясәт төртеп тормый.

Коръәнгә кадәр татар халкының конституциясе, яшәү кануннары, әхлагы, тәрбия кагыйдәләре шушы «Сак-Сок» бәетендә тупланган булган. Ихтимал, «Сак-Сок» ниндидер бер олы, озын, кануни әсәрнең бер өлеше генәдер. Шушы өлешендә генә дә без ул дәвердә яшәү рәвешенең нинди кагыйдәләргә буйсынганын чамалыйбыз.

Ике туган талашмаска, бер-берсен рәнҗетмәскә тиеш!

Бала ана сүзеннән чыгарга тиеш түгел!

Ана ул – изге зат. Бала аны борчырга, аңа каршы килергә, ананы рәнҗетергә тиеш түгел!

Ана баласын каргый икән, үз башына булыр! Димәк, ул заманнардагы әхлак буенча каргану ярамаган эш саналган.

Кызып китеп, ана кеше газиз балаларын каргап ташлый да, балалары ике кошка әверелеп урманга очып киткәч, соңра кара кайгыга сабыша, үкенә. Ягъни, кылган языгының җәзасын шундук татый.

Балалар да бер тимер ук өчен сугышып, аналарына хәсрәт китергәннәре өчен үкенәләр. Ләкин ананың ялварулары да, балаларның теләкләре дә кабул булмый. Алар шулай мәңгегә аерылалар. Кайтарып ала алмаслык үкенеч, аяныч. Кара тәкъдирле балалар, кара тәкъдирле

ана белән ата, ләкин атаның роле әсәрдә күренми дә, аның гаиләдәге хокукы юк дәрәҗәсендә. Ата өйгә кайтып керүгә балаларының, каргалган килеш, Сак белән Сок кошларына әверелеп, тәрәзәдән очып чыгып киткәннәре турында ишетә. Ләкин берни кыла алмый. Хәтта хатынын битәрли дә алмый.

Бу – Сак-Сок вакыйгасы – анабаш (матриархат) чорында булганга ишарә түгелме? Ананың гаиләдәге хокукы зур икәнлеге ярылып ята, ул каргый, ул ачулана, ул тәртип урнаштырырга тырыша, ялгыша. Ата пассив бер зат кебек кенә күренә.

Әсәрнең чыннан да бик борынгы заманнарда язылганына тагын бер ишарә бар. Ике ир туган бер тимер ук өчен талашалар. Аларның башка уклары булмаганмы? Шушы бүгенге күзлектән караганда, чүпкә дә тормаган тимер ук башы өчен алар талашып, ана тикле ананың каргышына дучар булалар. Таш гасыр, аннан соң Бакыр гасыр, аннан соң Тимер гасыр килгәнен без яхшы беләбез. Бакыр кораллар кешелек дөньясын Таш гасырдан алып чыккан, тимер табылгач, кешелек дөньясы Тимер гасырга кергән. Ягъни, бакыр укка караганда тимер ук затлырак, кыйммәтлерәк һәм сирәк булган. Димәк, Сак-Сок вакыйгасы Бакыр гасырдан Тимер гасырга күчкән елларда, чама белән дүрт мең еллар әүвәл булган, дип фаразларга мөмкин. Әйтик, тимернең яңа гына кулланыла башлаган чорында бер тимер ук ат бәясе torгандыр. Ике ир угланның чүп өчен түгел, шактый кыйммәт нәрсә өчен талашуы чамалана, бу исә кечкенә нәрсә түгел.

Бәлки, әсәр тар гаилә гаугасын түгел, ике кардәш халыкның вак бер нәрсә өчен кан дошман булып талашып, аерылышуына кинаядер. Сок исемле елга бар Самара өлкәсендә. Шуның белән кушыла алмыйча ага торган Сак елгасы да булгандыр, бәлки. Исеме генә үзгәргәндер. Сак исемле борынгы бабаларыбыз да булган, далаларыбызда саклаблар яшәгән*. Бүгенге көндәге төрки якутлар үзләрен «саха халкы» дип тә йөртә. Кайчандыр Сок буендагы мишәрләр-татарлар саха халкы белән бертуган булган, ләкин аерылган, телебез нык үзгәргән, динебез дә уртак түгел. «Сак-Сок бәете», бәлки, бу ыруглар, нәселләр арасындагы котылгысыз гаугаларны, фаҗигагә китергән дошманлашуны да күз уңында тотадыр.

Инде иң мөһим бер мәсьәләгә тукталмыйча мөмкин түгел. Гаеплеләр өстеннән каргышның алынмавы. Тылсым көче дә, сихер дә, Алла да бу эшкә катнашмый. Ана кеше балаларымны коткар, дип, бер затка да ялвармый. Күрәсең, Ана каргышына бер затның да кодрәте җитми. Әсәр шушы фаҗигасе белән озын гомерле булып туган. XX гасырда язылган балалар

* Редакция искәрмәсе – әле бит Саксин шәһәре дә булган Идел буйларында.

әдәбияты әсәрләрендәге кебек, бу әкият яхшы тәмамланмый, каһарманнар кушылмый, ахырда сөенмиләр, соңыннан: кабат алай эшләмәбез, дип тә әйтмиләр алар. «Сак-Сок» әсәре фаҗигале азагы белән куәтле дә, шуның аркасында ул мең елларны узып та тузмаган. Матур тәмамланган әсәрләр озын гомерле булмый, күрәсең.

Хөрмәтле кардәшем! Әсәрнең фаҗигасе тетрәндерә һәм син шушы фаҗигане гомереңбуена онытмаячаксың. Бу әсәрне укыгач, бу әсәрне тыңлагач, син инде гамьсез генә яши алмаячаксың. Бичара ана, бичара балалар турында уйлап, син аларга теләктәш булачаксың. Син өч мәсьәләгә җавапны шушыннан табачаксың: туганнар белән бозылышмаска, тату яшәргә; Анага борчу салмаска. Ана – Изге зат. Никадәр генә кыен булса да, Ана үз баласын каргарга тиеш түгел. Каргый калса, ул үзенә, бөтен нәселенә җәза чакырган булыр, һәр каргыш кешенең үз башына була икән.

«Сак-Сок» бәетенең көйләре бик күп. Композитор, галим Шамил Шәрифуллин «Сак-Сок» көенең 22 нөсхәсен җыйган. Шуларның иң борынгысы, иң матуры, минемчә, безнең Зәй якларында җырлана торганы. «Сак-Сок» бәете тагын бер фаразга этәрә. Бу әсәр музыкалы, җырлы, уенлы тамаша. Безгә аның аерым өлешләре генә килеп җиткәндер, ахрысы. Ләкин бу мең еллар әүвәл думбыра, кубыз, курай кебек уен кораллары катнашкан оркестр ярдәме белән башкарыла торган халык тамашасы, театры булгандыр.

Мәрхүмә әбием – Мәгъсүмә карчык, «Сак-Сок»ны бая санаган уен коралларында уйный-уйный сөйли, җырлый, аңлата торган иде. Аның «Сак-Сок»ны башкаруы бер кешелек театр кебек иде.

Ислам дине татар халкының йолаларына балта чапмаган, һәрхәлдә, татар халкы мөселман булгач та, Исламгача булган йолаларын ташламаган. Халыкның Исламга кадәр булган изге йолалары: Сабан туе, ияләргә ышану, йөзенче кыл йоласы, чишмәләргә хәер салу һәм менә «Сак-Сок» могҗизасы бүгенгә кадәр килеп җиткән. Халык талантлары көйле, җырлы уеннарын, бәетләрен йола буларак башкарган, алар халык театрының башында торган, дип әйтергә тулы нигез бар. Моңа мисаллар күп: «Хан кызы», «Йосыф-Зөләйха», «Таһир-Зөһрә» исемле музыкаль әсәрләр – Хан сарайларында, мәйданнарда, халык алдында көннәр буена башкарыла торган музыкаль тамаша һәйкәлләре.

XVI йөздә Казан хакиме Мөхәммәд Әмин ханның сараенда кыллы, барабанлы, быргылы оркестр, биючеләр, җыручылар булганы мәгълүм. Аларның җитәкчесе җыр чыгаручы һәм шул җыруларны үзе башкаручы шагыйрь Голәм Шаади булган.

Ихтимал, бу сарай театрының репертуарында халкыбызның үлмәс музыкаль әсәре «Сак-Сок» тамашасы да булгандыр. Нинди гүзәл әсәр

дөньяга чыкмый ята. Юкса, «Сак-Сок» төкәнмәс мәүзуг булып, татарның һәр төр сәнгатендә лаек урынын алырга тиеш бит. Симфония, опера, балет, драма, кыйсса, телевизион һәм радио тамашалары иҗатителергә тиештер. Сәнгатьчеләрнең күңел күзе шушы үлмәс әсәрне күрмәде, һәм, ниһаять, Татар яшьләре театрының баш режиссеры Ринат Әюповның махсус кушуы буенча, мин «Сак-Сок» исемле пьеса яздым, бу тамаша 2003 елда дөнья күрде.

Әйтергә кирәк, «Сак-Сок»ның тарихта ике нөсхәсе сакланган, киң таралганы – бәет, икенчесе – кулъязма сыйфатында чыкканы – дастан. Төп мәүзуг (тыңлаусыз балалар, ана каргышы һәм ул каргышны кайтару мөмкинлеге булмавы) уртак. Ләкин аермасы да кечкенә түгел, дастанда бәеттә булмаган әкияти каһарманнар: Алпамша, Албасты, Шүрәле дә хәрәкәт итә. Яшь тамашачылар театрындагы тамашага дастан нөсхәсе нигез итеп алынды. Бәет нөсхәсен файдаланып язылган «Ана каргышы» исемле икенче пьеса Чаллы драма театрында куелды. Бәлки әле, алга таба симфония дә, балет та, балалар өчен опера да пәйда булыр. Бирсен Ходай!

*Г. С. Хаҗиева*

# АВЫЛЫМ КУШАМАТЛАРЫ

***Аннотация.*** *В данной статье рассматриваются семантические и лексико-тематические особенности татарских прозвищ. К анализу в работе привлекаются прозвища, зафиксированные в научных экспедициях в Мензелинский и Муслюмовские районы РТ. Объем анализируемого материла не является исчерпывающим, но позволяет выявить общие особенности татарских прозвищ. В ходе исследования выявлены различные их типы, мотивы наречения. Выявление диалектных особенностей татарских прозвищ и их трансформации позволяют выявить происхождение ряда антропонимов.*

***Ключевые слова:*** *татарские прозвища, локальные варианты прозвищ, традиционная культура, мотив, семантические особенности.*

Кушамат – кешенең рәсми, төп исеменә кушма, өстәмә мәгълүмат бирә торган ономастик берәмлек. Кушамат термины составындагы ат сүзенең борынгы төрки телдә булуы аның бик күптәннән барлыкка килүен һәм төп исемгә өстәмә буларак элек-электән кулланууын раслый. Борынгы заманнарда кушаматлар фамилия функциясен башкарганнар, ягъни кеше исеменә өстәлеп, шәхесне тагын да конкретлаштырганнар. Орхон-Енисей язмаларында, М. Кашгариның «Диван лөгат әт төрк» хезмәтендә исем белән бергә кушамат та аерым функция үти. М. Кашгариның әлеге сүзлегендә «at» сүзенең беренче мәгънәсе исем дип күрсәтелсә, икенче мәгънәсе – кушамат [Махмут ал-Кашгари: 2010. С. 112].

Балага исемне тугач та, әти-әнисе бирсә, кушаматны кешенең яшәү дәверенең төрле этапларында коллектив, җәмгыять куша. Исем, ата исеме, фамилиягә образлы эмоциональ-экспрессив төсмерләр хас булмаса, кушамат коннотив, эмоциональ-экспрессив төсмерләргә ия мәгънә бирә. Кушамат – кешенең үзенчәлекле сыйфатларын яки җәмгыятьтәге урынын ачу максатында җәмгыять яки кешеләр тарафыннан бирелгән рәсми булмаган исем. Кушаматларның шәхси яки төркемнәргә хас төрләрен аерып карыйлар [Энциклопедический словарь-справочник: 2008. Т. 1. С. 146]. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә кушаматка конспирация өчен яки кешеләрдән көлеп, мәзәк өчен бирелгән исем дип аңлатма бирелә [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 2005. 299 б.]. Кушамат – тарихи, мәдәни, иҗтимагый һәм башка шартларда барлыкка килгән барлык төр антропонимик берәмлекләр өчен дә, аерым алганда, фамилияләрнең формалашуында хәлиткеч роль уйнаган берәмлек. Бүгенге көндә исә кушаматлар – аерым бер локаль мәдәнияткә хас, диалекталь тирәлектә формалашкан иҗтима-

гый аеру вазифасын үтәп, антропонимиконның динамик үсешен билгели торган темпораль, иҗтимагый, эмотив-бәяләү, территориаль факторларга нигезләнгән тану өчен хезмәт итә торган берәмлекләр. Кушаматлар җирле мәдәнияткә нисбәттә яки иҗтимагый чикләнгән сөйләмдә, гади сөйләм, диалекталь, сленг тирәлегендә формалашалар. Шуңа күрә, әлеге фикерне дәлилләп, кушаматлар аерым диалект вәкилләренең күзаллауларын, җирле мәдәнияткә хас сәнгати мөмкинлекләрне, үзенчәлекләрне ачалар, дөнья, этнотирәлек турында мәгълүматның күләмен һәм дәрәҗәсен, креативлыгын билгелиләр, дип әйтергә нигез бар.

Борынгы төрки язмаларда кушамат кешене төрле яктан сыйфатлап килә. Мәсәлән, Орхон-Енисей язмаларында кешенең физик һәм психологик үзенчәлекләрен сыйфатлаган кушаматлар төп исемгә ялганып килгән, кешене төрле яктан характерлыйлар. Орхон-Енисей ташъязмаларында еш очрый торган bilgä кушаматы – «акыллы» [Orhun Yazıtları: 2008. S. 129], alp – «укчы, герой, батыр, курыкмас, кыю» [Orhun Yazıtlar: 2008. C. 120]; küčlüg «кыю, көчле» [Orhun Yazıtları: 2008. S. 156] дигәнне аңлаталар. Шул рәвешле, борынгы төрки чорның акыллы, көчле, кыю кеше образын реконструкциялиләр. Исемнәрдән күренгәнчә, bilgä – «акыллы» компоненты бинар исемнәрдә кулланыла. Эпитафик язмаларда чагылыш тапкан Билге Каган акыллы, сакчыл, йомшак күңелле кеше булган, шуңа күрә әлеге компонент исем составында килеп акыллылык мотивын чагылдыра.

Борынгы төрки язмаларда көч мотивы Küč [Orhun Yazıtlar: 2008. S. 156] кушаматы нигезендә чагылыш таба: *Küç Barlığ, Küç Kül Tutuk, Küç Tegin, Küç Temir, Kılıç Küç Kara, Küç Kıyagan*. Борынгы төркиләр көчнең Тәңре тарафыннан бирелүенә ышанганнар һәм әлеге кешеләрнең дә Тәңре тарафыннан ятарылуына инанганнар. Борынгы төрки антропонимик системасында беренчел һәм икенчел антропонимик берәмлекләре арасында аерма булмый, әлеге категорияләр бер вазифа башкарганнар.

922-нче елда ислам диненең рәсми рәвештә кабул ителүе антропонимик системага да сизелерлек йогынты ясый. Мөселман мәдәнияте тәэсирендә антропонимик системада кушамат һәм исем антропонимик категорияләре арасына чик куела. Гасырлар дәвамында мөселман антропонимик система белән янәшә төрки антропонимик системасы да кулланылышта була. Кешенең тормышын күзалларга мөмкинлек биргән титуллар, кушаматлар озак вакытлар исем белән бергә кулланылышта йөри. Мәсәлән, Алтын Урда чоры чыганакларында да традицион борынгы төрки исемнәрнең кулланылышын күзәтергә мөмкин: *Биш Куртук, Бука Тимур, Бәк Тимур, Ильбука, Ильтутмуш, Караболат, Карабаһадир* и һ.б. [Становление и расцвет Золотой Орды: 2011]. Алтын Урда чоры чыганакларында борынгы төркиләрнең исемнәрендә хайван атамаларының

кушамат ролендә килүе күзәтелә: *Бука Тимур, Биш Бука, Арык Буга* һ.б. Хайван тотемнары белән бирелгән кушаматлар шәхеснең нәсел-нәсәбе, ыру башлыгының исеме турында да мәгълүмат бирәләр.

XVI–XVII гасыр писцовая кенәгәләрендә исем белән кушамат аерылып бетмәгән антропонимик компонентлар очрый: *Күчүк* (кечкенә), *Кәтүк* (кечкенә); *Тулыбай* < «тулы +бай»; *Күкеш, Сытыш* кушаматларының сәламәт булмаган балага бирелүе турында искәртелә [Писцовая книга: 2001; Писцовая книга: 2009].

XVIII гасырга караган Ревизия кенәгәләрендә исемнәр белән бергә кушаматлар кулланылышы күзәтелә: *Карабаш Гали, Сабай Ишкенә* һ.б. Карабаш, Сабай кебек компонентлар, кушамат ролен үтәп, рәсми кенәгәләрдә теркәлгәннәр. Тарихи чыганакларда төрки-татар исемнәренең зур өлешен кушаматлар тәшкил итәләр. Татар исемнәре бер яктан кушамат буларак кыскарып үзгәреш кичерсә, икенче яктан әлеге кушаматлар гарәп һәм урыс теленең яңгыраш үзенчәлекләренә бәйле бозыла: *Мамай* (Мәмеш, Мәмәд, Махмед) *Мөхәммәд*, *Камай* (Камалетдин), *Колай* (Коләхмәт), *Малей* (Мәли, Малик), *Шамса, Шемай, Шәмәй, Шәмси* (Шәмсетдин), *Баһау, Багыш, Баһдан* (Баһаветдин). Тарихи чыганакларда кешенең үзенчәлекләрен сыйфатлаган кушаматлар да бирелгән: Кылый Гали, Тупас, Чуан Төмән, Йомык, Алабаш, Елый Бирде, Караҗан, Аксак Тимер, Тәбәнәк, Аңнамас, Артык [Ревизская сказка. Ф. 3. Оп. 3]. Мәсәлән, Мамайның (Олы Урда ханы) икенче исеме буларак язмаларда «Тетякъ» (Титәк, Тинтәк) атамасы күрсәтелә.

Кушаматлар XIX–XX гасыр башында ук инде рус теле белемендә игътибар үзәгендә булалар (А.В. Балов, 1899; Д.К. Зеленин, 1913). Соңгы елларда исә тел белгечләре кушаматларны диалект дөнья картинасы фрагменты буларак өйрәнүгә игътибар бирәләр. Рус теле белемендә кушамат рус ономатологлары С.И. Зинин, Н.В. Подольская, А.М. Селищев, А.В. Суперанская, Н.Н. Ушаков, З.П. Никулина тарафыннан өйрәнелә. Е.Ф. Данилина, И.Ю. Карташева, Т.Т. Денисова, Ю.Б. Воронцова, Ж.Д. Маюрова, Е.С. Шостка, А.Н. Лангнер, Н.В. Дранникова, Т.В. Шпар һ.б. диссертацияләрендә кушаматларның лексик-семантик үзенчәлекләре теоретик яктан нигезле итеп тикшерелә. Татар антропонимикасында кушамат Г.Ф. Саттаров, С.И. Гасимова хезмәтләрендә җентекле итеп өйрәнелде. 1973-нче елда, беренчеләрдән булып, Г.Ф. Саттаровның «Совет мәктәбе» журналында «Татар кушаматлары» дигән мәкаләсе дөнья күрә. Әлеге мәкаләдә галим шәхси кушаматларның 21 төркемен аерып күрсәтә [Саттаров: 1973. Б. 46]. Төрки тел белемендә кушамат башкортларда – Г.А. Амиргалина, кумыкларда – Р.А. Мусаева, каракалпакларда – Ю.Н. Хоҗалепесова, азәрбайҗаннарда – А. Курбанов, М.Н. Чобанов, үзбәкләрдә – Э. Бегматов, кыргызларда – Ш. Жапаров, казакълар-

да – Т.Җ. Жанузаков, төрек тел белемендә Ю. Кенан Караҗан, М. Семих тарафыннан яктыртыла.

Кушаматлар түбәндәге төрләргә аерыла: *мелиротив кушамат* – кешенең аерым бер яхшы сыйфатын, дәрәҗәсен билгеләү өчен хезмәт иткән исем; *коллектив кушамат* – аерым бер кешеләр төркеменә, гаиләгә, нәселгә, этник төркемгә бирелгән исем; *шаярту кушаматы* – кешене кимсетү, көлү максатында кулланылган исем; *түбәнсетү кушаматы* – кешене түбәнсетү максатында, сүз белән түбәнсетү өчен бирелгән исем; *мәктәп кушаматы* – мәктәптә укыган чорда бирелгән кушамат.

Мәкаләдә Мөслим районы Вәрәшбаш авылына караган кушаматлар материал буларак кулланылдылар, аларга анализ бирелде. Тел белемендә кушаматларның берничә төре аерыла. Хәзерге татар антропонимик системасында да традиция нигезендә сакланып килеп, тотемистик карашларга нигезләнгән кушаматлар кулланылышта йөриләр. Шәхси кушаматлар исә шәхеснең төрле сыйфатларына нигезләнгән метафорик эчтәлек биреп, чыгышлары белән реаль чынбарлык белән тыгыз бәйләнештә булалар. Алар кешенең гомуми, хосусый, физик һәм рухи сыйфатларын, профессиясенә, яшәү урынына һәм башка мотивларга нигезләнеп кушылалар. Функциональ-семантик яктан, шәхси кушаматлар: 1) бәйләү төсмере булган; 2) сыйфатлау төсмере булган кушаматларга аерылалар. Бәйләү төсмере белән билгеләнгән кушаматлар кешенең теге яки бу сыйфатын, рухи яки физик билгеләрен турыдан-туры атау юлы белән ясалалар: *Олы колак Шамсулла, Тешләк Әзһәр, Косой, Кара Хәбибулла, Торна, Чәүкә* һ.б. Кешенең физик үзенчәлекләрен чагылдырган кушаматның бирелү мотивлары төрле булырга мөмкин. Мәсәлән, күрсәтелгән авылда Чәүкә Хәмәте кушаматы тагылуның түбәндәге мотивы билгеләнә: «*Хәбибулла исемендәге кешеләр авылда өчәү булган. Берсе – Түбән очта, икесе – югары очта. Түбән очтагысын коңгырт йөзле булган өчен Кара Хәбибулла дип, Югары очтагыларын Торна һәм Чәүкә дип атаганнар. Озын буйлысының Торна кушаматы баласына да күчкән, мәсәлән, Торна Әбүзәре. Чәүкә кушаматы да улына калган. Чәүкә Хәмәте*».

Сыйфатлау төсмеренә ия кушаматлар шәхеснең тышкы кыяфәтен һәм физик үзенчәлекләрен, холкын-характерын, һөнәри эшчәнлеген яки социаль статусын билгелиләр. Җирле мәдәнияттә кешенең физик үзенчәлекләрен чагылдырган кушаматлар, күпчелекне тәшкил итеп, кешегә характеристика бирәләр, аның буен, фигурасын, чәч төсен, физиологик кимчелекләрен күрсәтәләр.

Кушаматта кулланылган квалитативлар иркәләү-кечерәйтү төсмерләренең киң спектрдагы мәгънәләрен бирәләр, үз чиратында, әлеге коннотатив мәгънәләр кешегә карата гына түгел, ә сөйләм субъектына карата

да мөнәсәбәт чагылдыралар (*Абыстакай Нәгыймә*). Кешенең төс-кыяфәтен, хәрәкәтләрен, тормышка карашын характерлый торган кушаматлар арасында тискәре семантикага ия сүзләр дә урын алган (*Тешләк Әзһәр*). Квалитатив принцип нигезендә, теге яки бу сүзнең семантик тулылыгына басым ясаган кушаматлар персонажның тышкы кыяфәт үзенчәлекләрен сыйфатлыйлар. Мәсәлән, Вәрәшбаш авылында физик эшне яратып эшләгәнгә тагылган *Дию* кушаматының бирелү-кушылу мотивы түбәндәгечә аңлатыла: «*Салам төяргә барса, бер арба саламны ике генә күтәреп салган, эскертләүгә барса, бер чүмәлә печәнне өч чатлы агач сәнәк белән эскерт башына очырган. «Дию пәриеме әллә син, ник шулкадәр күтәрәсең»,– ди икән хатыны Икълимә апа. Шуннан киткән инде ул «Дию»гә әйләнеп*». Кушаматларның семантикасы кешенең реаль үзенчәлекләрен, иҗтимагый береккән сыйфатларын «билге» итә. Әлеге билгеләр аерым бер коллективта гына түгел, аерым бер гаилә эчендә дә идентификацияләнә. Коллектив эчендә кушаматлар шәхес тарафыннан актив реальләшәләр, коллективтан тыш пассивлашалар.

Топонимнарга яки микротопонимнарга нигезләнеп ясалган кушаматлар, башлыча, шәхеснең нинди торак пункттан булуына яки кая да булса барып кайтуына мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килеп, этнокультур тирәлеген билгелиләр: *Нәдер тау башы Тәбҗидә* һ.б.

Шәхеснең кәсебе-һөнәренә, профессиясенә яки эшләү урынына мөнәсәбәтле кушаматлар да чагылыш таба. Мондый кушаматлар күбесе хәзерге профессия атамаларына нигезләнеп ясалганнар. Шулай ук хәзерге вакытта онытылып бара торган һөнәр, кәсеп исемнәренә нисбәтле кушаматларның да очравы күзәтелә: *Сунарчы Сәбәк, Атҗабар Минниса, Итекче Җиһанша, Тимерче Нотфый; Көтүче Хөснетдин, Прит Әлфинур, Силсәвит Мәдинә, Умартачы Равил* һ.б. Шәхеснең яки аның ата-бабаларының титулына, социаль чыгышына мөнәсәбәтле кушаматлар да очрый: *Зимагур Булат, Алпавыт Шәйхи, Зимагур* һ.б. Шулай ук хәзерге вакытта онытылып бара торган һөнәр, кәсеп исемнәренә нисбәтле кушаматларның да очравы күзәтелә: *Умартачы Мирзаян, Чөгендерче Заһид, Биюче Ләйсән, Чәкчәк Сәвия, Экономист, Сөтче Бибинур, Гармунчы Данил, Җырчы Фаил, Яшелчәче Камәрия, Биюче Кәримә, Лесник Зәкәрия, Тракторчы Фәһимә, Астроном Расих* һ.б. Мисал итеп, Вәрәшбаш авылында кушамат тагылуның түбәндәге мотивы күрсәтелә: «*«Тегүче Вәли» кушаматы һөнәренә бәйле рәвештә тагылган. Ләкин Вәли абзый гади тегүче генә түгел, ул толыплар, туннар, пальтолар тегүче оста иде*».

Шәхес белән бәйләнешле берәр кызыклы вакыйга яисә аңа карата әйтелгән нинди дә булса көлкеле сүзгә нисбәтле кушаматлар да аерым урын тоталар. Мәсәлән, Мөслим районында *Яшел Күзлек* кушаматының килеп

чыгышы түбәндәге вакыйгага нисбәтле барлыкка килә: «*1960–1970-нче елларда колхозчыга бер сыер асрарга да мөмкинлек булмый. Бер төркем кешеләр, колхоз идарәсе буенда зарланышып торалар икән. «Сыерга ашатырга печән бетте, нишләргә инде», – дип. Шулвакытта Насертдин бабай (ул вакытта бабай иде инде) тыйнак кына әйтеп куйган: «Сез, егетләр, сыерларыгызның күзенә яшел күзлек бәйләп куегыз, саламны печән дип белерләр», – ди икән. Бөтенесе рәхәтләнеп, егыла-егыла көлгәннәр. Шуннан «Яшел күзлек» кушаматы тагылып калган*».

Кушаматлар эмоциональ-экспрессив тирәлектә барлыкка килеп, телнең этнокультур тирәлеге моделен гәүдәләндерәләр. Кушаматларга эмоциональ, экспрессив яки эмоцональ-бәяләү вазифалары хас. Алар объектив реальлектән сайлап алынган һәм танып-белгән процессны чагылдыралар. Теге яки бу коллективка таныш кешенең сыйфаты кушаматларда предметлыкка һәм танып-белүгә хас конкретлык аша чагыла. Аларның сематикасы конкретлыктан абстрактлыкка, абстрактлык аша сенсорлыкка омтыла. Бер яктан карაганда, кушаматларга традицион бәяләү хас булса, икенче яктан, кушаматлар шәхси, иҗади күзаллауларны коннотатив тулыландыралар. Кушаматлар, традицион халык культурасы элементы буларак, милли үзаңны формалашу өлешен тәшкил итәләр һәм милли культурага яраклаштыралар.

## Кушаматлар тарихы

***Чәүкә Хәмәте***

1955–1957-нче елларда колхоз басуларына квадрат – оялап кукуруз чәчә башладылар. Махсус эш коралы белән башта басуга квадрат ясап чыгалар. Шул квадратларга кул белән 1–2 орлык күмдерәләр. Бу эшкә мәктәп балаларын тарталар. Балалар кайтып китүгә, басуга карга, чәүкә ябырыла. Бригадир ярдәмчесе Хәмәт абый басуга каравылчылар куя, алар карга, чәүкәләрне куып торалар. Кошларны куркыту өчен төрле җайланмалар, карачкылар куялар. Шушы эшләр белән җитәкчелек иткәнгә, Хәмәт абыйга «Чәүкә» кушаматы ябышып кала.

***Мәзәк***

Торна Хәбибулла абзый малае Әбүзәр өй түбәсендә морҗа чистартып тора икән. Бу хәл яз көне була инде. Ул вакытта өйләр утын белән җылытыла бит. Яз көне, өй юганчы, морҗаны озын пумала белән корымнан чистарталар. Шул эшне безнең авылда «морҗа чөшкенләү» диләр. Әбүзәр абзый шул эш белән мәшгуль икән. Түрләреннән Хәмәт абзый үтеп бара, ди. Сөйләшеп киткәннәр. Хәмәт абзый аларның кушаматларына төрттереп:

– Бәй, торналар килеп тә җитте мени инде, – ди икән. Әбүзәр дә җор телле, сүз эзләп кеше кесәсенә керә торганнардан түгел.

– Әйе, менә чәүкәләр ояламасын, дип, морҗаны чистартам әле, – ди икән.

***Шүкә Кәшби***

Авылыбызда шактый кырыс табигатьле, таләпчән Кәшферазый абзый яши иде. Озак еллар Мөслим районы авылларында партия оешмасы җитәкчесе булып эшләде. Соңыннан үзебезнең Вәрәшбаш авылында бригадир булды. Лаеклы ялга чыккач, балык тоту белән мавыгып китте. Имәнле авылы янындагы күлләргә барып зур-зур балыклар тотып кайта иде, мәрхүм. Үзебезнең авыл янындагы буага да еш йөрде ул, һич буш кайтмады. Күршесендәге Нәгыймә әбигә дә бу балыклардан өлеш чыгара торган булган. Нәгыймә әби сорый икән:

– Бу ни дигән балык соң, Кәшби улым?

– Болар, Нәгыймә әби, шүкә балыклары, – ди икән тегесе.

Ә Нәгыймә әбигә кеше күп килә, хәерен, бүләк-санагын һаман китереп торалар, чөнки ул бик тәмле телле, дога укырга да бик оста, моңлы итеп Коръән сүрәләрен, төрле мөнәҗәтләр дә укый белә иде. Килгән бер кешегә: «Кәшферазый улым балык кертте әле, шүкә балыклары», – дип сөйли икән. Менә шулай итеп, Кәшферазый абзыйга “Шүкә” кушаматы тагылды да калды. Кушамат тагылуга мондый исемдәге кешеләрнең икәү булуы да тәэсир иткәндер.

***Борчак Расих***

Җәйге эссе көн, койма кырындагы күләгәдә 3–4 яшьлек малай уйнап утыра. Авылның электригы Расих үтеп бара. Теге бала:

– Исәнме, Борчак абый, – дип сәлам бирә.

– Әй, малай, кем әйтте сиңа мине борчак дип, Расих абыең булам мин, – ди икән электрик. Бәләкәй малай курка кала.

– Бәй, әти дә, әни дә сине «Борчак» диләр бит, – ди икән шәрә малай.

Шушы урында бер истәлек сөйләп китәсе килә. Бер төркем бала-чага, басу каравылчысыннан качып кына борчак ашарга киттек. Борчакның каешланып җитешкән чагы бу, бик тәмле чагы. Туйганчы ашадык борчакны. Меңкаран чишмәсенә төшеп су эчтек. Бераздан эчебез авырта башлады. Ике көнсез бетмәде бу авырту. Бөтенебезне «күбенгән борчак» дип үрти башладылар. Бераздан онытылды бу кушамат. Ләкин Расихка ябышып калды. Кыска буйлы һәм шактый таза гәүдәле булган өчен аңа «Борчак» кушаматы тактылар. Кушамат тагуга иң беренче олы кешеләр сәбәпче бит, балалар шулардан үрнәк ала.

***Бай Галимҗан***

Авылның иң оста рәссамы. Безнең авылга ул 1962–1963-нче елларда кайтты. Чыгышы белән Иске Вәрәш авылыннан. Безнең авылга күчүенең та-

рихы болай. Галимҗан абзыйның сеңлесе Фәрдәнә (ата бер, ана башка) безнең авылның Идрисов Марсель исемле кешесенә кияүгә чыкты. Фәрдәнәнең әнисе дә безнең авылга күчеп килде, чөнки бик карт иде. Галимҗан абый Магаданнан үги әнисе Мәһираван әби янына кайтты. Бик бай кайтты. Авылда беренче телевизор алучы да ул булды. Бөтен авыл халкы аларга телевизор карарга йөрде. «Моның кешеләре каян килеп чыга соң?» – дип, авыл өлкәннәре телевизорның артларын карап йөри торган булганнар. Гомумән, ул елларда Галимҗан абзыйның өе клуб хезмәтен үтәде. Ә Магаданга ул ипи карточкалары ясаган өчен эләгә. Сугыш (1941–1945) вакытлары була ул. Сталинны ишәккә атландырып ясаган, шуның өчен кулга алганнар, дигән сүзләр дә йөри халык арасында. Галимҗан абзый гаҗәеп оста рәссам иде. Бервакыт Гамирҗан абый Дәүләтшин мондый вакыйга сөйләде. Мөслимдә Кузьма Иванов исемле бик оста рәссам бар, Галимҗан абзыйларның туганы инде ул. Шул Кузьма белән Галимҗан абзый бәхәсләшеп киткәннәр. Кем 10 минут эчендә Ленин рәсемен ясый ала? Галимҗан абзый 4–5 сызык сызган да, 2 минут эчендә Ленин башын ясап та куйган.

«Бай» кушаматы тагылып калуның сәбәбе – авылда Галимҗаннарның өчәү булуында. Икенчесе – «Камали Галимҗаны», бабасы Камалиев булганга шулай атыйлар, өченчесе – «Ахун Галимҗаны». Ахунҗанов фамилиясеннән бозып ясалган.

***Карпыч – Исрафилов Тәлгать***

Төп безнең авыл кешесе. Армиядә хезмәт иткәннән соң, Чиләбе янындагы «Маяк» атом электр станциясендә эшли. «Маяк»та авария вакытында да шунда була әле ул. Рус кызы Галинага өйләнгәч, авылга кайтып төпләнәләр. Тәлгать абый гомергә җаваплы эшләрдә эшләде. Механик, бригадир, ферма мөдире, авыл Советы рәисе һ.б. Халык арасында кушамат тагылу сәбәпләренең төрле вариантлары яши.

Беренчесе. 1970-нче елларда Вәрәшбаш авылында зур, өсте ябулы ындыр табагы ясадылар. Тәлгать абый, механик буларак, эшчеләргә ярдәм итеп йөрде. Төзүчеләрнең берсе Карпов фамилияле булган. Тәлгать абый аңа гел «Карпыч» дип эндәшә икән. Күрәсең, бу сүзне еш кабатлагандыр инде, үзенә дә «Карпыч» кушаматы ябышып калган.

Икенчесе. Тәлгать абый рус кызына өйләнгән, дигән идек бит. Хатыны Галя апа да, әби-бабай да аңа үзләренчә Толя–Анатолий дип дәшкәннәр. Атаклы шахматчы да Анатолий исемле бит, фамилиясе Карпов. Шуннан тагылган кушамат, диләр.

***Сакчыл Хәернас***

Сабантуй. Түбән очтан җигүле арба белән берәү бәйрәмгә менеп килә. Арбасын тутырып яшел печән төягән. Дилбегәне 13–14 яшьләрдәге бер

үсмер тоткан. Арбада берсеннән-берсе нәни 4 кыз. Өстенә печән капланган кечкенә мичкә дә күренә. Аның кырында кукраеп җиз самовар урын алган. Балаларның әнисе (ул Мәхмүзә исемле), ак читле кызыл ашъяулыкка төрелгән Сабантуй күчтәнәчләре тотып, арбаның артындарак утыра. Ә хуҗа кеше, Хәернас абзый инде ул, аягын салындырып арбаның читенә утырган. Аякта – яхшы хром итек, өстә – ак күлмәк. Ә кулда – кыңгыраулы гармун. Ат салмак кына атлый, шул уңайга авыл өстенә кыңгыраулы гармуннан моң агыла. Хәернас абзый гаиләсе белән Сабантуйга бара. Сабантуй мәйданы әллә ни ерак түгел, югыйсә, җәяү дә барып булыр иде. Ләкин шушы кечкенә гармун моңы, атның пошкыра-пошкыра моң тавышына изрәгәндәй атлавы, арба артыннан ияргән матур күлмәкле бала-чагалар авылга ниндидер үзенчәлекле ямь өсти, бәйрәм төсе бирә.

Менә ат Сабантуй мәйданы булачак урынга килеп җитте, уңга борылып, бәрәңге бакчаларын әйләндереп алган киртә буена килеп туктады. Үсмер малай (ул Радик исемле) аттан сикереп төште дә аны тугарып печәнгә кушты, бахбай рәхәтләнеп яшел печәнгә сузылды. Хәернас абзый белән Мәхмүзә апа чәй урыны әзерли башладылар, самовар куеп җибәрделәр. Ул арада абзыйның кордашлары да килеп җитте. Теге арба башындагы кечкенә мичкә дә «кузгалды». Озакламый чәй дә кайнап чыкты. Бәйрәм кызды. Хәернас абзыйның кулыннан гармуны һич төшми, әле биетә кешеләрне, әле җырлата, Мәхмүзә апа аларны чәй белән сыйлый. Икесе дә мәрхүмнәр инде. Үтә сакчыл (кушамат шуннан), бик тә тырыш кешеләр булдылар. Эшли белгән кеше ял да итә белә бит ул. Мул яшәделәр, ләкин саран түгелләр иде, кызлары белән уйнарга барсаң, сез ятим балалар, дип, тамакны туйдырмыйча җибәрмәделәр.

***Кырау Марсель***

Авылда алдынгы комбайнчы Марсель абый бар иде. Сүзгә кесәгә керми торган, җор телле иде ул. Юк кына нәрсәне дә кызык итеп сөйләп, кешеләрне көлдереп тәм таба иде. Тыңлаучылар егыла-егыла көлә, эчләрен тотып бөгелеп төшәләр. Язгы кырау суккан кебек, бөтен кеше егылып көлгәнгә, шундый кушамат тагылгандыр инде. Кырыс табигатьле булганга, бу сүзне үзенә әйтергә куркалар иде. Үзе белдеме икән ул шундый кушаматы булуын.

***Бүреләр***

«Бүре» кушаматы иң беренче Дәүләт абзыйга тагылган. Сугыштан соңгы авыр еллар. Дәүләт абзыйның берсеннән-берсе кечкенә 8 баласы бар. Аларның тамакларын туйдырасы, өс-башларына юнәтәсе бар. Колхозчыларның «таякка» эшләгән еллары бу. Бер көн эшлисең – бер таяк сызыла, ике көн эшлисең – ике таяк. Шул рәвешчә, ел буе. Икмәк суккач, таякларны санайлар. Бер таяк башына 200 яки 300 гр икмәк бүләләр. Менә шулар белән 10

җанны асрарга кирәк. Колхозчыларның эшләсәң дә шул бер таяк, эшләмәсәң дә шул бер таяк, дип йөргән заманнары. Күбесе эшләмичә, күренеп кенә китү ягында. Көн буе тәмәке тартып, ял итеп ятсалар да була. Ә Дәүләт абзый алай эшли алмый. Аңа балаларын үстерергә кирәк. Абзыең бригадир әйткән эшкә бара, әйтик, салам эскертләргә, ди. Үзенә тиешлесен һич туктамыйча эшли-эшли дә кайтып китә икән бу. Бер ыргытканда эскерт башына бер чүмәлә (кечерәк бер ат йөге кадәр) саламны ыргыта иде, дип сөйли замандашлары. Шундый көчле кеше була ул. Өендә итек баса (ул эшнең дә остасы иде) яки урманга китеп зелпе тамыры җыя. Зелпе агачының тамыр кабыгыннан каучук ясаганнар. Шул кабыкны урманчыга (лесник) тапшырып, азмы-күпме акча алган яки кемгә дә булса бура бураган, өй салган. Бригадир да, колхоз рәисе дә моның холкын сындыра алмаганнар. Авылда яшәргә мөмкинлек тә бирмәгәннәр һәм ул Чаллы якларына китеп, бер лесхозга эшкә урнаша. Гаиләсен дә шунда алып китә. Лаеклы ялга чыкканчы шунда эшләп, күрше авылга кайтып төпләнде. 90 яшенә тикле мал асрап яшәде.

Кече малае сөйләгәннәрдән:

– Әти белән печән чабарга киттек. Мин бер-ике покос чабам да, ял итеп алам, ә ул һич туктап тормыйча 5 сәгать буе печән чапты. Яше 86да, күзе дә юньләп күрми, югыйсә. Менә шундый үзенчәлекле үҗәт холкы өчен тагылгандыр инде ул кушамат.

Ә алда телгә алынган Нурмый абый һәм Нәһиягә ул кушамат ни өчен тагылды икән? Бәлки аларның да холыкларында Дәүләт абзый холкы белән аваздаш яклар булгандыр.

***Көрәшче Дәүләт***

***Хуҗин Дәүләт***

Бөек Ватан сугышы ветераны Дәүләт абзый кечкенә буйлы, чандыр кеше иде. Сугышта күп батырлыклар күрсәтеп, орден-медальләр белән бүләкләнеп кайткан иде ул. Сабантуйларда үзеннән зур гәүдәле егетләрне дә аркасына сала торган булган. Кулы корыч кебек каты, гәүдәсе мускуллардан гына тора иде. Шуның өчен «Көрәшче» кушаматы тагылган.

Хуҗин Дәүләт. Татарлар арасында кешене фамилиясе белән атау бөтенләй юк, диярлек. Ә Дәүләт абыйны Хуҗин дип кенә йөртәләр. Ул бик алдынгы тракторчы иде. Башта чылбырлы, аннан соң тәгәрмәчле тракторда эшләде. Ел азагында иң күп икмәк алучы да – Хуҗин, авылда иң мул яшәүчеләр дә – Хуҗиннар.

***Чемети Вәли***

Чемети Вәли абзыйларның өе Мулла бакчасына терәлеп тора иде. Сугыштан кайткач, ул үзенең гаиләсе белән Үзбәкстан якларына китеп

төпләнде. Озын буйлы, киң җилкәле, чибәр кеше иде Вәли абзый, әмма бер гадәте бар: ачуы чыкса, дәшми – чеметеп кенә ала. Кушамат шуның өчен тагылган.

***Пычак Вәли***

«Пычак Вәли» абзыйларның өе, хәзерге Рахманов Әбүзәрләр янында иде. Авылдагы бөтен кешегә Вәли абзый пычак ясый. Кушамат шул һөнәренә нигезләнеп ясалган.

***Тегүче Вәли***

Бу кушамат та һөнәренә бәйле рәвештә тагылган. Ләкин Вәли абзый гади тегүче генә түгел, ул толыплар, туннар, пальтолар тегүче оста иде.

**Әдәбият**


1. Писцовая книга Казанского уезда 1647–1656 годов: Публикация текста. М.: Институт Российской истории РАН, 2001.
2. Писцовые книги Казанского уезда 1685–1687 гг.: публикация описаний Зюрейской дороги / изд. подгот. Д. А. Мустафиной. Казань: Казанский государственный университет, 2009.
3. Подольская Н. В. Словарь русский ономастической терминологии / Н. В. Подольская. М.: Наука, 1988.
4. Ревизская сказка о купцах мещанах и цеховых г. Казани русского и татарского сословиях (1891–1879) // ЦГА РТ. Ф 3. Оп. 2.
5. Саттаров Г. Ф. Татарларда кушаматлар / Г. Ф. Саттаров // Совет мәктәбе, 1973, № 9.
6. Становление и расцвет Золотой Орды. Источники по истории Улуса Джучи (1266–1359 гг.). Казань: Татар. кн. изд-во, 2011.
7. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 2005.
8. Хаҗиева Г. С. Телнең этнокультур пространствосында татар кушаматлары / Г. С. Хаҗиева // Актуальные проблемы современной фольклористики. Вып. 1. Казань: Ихлас, 2017.
9. Энциклопедический словарь-справочник лингвистических терминов и понятий. Русский язык: в 2-х томах / А. Н. Тихонов, Р. И. Хашимов, Г. С. Журавлева и др. / под общ. ред. А. Н. Тихонова, Р. И. Хашимова. Т. 1. М.: Флинта: Наука, 2008.
10. Tekin T. Orhon Yazıtları. Ankara: Türk Dil Kurumu, 2008.

***Раис Яушев***

# ИЗ ОПЫТА РЕКОНСТРУКЦИИ РОДОСЛОВНОЙ

*(Акмолинские Яушевы)*

Мое детство и школьные годы прошли в Караганде. В раннем детстве я часто подолгу рассматривал фотографию времён I мировой войны Ахметгали бабая, которого никогда не видел живым. Так у меня пробудился интерес к истории семьи. Тогда же в начале 1980-х еще принято было регулярно собираться с родственниками в большом кругу, и когда неизбежно речь заходила о былых временах, всегда с гордостью вспоминали две семейные легенды. Одна гласит, что после покорения Иваном Грозным Казанского ханства он предложил мурзам сохранить их права на землю, лес и иные угодья в обмен на отказ от веры предков. Все дворянское сословие покорно согласилось сохранить богатства, и только два рода отказались креститься, среди них были Яушевы, в результате чего семья постепенно обеднела. По второй легенде наш прямой предок князь Яушев служил в личной охране царицы Софьи, в 1682–1689 гг. бывшей регентом при младших братьях Петре (будущий Петр I) и Иване.

Связь между Яушевыми из Акмуллы (так татары называли Акмолинск–Целиноград–Астана–Нурсултан, ныне столица Казахстана) и Татарстана была утеряна в годы сталинского террора. Для потомков дворян и купцов знакомая история. По прошествии многих лет у них встал вопрос: кто наши предки?

Политика физического уничтожения всех потенциальных противников советской власти наводила жуткий страх на дворян и дореволюционную интеллигенцию. Так, мой дед Ахметгали Шангараевич Яушев, после информации, полученной от родственников со стороны жены Муксиновых, работников акмолинского НКВД, долгое время «сидел на чемоданах» в ожидании ареста и высылки в лагеря ГУЛАГа. Возможно, непрестижная работа рентгенологом спасла ему жизнь в тот момент, но в то же время стала причиной преждевременной смерти от рака в последующем. Во время этих событий Ахмет Яушев мог уничтожить документы, свидетельствующие о мурзинском происхождении. В любом случае он избегал в разговорах с детьми темы о далеких предках и своей биографии в дореволюционный период.

Тем не менее, до нас дошла в устном виде информация, пусть и скудная, от Марьям Яушевой (умерла в 1982), в основном благодаря ее ясному уму и памяти в глубокой старости (она прожила более 90 лет). От нее мы, акмолинские Яушевы, знаем, что в нашем предком был ясновидец

Габбас хаджи Яушев. Важным информатором для меня по истории семьи Яушевых была моя мама Альбина (урожденная Гимаева). Она живо интересовалась членами большой семьи Яушевых и увлечённо рассказывала мне их жизненные истории.



*Приказчики Ахметгали (1-й в ряду) и Темиргали (3-й в ряду) Яушевы. Акмолинск. Примерно 1910 г.*

По словам Марьям Кабир кызы Яушевой, в 12 лет Шангарай (Шахингарай) Исмагыйл улы Яушев (видимо во 2-й половине XIX в.) в поисках лучшей жизни приехал с братом из Татарстана (его у нас называли «Казан яклары», т. е. «из-под Казани») в Кызылжар (Петропавловск) к сестре замужней за казахским баем. У Шангарая и Камили в Казахстане родились сыновья Темиргали (1883–1952) и Ахметгали (1987–1951), дочери Рабига (18??–1942) и Халима (18??–1955). Семья на гостеприимной казахской земле жила хорошо. Хамза, сын Рабиги, вспоминал, что

его старший брат Шарип, уже в советское время частенько с сожалением говорил: «Эх, прошли времена Камили аби». Оба сына были образованными людьми по меркам своего времени (требование знания Корана обуславливало среди татар почти 100% умение читать и писать), знали татарский, казахский и русский языки, а потому работали приказчиками у самых крупных акмолинских русских купцов Семенова и Кубрина. Занимались тем, что брали на реализацию товар, ездили торговать по аулам, и по ее результатам получали комиссионное вознаграждение. По словам Бибинур Абубакировой (1903–1982), за хорошую работу мужа Ахметгали купец ее нередко одаривал отрезами на платье.

Их сын Рустем ребенком слышал из истории семьи как Марьям спрашивала у Ахметгали: «Мы из рода Карабая?» Возможно речь шла о легендарном Карабеке из Карино. Если это так, то предки Яуша или он сам были знаменитыми каринскими князьями. К данному выводу независимо от нас много лет назад пришел Дамир Исхаков, он изложен во многих его трудах, к примеру, в недавно вышедшей монографии «История рода Яушевых в средневековый период и Кимакская проблема».

По рассказам Марьям Яушевой и Бибинур Абубакировой, когда Ахметгали Яушеву было примерно 8–9 лет к ним приехали в гости родственники, тоже Яушевы, у которых не было сына, и они захотели усыновить Ахмета. Мальчик вначале согласился, но когда наступило время отъезда, он сильно расплакался и не захотел уезжать. Родители и родственники, приехавшие в гости, пожалели ребенка и не стали настаивать на отъезде его из дома. Предположительно приезжал троицкий миллионер Муллагали Яушев (1864–1927). Как известно, у него была единственная дочь Разия, в будущем мать известного советского арабиста, журналиста-международника и телеведущего Фарид Сейфуль-Мулюкова.

Темиргали Шангарай улы Яушев (1883–1952), старший брат Ахметгали, долго не был женат, тогда ему сосватали в 1912 г. из Татарстана («Казан яклары») двоюродную сестру Марьям Яушеву. У Марьям был в Казани брат Гарифкан, репрессированный в 1937–38 гг., а в Петропавловске – сестры Махи и Акрям.

Стоит отметить еще один эпизод из жизни Яушевых в Акмолинске. По рассказам Марьям Яушевой, после ее переезда в Казахстан случай позволил ей вновь встретиться во время Гражданской войны со своим двоюродным братом, поручиком царской армии, Ибрагимом Яушевым, который в составе Белой армии (возможно в частях атаманов Дутова или Семенова) отступал под натиском красных через Акмолинск в Китай. Из несохранившейся статьи (журнал «Казан утлары», 80-е годы) мы знаем, что некий Ибрагим Яушев жил и в США.

Мы, акмолинские Яушевы, еще до перестройки–времени, когда возродился интерес к собственным корням, когда люди снова стали не боясь задавать себе вопрос «Кто мы?»–знали о принадлежности к известному мурзинскому роду Яушевых. Оставалось дело «за малым»: заново найти себя.

Из вышеизложенного мы имели следующие семейные предания, на которые можно было опираться при реконструкции родословной:

1. Семья обеднела во времена Ивана Грозного.
2. Прямой предок служил в личной охране царицы Софьи.
3. Мы являемся потомками известного ясновидца Габбас хаджи Яушева.
4. Шангарай родился в Татарстане («Казан яклары»).
5. Шангарай с братом в 12 лет переехал в Петропавловск.
6. Отца Шангарая звали Исмагыйль.
7. Жену Шангарая звали Камиля.
8. Марьям, жена Темиргали, родилась в под Казанью примерно в 1890 г.
9. Отца Марьям звали Кабир.
10. Марьям и Темиргали поженились в 1912 г.
11. Марьям была двоюродной сестрой Темиргали.
12. У Марьям в Петропавловске проживало две сестры: Махи и Акрям.
13. У Марьям в Казани был брат Гарифкан, репрессированный в 1937–38 гг.
14. У Марьям был брат Ибрагим.
15. Бездетная, но богатая семья из рода Яушевых приезжала усыновить Ахметгали.

Поиск родового села проводился в 2014 г. кандидатом исторических наук, старшим научным сотрудником Института истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан Ильшатом Файзрахмановым. Упоминание Габбас хаджи говорило, что начинать искать надо с с. Кошар, Атнинского района, Республики Татарстан. Найденная информация в ревизских сказках и метрических книгах о рождении и бракосочетании по с. Кошар, архивные дела, подтвердили семейные предания:

1. После взятия Казани в 1552 г. семья не обеднела, даже обогатилась, обеднела позже, во времена Петра I. Багыш сын Яуша по жалованной грамоте получил в 1582 г. от Ивана Грозного целую волость Терьса (ныне на этой земле стоят города Ижевск и Агрыз). Данный факт можно объяснить тем, что для России это был первый опыт завоевания соседнего государства, и новая администрация оказалась неготова управлять вновь присоединенной территорией, населенной

народом, будучи далеко от его быта, языка и культуры. В таком случае наиболее разумный способ – это опереться на существовавшие институты власти в лице чиновников и мурз Казанского ханства, сохранить ясачное налоговое право. Новая политика с приходом Петра I и продолженная Анной Иоановной в отношении инородцев вынудила служилых мурз Яушевых из дд. Кошар и Старый Менгер Алацкой дороги продать по купчей грамоте от 09.08.1733 г. переводчику государственной коллегии иностранных дел Мамету Мамешеву (Алексею Ивановичу) сыну Тевкелеву, принадлежавшую им «Большетерсинскую волость з деревнями, з дворовыми людьми и со крестьяны» за 3000 руб. [РГАДА. Ф. 615. Оп. 1. Д. 12202. Л. 61. об. 62]. Впоследствии А. И. Тевкелев 27.07.1765 г. за земли по р. Иж, купленные в 1733 г. у Яушевых, получил компенсацию, так как на них был самовольно построен Ижевский железо(меде)-плавильный завод. Строил казенный завод с 1758 г. генерал-фельдмаршал граф Петр Иванович Шувалов (1711–1762) (Доношение Берг-Коллегии в Правительствующий Сенат об истории строительства Ижевского железоделательного завода и о решении вопроса по землям генерал-майора А. И. Тевкелева от 31.08.1764 г. [РГАДА. Ф. 248. Д. 21/3592. Л. 846–846 об.]

2. Прямыми нашими предками являются ротмистр Богдан (16?? г. р.) и его сын ротмистр Мустафа (1667–1742). Относилась ли рота, в которой они служили, к охране царицы Софьи, установить не удалось. Но период их службы может совпадать с временем правления Софьи (дело «По прошению Казанской губернии и уезда деревни Кошар из татар от мурзы Ахмера Монасыпова Яушева о утверждении его с сыном Мухаметом Фейсом в княжеском достоинстве» [НА РТ. Ф. 168. Оп. 1. Д. 685].
3. Габбас хазрат в нашем роду был, но по линии Камили (жены Шахингарая), он ей приходится дедушкой.
4. Шахингарай родился в 1847 г. в с. Кошар, в ревизской сказке 1858 г. в русской транскрипции именуется Шаингарей.
5. У Шахингарея было пять родных братьев (Искак, Абдулвалей, Хабибзямал, Мухаметшакир, Мухаметзакир), переезжал ли кто из них жить в Петропавловск или это был их двоюродный брат, выяснить не удалось. Установлено рождение у Шахингарея 05.01.1875 г. в с. Кошар дочери Бибимаймуны, что делает маловероятным его переезд в г. Петропавловск в раннем возрасте.
6. Исмагыйль (1790–1856), отец Шахингарея, согласно ревизских сказок 1834 г. и 1858 г., в русской транскрипции именуется Смаил.

7. Жену Шахингарея действительно звали Камиля (метрика о бракосочетании от 22.11.1865 г.). Дополнительно выяснилось, что Камиля (1848 г.р., ревизская сказка 1858 г.) тоже была Яушевой, с мужем Шахингареем они были братом и сестрой в десятом (!) поколении, потомками легендарного князя Багыша.
8. Марьям родилась в с. Кошар (15.08.1889 г., метрика о рождении), ее полное имя Бибимарьям.
9. Полное имя Кабира, отца Марьям, Габделькабир (1837 г.р., ревизская сказка 1858 г.).
10. Марьям и Темиргали действительно поженились в 1912 г. (метрика об их бракосочетании от 13.03.1912 г.). Что примечательно: метрика, по правилам того времени, оформлена в родовом селе невесты с. Кошар – месте проведения никаха. Ездил ли Темиргали за 2000 км в с. Кошар? Похоже, да.
11. Марьям и Темиргали действительно были двоюродными братом и сестрой, их отец и мать (Габделькабир и Камиля) были родными братом и сестрой.
12. У Марьям в с. Кошар родились сестры Махи и Акрам, их полные имена Махибадар (22.08.1873 г.р., метрика о рождении) и Бибиакрамниса (12.02.1887 г.р., метрика о рождении).
13. В Казани действительно проживал Гарифкан Яушев (1901–1938). Однако, Гарифкан Яушев был не двоюродным братом, а племянником Марьям, его отец Касымхан (29.09.1870–1945) приходится ей родным братом. Гарифкан заведовал отделом культуры в обкоме КПСС ТАССР, был выдвинут на вновь образовавшуюся должность Министра культуры Татарской АССР, но первым Министром культуры в истории Татарстана ему не суждено было стать, в этот момент он был арестован и репрессирован.
14. В метрических записях с. Кошар нашелся Ибрагим Яушев (23.01.1898 г.р.), сказать с уверенностью тот ли это Ибрагим, о котором говорила Бибимарьям, нельзя. Ответ на этот вопрос будет получен в том случае, если мы сможем проследить дальнейшую судьбу выявленного Ибрагима. Пока лишь ясно, что они оба Яушевы с общим предком легендарным князем Багышем.
15. Для проверки последней легенды необходимо будет переговорить с потомками Яушевых из Троицка.

Таким образом, семейные предания, которые часто и с трепетом рассказывались в семейном кругу, передавались из уст в уста, которые создавали невидимую связь с землей обетованной, нашли свое документальное подтверждение. В результате была реконструирована родословная:

Равиль (08.03.1937, Акмолинск), Рустем (14.10.1934, Акмолинск) бин Ахметгали (07.01.1887–20.08.1951), Темиргали (1883–1952) бин Шахингарай (1837, с. Кошар – 12.04.1907, Акмолинск) бин Исмагил (1790–1856) бин Мукмин (1754–18.01.1831) бин Госман (1724-??) б. Семеней (1690–1760) б. ротмистр Мустафа (1667–1742) бин глава роты Богдан бин Исеней морза (–1694) бин Семеней бек (из с.Кошар) бин Багыш бек бин Яуш бек бин Альсуфый бек бин Гали (Галим) (13??–1445) бек бин Кара бек (13??–1391) бин Канбар бек бин Калдар бек бин Балым бек бин Бачман хан (??–1237) бин Габдрахман султан бин Боняк хан (1050–1147) бин Бирде султан бин Элвар султан бин Габдельгазиз султан бин Гыйффат султан бин Сократ хаким (?).

В последствии при изучении метрических книг с. Кошар и Амолинска были обнаружены записи, лишний раз подтверждающие родство Яушевых из Акмуллы с Яушевыми из с. Кошар:

1. Бибикамиля родилась 06.07.1849 в с. Кошар Казанского уезда, отец Мухамметжан, мать Балхис [ЦГА РБ. Ф.И. 295. Оп. 9. Д. 94].
2. Бибирабига родилась 25.06.1873 в с. Кошар Казанского уезда, отец Шахингарай Исмагыйль улы, мать Бибикамиля [НА РТ. Ф. 204. Оп. 6. доп. Д. 78].
3. Ахметгали родился 07.01.1887 в Амолинске, отец Шахингарей Исмагыйль улы Яушев из деревни Кошар Казанского уезда, мать Бибикамиля Мухамметжан кызы.
4. Шахингарей умер 12.04.1907 в Акмолинске в возрасте 70 лет, отец Исмагыйль Яушев из д. Кошар Казанского уезда, причина: болезнь груди.

Род Яушевых – это пример духовной стойкости нашего народа, живое доказательство его древней государственности, и теперь мы по праву гордимся своим родом и будем стараться быть достойными его представителями.

**Источники**

1. НА РТ. Ф. 168. Оп. 1. Д. 685.
2. НА РТ. Ф. 204. Оп. 6. доп. Д. 78.
3. РГАДА. Ф. 248. Д. 21/3592. Л. 846–846 об.
4. РГАДА. Ф. 615. Оп. 1. Д. 12202. Л. 61 об–62.
5. ЦГА РБ. Ф. И–295. Оп. 9. Д. 94.

*И.З. Гарифуллин*

# ХРОНИКА ТАТАРСКОГО НАЦИОНАЛЬНОГО ДВИЖЕНИЯ БАШКОРТОСТАНА (1988–МАЙ 1992 г.)

*В данной публикации отражены основные события, связанные с деятельностью татарского национального движения Башкортостана в период с февраля 1988 г. по апрель 1992 г. Первая татарская национальная организация в республике была создана в марте 1988 г., но именно в феврале 1988 г. на пленуме ЦК КПСС член ЦК партии Егор Лигачев в своем выступлении от лица государства признал факт ущемления национальных прав татар Башкортостана.*

***17–18 февраля 1988 г.***

В Москве состоялся пленум ЦК КПСС, на котором выступил член ЦК КПСС Егор Лигачев. В своем выступлении он впервые на государственном уровне публично признал факты ущемления интересов татар, проживающих в Башкирской АССР в период правления первого секретаря Мидхата Шакирова.

***1988 г., 8 марта***

В Уфе во Дворце культуры завода резино-технических изделий состоялось собрание татарской общественности Уфы, на котором было принято решение о создании «Клуба татарской культуры, искусства, языка и литературы имени Г. Ибрагимова».

***1988 г., май***

Статья Айдара Халима «Язык мой – друг мой» в журнале «Дружба народов», в котором были озвучены факты башкиризации татар в период руководства БАССР Мидхатом Шакировым.

***1989 г., 14 января***

Учредительное собрание ТОЦ БАССР, на котором были обсуждены тезисы Платформы ТОЦ, а также принята Резолюция съезда с предложениями по решению национальных проблем татар Башкортостана. В их числе главное требование – вернуть татарскому языку статус государственного.

***1989 г., 20 сентября***

В газете «Кызыл таң» опубликована статья «Букварь нашей жизни», подписанная группой членов клуба татарской культуры им. Р. Ибрагимо-

ва под заголовком «Обсуждаем проект закона «Об изменениях и дополнениях Конституции БАССР»», где в ст. 99 говорится, что законы, указы, акты ВС БАССР издаются на русском и башкирском языках. Члены клуба предлагают добавить в ст. 99 «и на татарском», как было в Конституции 1937 г.

***1989 г., 15 октября***

В Уфе состоялось собрание татарской общественности Уфы и республики, где обсуждались проблемы развития татарской культуры, языка, открытия театров, издания книг на татарском языке и т. д.

***1990 г., 17 февраля***

В Уфе состоялась встреча Председателя временного бюро Башкирского обкома КПСС И. А. Горбунова, членов временного бюро, Председателя БНЦ «Урал» Р. Шакурова и Председателя ТОЦ М. Рамазанова с общественностью города Уфы, в которой приняли участие представители БАИД (Башкирская ассоциация избирателей и депутатов), республиканского совета общества охраны природы, клубов башкирской, татарской, чувашской, марийской, украинской, еврейской культур и других общественных организаций.

***1990 г., 6 марта***

В редакции газеты «Йәшлек» прошла беседа за «круглым столом» по вопросу о татаро-башкирских отношениях с участием ученых руководителей двух национальных центров, писателей, членов временного бюро обкома КПСС. В беседе принимали участие: профессора Башгосуниверситета М. Г. Сафаров, Д. Ж. Валеев, историк М. М. Кульшарипов, ответственный секретарь ТОЦ К. Яушев, член правления ТОЦ Н. Бадретдинов, члены временного бюро ОК КПСС М. Д. Рамазанов, Р. З. Шакуров, ответственный секретарь БНЦ «Урал» М. С. Буракаева, писатели Расих Ханнанов, Вил Гумеров.

***1990 г., 28 марта***

В газете «Кызыл таң» опубликовано открытое письмо представителей творческой и научной интеллигенции временному бюро Башкирского обкома КПСС, Президиуму ВС БАССР, Совету Министров БАССР, Министерству культуры БАССР о необходимости открытия в Уфе Татарского государственного театра.

***1990 г., 30 июня–1 июля***

В Уфе состоялся II курултай ТОЦ Башкирии.

***1990 г., 8 сентября***

Расширенный Пленум ТОЦ БАССР принял резолюцию о государственном суверенитете Башкирии, в которой отвергается принцип государственного суверенитета только одной нации, о придании башкирскому, русскому, татарскому языкам статуса государственных языков, о праве народов на создание национальных сельсоветов, пропорциональном представительстве в органах власти и т.д. В случае непринятия данных условий, ТОЦ начнет работу по созданию Уфимской области в составе РСФСР.

***1990 г., 5 октября***

На Советской площади Уфы писатель Айдар Халим установил палатку и объявил голодовку в знак протеста против ущемления прав татарского населения республики и с требованием прописать в Декларации о суверенитете Башкортостана пункт о придании татарскому языку статуса государственного. К нему присоединился рабочий Кадерле Имамутдинов.

***1990 г., 9 октября***

На Советской площади Уфы состоялся митинг, организованный ТОЦ по поводу суверенитета Башкирии.

***1990 г., 24 октября***

ВС БССР принял решение об издании самостоятельной газеты для молодежи на татарском языке. Учредителями газеты будут Сов. Мин. БССР и СДМБ.

***1990 г., 20 ноября***

В специальном выпуске союза татарской молодежи «Азатлык» (приложение к газете «Ленинец») опубликован Устав союза татарской молодежи «Азатлык».

***1990 г., 8 декабря***

Учредительный съезд партии «Идель-Урал».

Учредительный съезд Союза татарской молодежи «Азатлык» (Башкирия).

***1991 г., 25 января***

В газете «Кызыл таң» напечатано сообщение Уфимского клуба татарской культуры по поводу событий в Литве.

***1991 г., 22 февраля***

В газете «Кызыл таң» опубликовано обращение ТОЦ Башкирии к татарскому народу, проживающему в Башкирии, о невозможности в полной

мере удовлетворить потребности в издательском деле, в обучении на родном языке, об отсутствии передач по телевидению и радиовещанию и т.д.

***1991 г., 6 июня***

Обращение Уфимского клуба татарской культуры к народам Башкортостана с призывом не участвовать в выборах Президента РСФСР 12 июня 1991 г.

***1991 г., 8 июня***

У моста через р. Ик у Октябрьска на границе с Татарстаном состоялась акция «Река Ик – Берлинская стена», организованный Всесоюзным ТОЦ и ТОЦ Башкирии. Это стало самой громкой общественной акцией за всю историю ТОЦ Башкирии.

***1991 г., 23 июня***

В Уфе состоялось заседание Гали меджлис (Пленум) ТОЦ Башкирии по анализу татарских национальных проблем в Башкирии, на котором принята резолюция по вопросу образования в составе РСФСР Уфимской области (республики), в ответ на бездействие руководителей республики по решению проблем татарского населения.

***1991 г., с 22 июля по 2 августа***

В Казани состоялись Дни всемирной татарской молодежи, в которых участвовала делегация из Башкирии.

***1991 г., 27 июля***

Вышел первый номер молодежной газеты на татарском языке «Өмет» («Надежда»). Учредители Совмин БССР и СДМБ.

В газете «Кызыл таң» публикован репортаж о пресс-конференции проведенной ответственным секретарем ТОЦ Башкирии К. Яушевым после поездки в ВС РСФСР, где был вручен пакет предложений, выработанный ТОЦ БССР, на имя Б. Н. Ельцина по созданию на территории бывшей Уфимской губернии Уфимской области в составе РСФСР.

***1991 г., 10 октября***

В газете «Кызыл таң» печатается пакет предложений ТОЦ для обращения совместно с БНЦ «Урал» в ВС БССР, а также ответ БНЦ «Урал» по поводу предложений ТОЦ, где отвергаются многие пункты предложений ТОЦ.

***1991 г., 2 ноября***

Состоялся третий внеочередной курултай ТОЦ Башкирии, на котором были внесены изменения и дополнения в Устав ТОЦ.

***1991 г., 10 ноября***

На собрании татарской общественности в Уфе принято заявление, в котором сообщается об ущемлении татар в области языка, образования, об отсутствии передач на татарском языке по радио, телевидению, в кадровых вопросах и т. д.

Собрание решило начать сбор подписей за проведение референдума с целью воссоединения с Татарстаном тех районов, где проживают татары.

***1991 г., 22 ноября***

Вышел первый номер газеты «Идел-Урал» на татарском языке, орган Татарской демократической партии «Идель-Урал» и Уфимского клуба татарской культуры.

***1991 г., 19 декабря***

В газете «Кызыл таң» опубликовано открытое письмо писателей И. Абдуллина, Н. Нажми, Г. Рамазанова, композитора Р. Хасанова, народного депутата РСФСР, врача Э. Мулдашева Председателю ВС БССР М. Рахимову, Председателю Совмина БССР М. Миргазямову об создании в республике татарского книжного издательства.

***1992 г., 4 января***

Состоялся Пленум ТОЦ БССР, принявший «Обращение к населению, руководству нефтедобывающих районов Башкирии, в котором говорилось о необходимости оставления 50% доходов от добычи нефти в бюджетах районов», резолюцию «О VI внеочередном Всебашкирском курултае», резолюцию «О необходимости проведения неотложных мер по приватизации государственной собственности и земельной реформе», резолюцию «О двойном гражданстве для татар, живущих в Башкортостане» (Башкортостана и Татарстана).

На заседании Гали меджлис Председателем ТОЦ Башкортостана избран Карим Яушев, ранее исполнявший обязанности ответственного секретаря ТОЦ Башкирии.

***1992 г., 4 февраля***

В газете «Өмет» опубликовано письмо, принятое на собрании Уфимского клуба татарской культуры 29 декабря 1991 г. Председателю ВС БССР М. Рахимову, Президенту ТССР М. Шаймиеву, Председателю Совмина БССР М. Миргазямову, Председателю Совмина ТССР М. Сабирову с требованием выделения здания для клуба в Уфе.

***1992 г., 6 февраля***

В газете «Ленинец» опубликовано заявление Совета представителей Демократического конгресса Башкирии с осуждением национал-шовинистических сил республики, вставших на путь беззакония, произвола и шантажа. Совет представителей Демократического конгресса Башкирии расценивает политику национал-шовинизма БНЦ «Урал» и Союза башкирской молодежи как действия, провоцирующие межнациональный взрыв и гражданский пожар, и возлагает ответственность за разжигание межнациональной розни в республике на их лидеров, а также на попустительскую политику ВС, его Президиума и правоохранительных органов.

В газете «Кызыл таң» опубликован протокол заседания кафедры татарской филологии Башкирского государственного университета с повесткой дня: Предложения комиссии по подготовке проекта «Закона о языках». Заседание кафедры приняло решение:

1. Выразить недоверие комиссии по подготовке проекта «Закона о языках» в связи с несоблюдением национального состава и предложить создать комиссию заново.

2. Защитить принцип равноправия языков в республике, добиться придания статуса государственного языка башкирскому, татарскому и русскому языкам.

3. Выступить с обращением к татарской общественности, представителям интеллигенции, учителям, предпринимателям, родителям, чтобы они высказали свое мнение в защиту родного языка.

***1992 г., 8 февраля***

В газете «Өмет» публикуется сообщение о проходившем в Казани 1–2 февраля курултае татарского народа.

***1992 г., 21 февраля***

Обращение Уфимского клуба татарской культуры и Татарской демократической партии «Идель-Урал» к Президенту Республики Татарстан, ВС, Совмину Татарстана, общественным организациям, партиям, татарскому народу, где говорится о необходимости принятия закона о двойном гражданстве перед референдумом о государственной независимости.

***1992 г., март***

В газете «Идел-Урал» №3 опубликовано обращение Татарской демократической партии «Идель-Урал» по поводу ущемления национальных прав татар Башкортостана и обращение ТОЦ, ТДП «Идель-Урал», Уфимского клуба татарской культуры, СТМ «Азатлык» к депутатам-татарам с

призывом к созданию татарской депутатской фракции в ВС Республики Башкортостан.

***1992 г., 7 марта***

В газете «Кызыл таң» опубликовано открытое письмо коллектива этой газеты к Президенту Республики Татарстан М.Ш. Шаймиеву в связи с референдумом в Татарстане.

***1992 г., 12 марта***

В газете «Өмет» опубликовано открытое письмо татарской молодежи Башкортостана к Президенту Татарстана М.Ш. Шаймиеву с просьбой о предоставлении возможности принять участие в референдуме татарам, проживающим вне Республики Татарстан и объявить их гражданами Республики Татарстан.

***1992 г., 13 марта***

Нижнекарышский сельсовет Балтачевского района принял постановление о необходимости придания татарскому языку государственного статуса в Башкортостане.

***1992 г., 14, 17 марта***

В газетах «Ленинец» и «Советская Башкирия» опубликовано открытое письмо правления Башкирской республиканской организации народной партии «Свободная Россия» по проекту закона «О языках Республики Башкортостан», где говорится о необходимости придания статуса государственного языка 3-м языкам – башкирскому, татарскому и русскому.

***1992 г., 15 марта***

На Советской площади Уфы состоялся митинг-концерт в защиту референдума в Татарстане, организованный СБМ. Принята резолюция в поддержку референдума.

***1992 г., 18 марта***

В газете «Кызыл таң» опубликована Резолюция митинга, проведенного в Уфе в поддержку референдума в Татарстане. Митинг был организован и проведен ТОЦ Башкортостана.

***1992 г., 19 марта***

ТОЦ Башкортостана направил телеграмму Президенту России Б. Ельцину, Председателю ВС РФ Р. Хасбулатову, Президенту Татарстана М. Шаймиеву, Председателю ВС РТ Ф. Мухаметшину, Президенту ВТОЦ М. Мулюкову, в которой подчеркивается, что любая попытка применения

силы и введения экономической блокады против суверенного Татарстана со стороны имперских сил признается как акт, направленный против татарского народа, народов Поволжья и демократии. Мы твердо заявляем: Руки прочь от суверенного Татарстана!

***1992 г., 25–27 марта***

В Уфе впервые проводилась республиканская олимпиада по татарскому языку и литературе.

***1992 г., 23 апреля***

В газете «Өмет» опубликовано обращение к ТОЦ Башкирии, башкирскому народу, башкирскому национальному движению, башкирской молодежи, принятое Президиумом Всетатарского общественного центра, одобренное Ассоциацией тюркских народов, Союзом татарской молодежи «Азатлык», Ассоциацией тюркской молодежи и лидерами молодежного религиозного общества «Иман» 23 апреля 1992 г. в поддержку политической голодовки башкирской молодежи.

В Министерстве юстиции зарегистрированы уставы Башкирского народного конгресса, Ассоциации тюркских народов Башкортостана, Ассоциации студентов-юристов Башкортостана, Союза работников культуры Башкортостана, Башкирской республиканской ассоциации традиционной и народной медицины.

***1992 г., 25 апреля***

В Уфу из Татарстана прибыла делегация в составе 200 человек во главе с лидером партии «Иттифак», народным депутатом Татарстана Фаузией Байрамовой с целью поддержки участников политической голодовки.

Прошел курултай Союза татарской молодежи «Азатлык», на котором рассматривались вопросы утверждения плана работы на 1992 г., внесения изменений и дополнений в устав. По новому уставу, вместо одного председателя предусматривается пять сопредседателей. СТМ «Азатлык» вышел из состава «Комитета молодежных организаций».

В Уфе принята совместная рабочая программа общественно-политических организаций Татарстана и Башкортостана. Принята резолюция совместного митинга представителей Татарстана и Башкортостана по защите государственного суверенитета Башкортостана и Татарстана.

Состоялось расширенное заседание Гали меджлис ТОЦ Башкортостана с представителями всех татарских объединений Башкортостан с повесткой дня:

1. Новая Конституция Республики Башкортостан и статус татарского языка;

2. Подготовка к оказанию помощи вернувшимся в республику жителям;
3. Состояние подготовки к новому учебному году;
4. Участие на Всемирном конгрессе татар.

***1992 г., 30 апреля***

В газете «Йәшлек» опубликовано Заявление членов правления Уфимского клуба татарской культуры в поддержку участников политической голодовки.

***1992 г., апрель***

Вышел первый номер газеты «Җидегән» на татарском языке. Учредитель газеты – ТОЦ Башкортостана.

*(Продолжение следует)*

## Литература


1. Гарифуллин И.З. «Роль татарских общественных объединений Республики Башкортостан в реализации этнокультурных интересов татарского населения в конце 1980-х–начале 2000-х гг.» [Дисс. на соискание ученой степени кандидата исторических наук]. Казань, 2016.
2. Этнополитическая мозаика Башкортостана. Очерки. Документы. Хроника. Том II. Башкирское национальное движение. / Ред. М.Н. Губогло. ЦИМО. М., 1992.

## Мирасыбызның төбәк тарихына кагылышлысы

## Наше историко-краеведческое наследие

# ИДЕГӘ ДАСТАНЫ

*(Дәвамы. Башын карагыз: №1, 3, 4, 2019)*

## VI

Идегә хан булды, теләгәнчә идарә кыла башлады. Ил эшләрен яхшы белгән кешеләрдән биләр куйды. Эше яхшы барадыр иде, ләкин, күпме вакыйгалар үткәчтен, үзенең углы Норадын белән икесе арасында каршылык чыкты, көрәш китте. Каршылык Туктамышның матур кызлары белән ханлык өчен иде. Туктамышны куа киткәндә Норадын, атасына карап:

– Олы кызы – синеке, кече кызы минеке булыр, – дип киткән иде.

Норадын Туктамышны үлтерүгә шактый гына вакытлар үтүгә, Норадын, кызның корсагы үсә башлаганын күреп, кыздан.

Сиңа ни булды, эчеңдә ни бар? – дип сорады.

Кыз:

– Бу хурлыкны атаң эшләде, – диде.

Норадынның моңа ачуы чыкты. Атасына яман ачуланды. Шуннан Норадын атасына каршы эшләр күрә башлады. Йола буенча, бер ханның ханлыгын кем алса, ханлыгы кемдә булса, аның бөтен халкы, йире генә түгел, бәлки, бөтен казнасы, гаиләсе дә шул кешенеке булырга тиеш иде. Идегә шул йола буенча эш күрде. Туктамышның олы кызын да, кече кызын да үзе түшәкләде.

Туктамышны үтергән Норадын исә:

– Туктамышны мин үлтердем, иң кимендә кече кызы минеке булырга тиеш, – дип тавыш чыгарды.

Янбай Норадынга караганда Идегәне якынрак күрә, борынгы йола буенча эш кылуны яхшырак саный иде. Шунлыктан Туктамышның кече кызы да Идегәгә улҗа булырга тиеш, дип караган булып күренде. Ул Идегәгә киләдер дә:

– Туктамыш ханның олы кызы гына түгел, бәлки, кече кызы да синеке булырга тиеш. Туктамышның ханлыгы кемдә булса, аның гаиләсе дә шул

кешенең иркендә булады. Ханны кем үлтерсә, аның ханлыгы да, гаиләсе дә шул кешенеке булады, дигән йола юк, – дип, Идегәне яклаган булды.

Норадын янына барадыр да:

– Ханны кем үлтерсә, аның ханлыгы да, гаиләсе дә аныкы булырга тиеш... – диядер иде.

Норадын бер яктан Туктамышның иң чырайлы, иң матур кече кызын үзенә алгалы тартышса, икенче яктан хан булгалы да даулаша торган булды. Норадын Туктамышның кече кызын мактап, аны даулап, атасын бермә-бер көрәшкә чакырып ерлады:

Кашы яйдай[1] бөгелгән,
Керпеге уктай тегелгән,
Караган кеше өңелгән[2]
Күзекәдәй сылу кыз –
Я синеке, я минеке!
Тулы айдай нур йөзле,
Коралайдай[3] саф күзле,
Шикәр, балдай сүзле
Күзекәдәй сылу кыз –
Я синеке, я минеке!
Коландаен[4] кара чәчле,
Энҗедәен саф тешле,
Чәнчелеп торган түшле
Күзекәдәй сылу кыз –
Я синеке, я минеке!
Бакса, җанны эреткән,
Көлсә, канны йөреткән,
Әйтсә, авыру терелткән,
Күзекәдәй сылу кыз –
Я синеке, я минеке!
Көрәш булсын түрәмез,
Түрә хөкемен күрәмез,
Ексаң, ата, синеке,
Егалмасаң, Күзекәй –
Сылу кыз, ул – минеке! – диде.

Идегә Норадынга:

– Туктамышның кече кызын гына түгел, олы кызын да, хәтта аналарын да ал, кәрәк булса, – диде дә, кече кызны Норадынга бирде. Туктамышның сылу кызын, ханлыгын даулаган Норадынга карата Идегәнең ерлаганы:

Әй, Норадын, Норадын,
Аңламаем морадың.
Күзекәйне сорасаң,
Анасыны сорасаң,
Анасын да бирәен.
Ләкин ханны үлтереп,
Башын миңа килтереп,
Хан булаен, димәче,
Дан булаен, димәче.
Ялгыз башың, халыксыз
Сан булаен, димәче!
Туктамышка каршы мин
Гомрем буе көрәштем,
Ничә еллар орышып,
Сөңгеләшеп терәштем.
Шаһ Тимергә дим салып,
Күз алдына йим салып,
Туктамышны аяктан
Егар өчен сөйләштем.
Туктамышның илендә,
Туган-үскән йиремдә
Ач бүредәй карыштым,
Эт-мешәктәй[5] талаштым.
Биле-савырлы[6] көрәнне

Боракка[7] охшаш менгәнмен,
Тамгасыз углы Баракан
Ирексез алу алганмын.
Урда өчен тырышкан,
Ягалашып орышкан
Алтын тавына барганмын,
Түрә булып алганмын,
Халкын аерым алып килеп,
Ак Урдага салганмын.
Батырларның кайберен
Идел нүгәре[8] кылганмын.
Минем белән бер булып,
Халык өчен тартышкан,
Ягалашып, көрәшеп,
Дошманнар ман чәнчешкән
Ыруларның батырын
Кайсын бием кылганмын,
Кайсын ханым кылганмын.
Әй, Норадын, Норадын,
Кандай[9] юан булса да,
Ялгыз агач өй булмас,
Кандай ятыш булса да,
Яңгыз егет би булмас.
Әй, Норадын, Норадын,
Нидер синең морадың?
Хан булаен, димәче,
Дан булаен, димәче,
Яңгыз башың, халыксыз
Сан булаен, димәче!
Үтәр еллар, үтәр ай,
Килер вакыт, килер йай,
Хан буларсың шулчагын,
Дан буларсың шулчагын... –
диде.

Идегәнең әйткәннәре Норадынга ошамады. Ул атасының сүзләрен мине кимсетәде, мине хурлайды, мине егарга тырышады, дип аңлады. Үзенең тумышыннан ук башка булып пешеп туганлыкларын әйтте, андый үгетләргә карамаячагын аңлаткалы теләде. Әгәр эш аныңча булмый икән, үзенең Шаһ Тимергә барып, аның белән берләшеп, эш күрәчәген әйтеп, шүрләткәле уйлады. Атасы Идегәгә җавап урынына ерлаганы:

Фирештәдәен атам,
Һәр эштә даим атам,
Нигә мине хурлайсын,
Нигә мине ерлайсын?
Ерласаң мине, атам,
Ерлавыңны отармын[10]:
Хурласаң мине, атам,
Хурлавыңны остармын.
Буранлы көн туганмын,
Борыч бирсәң еламан;
Арыслан булып туганмын,
Төрткәнеңә коламан.
Бораклы[11] аттан ярышмын (ярсумын),
Бугалак салсаң туктаман;
Борычтан яман ачымын,
Шикәр түксәң, чөчемән[12].
Китәрмен, атам, китәрмен,
Шаһ Тимергә йитәрмен,
Тимер биргән Кир атны
Тирләткәнче менәрмен.
Тимер биргән тимер тун
Сүтелгәнче киярмен,
Унике тотам укларны
Бетергәнче чөярмен.
Тимер мән зур антым бар,
Тимер биргән сылуны
Алныма алып сөярмен.

Норадын тагы әйтте:

Уй, дигәйдә, кыр, дигәй,
Уйны баскан морзамын,
Ханнар ман да беләр мән
Киймалашкан[13] морзамын.
Коймалашым беткән соң,
Алыс-алыс йирләргә,
Үзгә телле илләргә,
Таң алдында Чулпандай
Яна-яна торганмын.
Сүзле адәмне сөйләтмәс
Инәдән чичән туганмын,
Тешле адәмне тешләтмәс
Инәдән тешле туганмын.
Китәрмен, атам, китәрмен,
Илче кылып игәнмен[14].
Ай кашында Зөһрәдәй[15]
Балкый-балкый торганмын,
Шаһ Тимергә йитәрмен,
Тимер биргән Кир атны
Тирләткәнче менәрмен.

Норадын атасының сүзен тыңламаганын күреп, анасы да ачынды. Норадынга карап анасы әйтәде:

Әй, Норадын, Норадын,
Идел дигән су килер,
Аны ничек кичәрсең?
Итәгендә ил булыр,
Аны ничек үтәрсең?
Әй, Норадын, Норадын!
Йаек дигән су килер,
Аны ничек кичәрсең?
Ягасында ил булыр,
Аны ничек үтәрсең?

Норадын анасына әйтәде:

Идел дигән су булса,
Ике чумсам, кичәрмен,
Итәгендә ил булса,
Ике орсам, үтәрмен.
Әй, инәкәм, инәкәм!
Йаек дигән су булса,
Бер чумганда кичәрмен,
Ягасында ил булса,
Бер органда үтәрмен!

Анасы тагы әйтәде:

Әй, Норадын, Норадын!
Бер агачта мең ботак,
Аны кисәен, дидеңме?
Берүзеңә мең кеше,
Аны изәен, дидеңме?

Норадын анасына әйтәде:

Әй, инәкәм, инәкәм!
Бер агачта мең ботак,
Бер ботактан нисе артык?
Берүземә мең кеше,
Бер кешедән нисе артык? – дип ерлады.

Йайлы табылган бервакытта Норадын Шаһ Тимергә качты. Анда барып, Идегәгә каршы көч сорады, гаскәр сорады. Шаһ Тимер бирмәде. Шулай да Норадын, күпкәме-азгамыдыр, анда торып калды.

Идегә Норадынны өлкән хан итеп куюга каршы булса да, бәләкәйрәк берәр би итеп куюга каршы түгел иде. Норадын читтә вакытта ул аны

сагынып та аладыр иде. Аны сагынып ерлаган чаклары да булгалыйдыр иде. Идегәнең Норадынны сагынып ерлаганы:

Алыстан кара күренсә,
Айланышкан морза улым,
Йуыктан кара күренсә,
Тулганышкан морза улым.
Йиде дәрья кушылып,
Котырынып ташканда,
Йил-каектай утравын
Йилгә биреп дәрья ашканда,
Ташкын тирән дәрьяны
Болыттай үткән морза улым,
Бурай-бурай кар яуса,
Бүз киерешкән[16] морза улым,
Бурасыннан ук килсә,
Булат калкан – морза улым!
Читтә солтан булудан
Илдә олтан булу артык.
Күктә чулпан булудан
Суда чуртан булу артык,
Әй, Норадын улым-ай,
Сагындырдың мине артык.

Идегә Норадынны сагына. Норадынга карата кайбер яхшылыклар эшләгәнен дә хәтерли, аны читкә качып китәрлек хәлгә китерүен дә сиздергәли иде. Әгәр Норадын Шаһ Тимер каршында озак заманнар торып калса, моның Идегә өчен көтелмәгән бер куркынычка әйләнеп китү ихтималы барлыгын да уйлай иде. Идегәнең башында мондый уйлар булганын Янбай ерау да бик яхшы сизәдер, беләдер иде. Көннәрнең берендә Янбай Идегәгә Норадын турысында болай ерлады:

Идегә, син таңдагы көн,
Яу өстенә яу килсә,
Яңгыз нигә ярарсын?
Дошманың аулай үләрсен.
Норадын яман улың түгел иде,
Кендегеңне борарсын, диде.

Идегә әйтте:

Яхшы әйттең, Ян әкәсе,
Бик хуш әйттең, яу нәкәсе[17].
Яу өстенә яу килсә,
Яңгыз нигә ярармын?
Дошманым аулай үләрмен,
Я дошманга калармын.
Норадын яман улым түгел иде,
Кендегемне борармын, – диде.

Идегә шуннан соң Норадынны кайткалы чакырып, берничә кешедән торган илче йибәрде. Алар Йаекны кичеп, очы-кырые күренмәгән далаларны үтеп, Норадынны барып таптылар. Норадынның илдән чыкканына байтак кына вакытлар үткән иде. Ул илне яхшы ук кына сагына башлаган иде. Норадын илчеләрдән сорап ерлайды:

Әй, илчеләр! Безнең күргән ил аманмы?
Биләр белән киңәш кылган йир аманмы?
Үзем барда кошлар салып, эт йөгерткән
Айдын-айдын[18] Идел белән күл аманмы?
Кашкайлары йәйәдәен киерелгән,

Керлекләре атар уктай төз тегелгән,
Колан чәчле, коралай күз, уймак авыз
Күзекәйдәй сылу, нечкә бил аманмы? – диде.

Илчеләр кайтарып ерлайды:

Әй, Норадын! Синең күргән илең дә аман,
Биләр белән киңәш кылган йирең дә аман,
Үзең барда кошлар салып, эт йөгерткән,
Айдын-айдын Идел белән күлең дә аман.
Кашкайлары йәйәдәен киерелгән,
Керлекләре атар уктай төз тезелгән,
Колан чәчле, коралай күз, уймак авыз
Күзекәйдәй сылу, нечкә билең дә аман, – диделәр.

Илчеләр сүзне үзләренең төбәп килгән төп мәсьәләләренә бордылар. Алар үзләренең ирекле атасы Идегәдән илче булып кайткалы чакырып килгәннәрен аңлаттылар. Илчеләр әйтте Норадынга:

Камал улы Янбайдан,
Соргантай улы Сабрадан,
Аргылның улы Карагуҗадан,
Акның улы Булаттан,
Алчагыр улы Морзадан,
Исән улы Ходай Бирдедән,
Ирекле кеше атаңнан,
Өндәү килде: «Кайтсын!» – дип,
Чабар килде: «Кайтсын!» – дип,
«Үпкәләсә, үпкә сүзен әйтсен!» – дип.
Ике канат, бер койрык
Инеп шоңкар чөйсен! – дип,
Ирене алтын сараяк
Ир саргытын эчсен! – дип,
Ай кашында бер йолдыз –
Зөһрә балкый торсын! – дип,
Таң алдында бер йолдыз –
Чулпан балкый торсын! – дип,
Кызыл канлы кылычын
Ак сөт белән юсын! – дип,
Иргә сәлам бирсен дә
Иңкәеп тәгъзим[19] кылсын! – дип,
Асыраган атасын,
Кичерү сораган атасын,
Аз гына гаеп булса да,
Анасы аша кичсен! – дип.

Норадын әйтте илчеләргә:

Камал улы Янбайдан,
Соргантай улы Сабрадан,
Аргылның улы Карагуҗадан,
Акның улы Булаттан,
Алчагыр улы Мырзадан,
Исән улы Ходай Бирдедән,
Ирекле кеше атамнан
Өндәү килсә дә кайтмасмын,

Үпкәләсәм дә, үпкә сүзен әйтмәсмен,
Ике канат, бер койрык,
Инеп шоңкар чөймәсмен.
Ирене алтын сараяк –
Ир саргытын эчмәсмен,
Ирнең күңеле ефәктәй,
Бер төйнәлсә чишелмәс,
Таразуга[20] салсан, тиңәлмәс,
Мыскалга[21] салсан, ким имәс.

Илчеләрдән тагы берсе әйтте Норадынга:

Бер, дигәч тә ни яман?
Ходаны белмәс ул яман!
Икенчеләй ни яман?
Фарыз укымас, ул яман!
Өченчеләй ни яман?
Өзелеп чыгар ян яман!
Дүртенчеләй ни яман?
Төркене[22] юк кыз яман!
Бишенчеләй ни яман?
Бишектәгеләр елашып,
Атасыз калса, ул яман!
Алтынчылай ни яман?
Йитәкләшеп ятимнәр
Елай калса, ул яман!
Йиденчеләй ни яман?
Турбала[23] – кош баласы
Ояда калса, ул яман!
Сигезенчеләй ни яман?
Яңгыз туган угыл яман!
Тугызынчыдай ни яман?
Үз иреннән сирпелеп,
Дәүләт китсә, ул яман!
Унынчылай ни яман?
Ултырган йире йопарлы[24],
Күзекәйдәй туталар
Елай калса, ул яман.
Ун бармагы кыналы.

Илчеләрнең соңгы сүзләрен ишеткәннән соң Норадын ата-анасы, гаиләсе янына кайткалы булды. Чакырып барган илчеләр мән бергә Норадын да кайтты:

Кайтып килде Норадын.
Кашка көрән ат менеп,
Ата-анасын үз санап,
Башкаларны ят белеп.
Чаба кайтты Норадын,
Атасына ялынып,
Языгы ман гөнаһысы
Үз муйнына алынып.

Идегә Норадынны чын шатланып каршы алды. Аны мактап шуны ерлады:

Уяу батыр баламсын,
Уяныклы морза улым,
Бүз аргымак баласындай
Буйлы-сынлы морза улым.
Алсу-кара битле улым,
Иплеләргә ипле улым,
Алача епәк тун кисә,
Ярашыклы[25] морза улым.
Катим Тайдай[26] юмартсың,
Арсландай адусың[27],
Камзәдәй[28] палвансың[29],
Галинең[30] гали улысың,
Арыслансың, морза улым.
Садагың алтын, угың алтын,

Чамыргап[31] әйткән сүзең алтын,
Саф азамат морза улым.
Йәмәннән[32] кеше җыйсам,
Уртага агач тексәм[33],
Мин тугыз күрек бассам,
Сине дәрәҗәгә чиксәм[34],
Саф алтынсың, морза улым.

Норадын кайткач, Шаһ Тимер килү куркынычы бетте. Идегә моннан тынычланды. Ләкин бөтен Урданы үз кулында тоткан Идегә, ниндидер сәбәпләр мән, Норадынны тагы да ханлык дәрәҗәсенә күтәрмәде, билек дәрәҗәсенә генә күтәрде. Хәлбуки Норадын атасының «сине дәрәҗәгә чиксәм, саф алтынсың, мырза улым!» дигәненә карап, анардан ханлык дәрәҗәсенә күтәрүен көтә иде. Норадынның бөтен Ак Урданы үз кулында тота торган кеше буласы киләдер иде. Ул, бу дәрәҗәне булдыру өчен нинди генә нәрсәне булса да эшләгәле тайяр (әзер) иде, ләкин эшне кайдан башлагалы, нинди сылтау күрсәткәле генә белмәй иде.

Идегәнең Норадынны ханлыкка утыртмавы, бер би итеп кенә калдыруы улына ошамады. Атасына карап Норадын:

– Син мине дәрәҗәгә мендергәле сүз биреп чакырган идең, кайтып кергән вакытымда да дәрәҗәгә чигәчәгеңне аңлаткан идең. Кайда синең вәгъдәң? Кайда синең сүзең? Син миңа Туктамыш хан артыннан аны үлтергәле куа киткәнемдә, аның башын алып килсәң, кече кызы сиңа булар, дип вәгъдә биргән идең, шул вәгъдәңдә дә тормадың. Мин даулаша башлагач кына ул кызны бирдең миңа. Мин синең билек дәрәҗәңә карап, шуңа канәгатьләнеп кенә кала алмаем, – диде. Моңа шуларны ерлады:

– Кисәкчә чыккан болытмын,
Яумаенча таркалман,
Анадан кара туганмын,
Сабынлап юсаң, агарман.
Атадан аеры[35] туганмын,
Би үткәрсәң[36], ныгайман,
Я мин сине үлтерәмен,
Я син мине үлтер,
Яки күземә күренмә,
Казакъ чыгып[37] кит, – диде Норадын.

Идегә әйтте:

– Кузагачтан[38] биекмен,
Болытка йитмәй тынмасмын,
Башымнан давыл өрсә дә,
Мин аңардан сынмасмын.
Көлсәм, мин бер чуакмын[39],
Киреләнсәм, йокың бозармын,
Көрәшсәм, сине егармын,
Йөгерсәм, сине узармын.
Әй, Норадын, Норадын,
Уңмастайны даулама,
Уңмастайны даулашып,
Казакъ чык, дип каулама.

Янбай Идегәне яклап Норадынга әйтәде:

Кауданлы[40] йиргә ут салсаң,
Утны[41]кайдан утларсың?
Ана Иделгә кан койсаң,
Суны кайдан эчәрсең?
Кара аргымак катырсаң[42],
Атны кайдан менәрсең?
Кара лачын качырсаң,
Кошны кайдан чөярсең?
Катибаны[43] хурласаң,
Тунны кайдан киярсең?
Күзекәйне елатсаң,
Сылуны кайдан кочарсың (сөярсең)?
Колан чәчен чалартып.
Коралайдай күзен кызартып,
Карт атаңны кауласаң,
Кайда барып уңарсың?
Языгы белән гөнаһысын
Кайда барып юарсың?

Норадын әйтте:

Камал улы киң Янбай,
Кире сүзгә эт Янбай!
Кауданлы йиргә ут салсам,
Яз яхшыны утлармын.
Ана Иделгә кан койсам,
Суны ширбәт эчәрмен.
Кара аргымак катырсам,
Атны тулпар менәрмен.
Кара лачын качырсам,
Кошны шоңкар чөярмен.
Катибаны хурласам,
Тунны турка[44] киярмен.
Күзекәйне елатсам,
Сылуны таңлап[45] сөярмен (кочармын),
Колан чәчен чалартып,
Ике күзен кызартып,
Карт атамны кауласам,
Тәңре өе Кәгъбәне
Өч әйләнсәм, йолармын,
Я казакъ чык, я үлтерәмен!

Идегә, үз баласыннан мондый сүзләрне кабат-кабат ишеткәннән соң, Норадынны ниндәй уйлар мән, ничек асрап үстергәннәрен күз алдына китереп, Норадыннан зарланып, ерлап әйтәдер:

Әй, Норадын, Норадын,
Сине теләп тудырдым,
Син туганда хисапсыз (санаксыз)
Ту бияләр суйдырдым.
Я колыным, мин сине
Бигә лаек туды, дип,
Я морзам, мин сине
Ханга лаек туды, дип,
Карындаштан, ырудан
Туеңа кеше йыйдырдым,
Галимнәрне туйдырдым,
Ятимнәрне туйдырдым,
Хан кашында туды, дип,
Атыңны Норадын куйдырдым.
Сиңа бишек кәрәк, дип,
Алтыннан бишек бөктердем,
Чөмәген46 алтыннан уйдырдым,
Төбәген47 көмештән койдырдым.
Туганыңда мин сине
Биш биләүдән биләттем,
Биш биләүне яманлап,
Кара камкага биләттем.
Камка каты булыр, дип,
Сусар түшәк йәйдердем,
Сусарым суык булыр, дип,
Күк тиен түшәк йәйдердем.

Гарәп китабы укыган
Галимнән мәгънә сораттым,
Кочаклап Коръән укыган
Мулладан мәгънә сораттым.
Сүзгә чичән булсын, дип,
Артыңнан Янбайны иярттем,
Егет атың чыксын, дип,
Артыңнан егетләр иярттем.
Егет чагыңа килгәндә
Тулпар сайлап менгердем.
Хан сөярдәй булсын, дип,
Тимер туннар кидердем.
Мәргән булып үссен, дип,
Биленә садак[48] будырдым,
Йөрәгең батыр үссен, дип,
Качкан яулар кудырдым.
Я колыным, мин сине
Бигә лаек туды, дип,
Бидән нүгәр алдырдым.
Ханга лаек туды, дип,
Ханнан кәпәч алдырдым.
Колан чәчем чалартып,
Коралайдай күзем кызартып,
Картлыгымда син мине
Ник куасың, Норадын?
Нәрсә синең морадың?

Норадын әйтте:

Әйткәнеңне барысын
Кылганың хак, әй ата,
Әйткәнемнең берсен дә
Кылганың юк, әй ата.
Вәгъдә – иман иде,
Берен дә кылмадың миңа,
Я казакъ чык,
Я үлтерәмен, – диде.

Идегә Норадынга әйтте:

Каулыйсын, улым, каулыйсың,
Карт атаңны яудай яулыйсың.
Мин яу түгел сиңа, ә син үзең
Мин бирәлмәс нәрсә даулыйсың.

– Мине каулагач та хан буласың, эшләр бары да төзәлә, дип уйлайсың ахыры. Хан да була алмассын, эшне дә яхшырта алмассын. Син теләгән урынга башкалар утырыр. Моны тиздән аңларсын, ләкин эш үткән булыр, – диде дә казакъ чыгып китте.

Ханлык Идегә кулыннан китте, башканың кулына керде, Норадын һаман да хан була алмады.

Тәхеттән куылгач, казакъ чыгып киткән Идегәнең үз углы Норадынга үпкәләп, аның да хан була алмавына ачынып ерлаганы:

Тирлегем алтын булмады,
Тәгем[49] минәр[50] булмады,
Хан йийәне[51] би улы
Норадын хан булмады.
Карга кунмас агачка
Каз кундырдың, Норадын,
Козгын кунмас агачка
Куу[52] кундырдың, Норадын.

Норадын атасына кайтарып әйтте:

Тирлегең алтын булмаса,
Тәгең минәр булмаса.
Хан йийәне би улы
Норадын хан булмаса,

Хан ултыртты тәхеткә,
Ирешер ил бәхеткә.
Карга кунмас агачка
Каз кундырдым ил өчен,
Козгын кунмас агачка
Куу кундырдым ил өчен.

Карга кунмас агачка
Каз кундырдың йил өчен[53],
Козгын кунмас агачка
Атасы каршы әйтәде:
Куу кундырдың йил өчен.

Анасы Норадынга тагын сорап әйтәде:

Әй, Норадын, Норадын,
Каз төшермәс күлләргә
Каз төшереп уйнаттың.
Каздай башын агарткан
Атаңны нигә уйлаттың?

Әй, Норадын, Норадын,
Куу кундырмас күлләргә
Куу кундырып уйнаттың,
Куудай башын агарткан
Анаңны нигә уйлаттың?

Норадын анасына кайтарып әйтте:

Әй, инәкәм, инәкәм!
Каз төшермәс күлләргә
Каз төшердем ил өчен,
Каздай башын агарткан
Атаны уйлаттым ил өчен.

Әй, инәкәм, инәкәм,
Куу кундырмас күлләргә
Куу кундырдым йорт өчен,
Куудай башын агарткан
Анамны уйлаттым йорт өчен.

Анасы Норадынга әйтәде:

Әй, Норадын, Норадын,
Кара суга кан койсаң,
Суны кайдан эчәрсең?
Халык белән даулашып,
Яхшыны кайдан табарсың?

Әй, Норадын, Норадын,
Каулы йиргә[54] үрт салып,
Утны кайдан табарсың?
Халык белән яулашып,
Яхшыны кайдан табарсың.

Норадын, анасына кайтарып:

Әй, инәкәм, инәкәм!
Кара суга кан койсам,
Суны ширбәт эчәрмен.
Халык белән даулашсам,
Йорт яхшысын табармын.

Әй, инәкәм, инәкәм!
Каулы йиргә үрт салсам,
Ут яхшысын табармын.
Халык белән яулашсам,
Йорт яхшысын табармын.

Норадын анасына тагы ерлайды:

Әй, инәкәм, инәкәм!
Иртә тордым таң белән,
Тирә-ягым карандым,

Яуга чыктым яңгызым,
Яңгыз атам санаңдым55.
Әй, инәкәм, инәкәм!

Иртә тордым таң белән,
Тирә-ягым карандым,
Яуга чыктым яңгызым,
Яңгыз анам санандым.

Норадын анасына тагы ерлайды:

Әй, инәкәм, инәкәм!
Ике ташны култыклап,
Идел кичкән Норадын
Икедән[56] яуга төшеп,
Исән чыккан Норадын.
Әй, инәкәм, инәкәм!
Яңгыз ташны култыклап,
Йаек кичкән Норадын,
Яңгыз гына яуга төшеп,
Исән чыккан Норадын.

## Сүзлек–аңлатмалар

1. Яйдай – җәйдәй.
2. Өңелгән – таң калган.
3. Коралай – кыр илеге, җәйрән, газель (Н.Х.).
4. Колан – кыргый ат.
5. Мешәк – мәче.
6. Савыр – атның билдән койрыкка хәтле өлеше.
7. Борак – мифик ат исеме, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вәссәләмне Аллаһы Тәгалә катына илтеп җиткерүче.
8. Нүгәр – дус, ярдәмче. Себердә «туй егете» (дружка) мәгънәсендә әле дә саклана.
9. Кандай – нинди. Себер сүзе түгел.
10. Отармын – «тотармын, күтәрермен» мәгънәсендә.
11. Бораклы – Бораклай (Боратай) мифик ат сурәтендә.
12. Чөчемән – төче, баллы булмамын.
13. Коймалашкан – утырдаш, мәҗлестәш булган.
14. Игәнмен – җибәргәнмен.
15. Зөһрә – Себердә сәрә, зәрә, заря дип атала торган Венера йолдызы.
16. Бүз киерешү – кар, яңгырдан сакланыр өчен ябынча күтәрү, бүздән чатыр ясау (Н.Х.).
17. Нәкәс – яраксыз, ялкау.
18. Айдын – якты.
19. Тәгъзим – олылау.
20. Таразу – зур үлчәү.
21. Мыскал – үлчәү берәмлеге, якынча 4.26 грамм булган.
22. Төркен –хатынының ир туганнары.
23. Турбала – чөелергә тиешле кош баласы.
24. Йопарлы – җәфарлы (хуш исле).
25. Ярашыклы – килешле, ярый торган.

26. Катим Тай – Хатәм Тай, татар фольклорында юмартлык сурәте. Тай иле Хатәме (изафә).
27. Аду – батыр.
28. Камзә – хәзрәти Хәмзә – гарәп батырларыннан.
29. Палван – пәһлеван.
30. Галинең гали улысы – биредә: «югары (затлы) улысың» мәгънәсендә.
31. Чамыргап – үпкәләбрәк (жам белән).
32. Йәмәннән – биредә: «тирә-юньнән» мәгънәсендә булуы мөмкин.
33. Тексәм – тезсәм.
34. Чиксәм – ирештерсәм, туендырсам.
35. Аеры – аерымлык, үзенчәлек белән.
36. Би үткәрсән ныгайман – билек белән генә нык булмам, дигәне.
37. Казакъ чыгу – «куылу, качу» мәгънәсендә.
38. Кузагач – чикләвек (кузы) агачы.
39. Чуак – җылы, йомшак, аяз (Н.Х.).
40. Каудан – үләне яндырылган жир (отава).
41. Ут – үлән.
42. Катырсан – «үтерсәң» мәгънәсендә.
43. Катиба – хәтфә.
44. Турка – кытай ефәге.
45. Танлап – сайлап; таңлану – гаҗәпләнү, таң калу.
46. Чөмәк – бишекне тирбәтер өчен тотар җире.
47. Төбәк – бишек астындагы тишек.
48. Садак – ук савыты (колчан).
49. Тәк – тәхет.
50. Минәр – бизәк.
51. Йийән – ана ягыннан туган тиешле ир-ат.
52. Куу – аккош.
53. Йил өчен – җилгә, бушка.
54. Каулы йир – кипкән үләнле җир.
55. Санаңдым (алт.) – уйладым.
56. Икедән – бермә-бер, кара-каршы.

*(Дәвамы бар)*

Алынды: Татар эпосы. Дастаннар. Казан: «Раннур». 2004. 286–336 бб.

## Олуг татар иле

## Magna Tartaria

*Айзирәк Гәрәева-Акчура*

# ТӨРКИЯДӘГЕ СОЛТАНОВЛАР КЕМ?

Әлеге сорауга җавапны Солтановлар нәселенең Төркиядә дини, гыйльми, фәлсәфи, мәдәни эз калдырган берничә әгъзасы хакында тупланган мәгълүматлар күзалларга булыша. Әлбәттә, әлегә тулысынча, дип әйтү – дөрес булмас. Хәтта кайберләре Төркиядә нәсел фамилиясе белән билгеле шәхесләр түгел. Татарстанда исә алар, ни Солтанов фамилиясе, ни чит илдәге исемнәре аша киң җәмәгатьчелеккә танылмаган...

2019 ел ахырында Төркиянең мәртәбәле оешмасы – «Гыйлем тарату җәмгыяте»нең (İlim yayma cemiyeti) ике елга бер милли аң сахибе булган, Төркиягә һәм инсаннар өчен хәерле эшләр башкарган галимнәргә тапшырыла торган дәрәҗәле бүләк ияләре билгеле булды. Бүләккә лаек дип табылган өч галимнең берсе – Мимар Синан гүзәл сәнгатьләр университетының тарих бүлеге галиме Ильяс Камалов. Милләттәшебезгә премия социаль белемнәр категориясендә бирелде. Чит илдә татар халкы тарихын танытучы милләттәшебез өчен Төркия татарлары зур горурлык, куаныч хисен кичерде.

Бу вакыйганы сөйләгәндә тарихи бер хаклык та беленергә тиеш дип саныйм. Ильяс Камалов бүгенге көндә дәүләт күләмендә зур роль тотучы оешманың (премияләрне Төркия Президенты Рәҗәп Эрдоган тапшыруы да шуны күрсәтә) бүләк иясе, дигәндә, бу оешманың татар кешесе оештырган җәмгыять икәнен дә истә тотыйк. Нәкъ шулай! Һәм ул – Солтановлар нәселеннән булган хәзрәт Абдулгазиз Беккинә (1895–1952). Нәкешбәндия тарикатенең «алтын силсилә» дип аталган чылбырында, мөршид-остазлары Мостафа Фәйзи һәм Абдуллаһ Хасиб әс-Серези Ярдәмчедән соң, Абдулгазиз Беккинә әл-Казани исеме 38 нче урында тора.

### *Җәмгыятьнең рәсми сайтында исеме юк*

«Гыйлем тарату җәмгыяте»нең (İlim yayma cemiyeti) рәсми оештыручылар саны 68 кешедән гыйбарәт. 2007 елда җәмгыять чыгарган бюллетеньдә әлеге 68 кешедән бу вакытта исән-сау булган бердәнбер кеше – Өмәр Лүтфи Таке белән интервью басылган. Өмәр әфәнде 2016 ел-

ның 23 апрелендә вафат. Шулвакытта Төркиянең төрле сайтларында аның мәрхүм булуы турындагы мәгълүмат әлеге әңгәмә видеосы белән бергә таратыла.

Иң беренче чиратта менә шушы әңгәмәгә игътибар итик. Алга таба интервьюның кыскартылган тәрҗемәсен китерәм.

***Өмәр Лүтфи Таке белән репортаж***

***– Иң башта үзегез белән таныштырыгыз.***

– 1924 елда Бурсада тудым. Солтанәхмәттә югары сәүдә мәктәбен тәмамладым. Бурсада абыем белән уртак фабрикабыз бар иде. Әтиемнең киңәше белән абый җитештерде, ә мин саттым. Безнең фабрика мәшһүр иде. 1950 елда мин, эшем белән бәйле рәвештә, Истанбулга килдем. Бәязит-Гедикпашада кибет ачтым. 1990 елда Мәдинәдә яшәргә рөхсәт һәм анда йорт сатып алдым. Мәдинә-Мөнәвәрәдә эшче хәлендә идек: ярты елдан соң Төркиягә кайтып килергә кирәк. Хатыным белән Мәдинәдә – 6 ай, Төркиядә 6 ай кала идек. Шуңа күрә елның яртысы анда, яртысы монда узды.

***– Әтиегез хакында сөйләсәгез иде.***

– Әтием – Кырымнан, әнием тарафы Русиядән, Казаннан килгән. Мин белгән кадәре, әтием һәм аның кардәше уртак эш алып баралар иде. Бабам, Кырымнан килеп, Искешәһәргә җирләшә, соңыннан Бурсага күченәләр. Алар чабата үргәннәр; ул чакта аяк киеме булмаган. Чабатачы Мостафа һәм Хөсәен буларак танылалар. Соңрак аяк киемнәре чыкты, чабата эше бетте. Аннары әтием туку станоклары, җеп алып кайтты; бу станоклар өчен «такә» (челнок) ясый башлады, фамилиябез шуннан килә. Әтием Исламга хезмәт иткән бер кеше иде.

***– Сез кайда рухи тәрбия алдыгыз?***

– Әти-әнисе мөселман булган бала, өендә күргәнне эшләячәк. Китаплар ярата идем, бик күп әсәрләр укыдым. Белгәнчә хезмәт итәргә тырышабыз.

***– 1950 елда Истанбулга килгәнсез. Сез – 1951 елда корылган «Гыйлем тарату җәмгыяте»нә нигез салучыларның берсе. Билгеле, мондый социаль, мәдәни эшләр белән кызыксыну булгандыр. Сәүдәгәрлектән тыш ниләр башкардыгыз?***

– Абдулгазиз Беккинә хәзрәт – минем туганым, Истанбулга иң беренче килгәндә, берничә ай аның йортында калдым. Ә аннары үземә арендага йорт тоттым. Җәмгыять идеясен көн тәртибенә китергән, бу эшнең беренче мәртәбә очкынын аткан Абдулгазиз Беккинә хәзрәт иде. Аның заманында Конья Ләззәт локантасы (рестораны) хуҗасы бар иде. Ул, Нуретдин Топчу (1909–1975, танылган фәлсәфә галиме, язучы – авт.) һәм берничә адвокат дустыбыз шундый бер җәмгыять корырга теләде. Миңа

ул вакытта 20–25 яшь иде, җәмгыять әгъзасы булдым. Беренче очрашуны Конья Ләззәт локантасында уздырдык. Бу җәмгыятьне ни өчен корабыз, нинди эшләр башкарачакбыз, максатыбыз нидән гыйбарәт – без шунда карар бирдек. Хәтерләгәнем кадәре, җәмгыятькә нигез салучылар арасында Вехби Билимер да бар иде.

***– Газиз әфәнде турында сөйләсәгез иде.***

– Абдулгазиз Беккинә хәзрәт динне тарату, халыкка җиткерү, хәерле балалар җитештерү өчен һәвәсле иде. Аның зиһене бик көчле иде. Гомере кыска булды. 1952 елда хаҗга китте. Чәйдән башка берни эчми торган кеше, анда, Дамастан килгәндә, салкын сулар эчә-эчә хасталанган. Бугазында яман шеш булуы әйтелә. Шунда беренче тапкыр дәвалана, табиблар аның калуын таләп итәләр. Ләкин янындагылар тизрәк балалары янына кайтырга телиләр. «Кайтыйк, кайткач дәваларбыз», – диләр. Кайткач хәзрәтнең чире тагын да көчәя, Истанбулга килгәч бер-ике айдан соң мәрхүм була. Аллаһ рәхмәт әйләсен.

***– Газиз әфәндедән соң сез Мәхмәт әфәнде (Захит Кокту хәзрәт (1897–1980), шәех, силсиләдә Абдулгазиздән соң килә – авт.) белән элемтәдә тордыгызмы? Ул дәвердән кемнәр белән якын булдыгыз?***

– Без мәчеткә мәхәллә кешеләре буларак килеп-китә идек, җомга көннәрендәге очрашуларга... Моннан тыш Мәхмәт әфәнде белән шәхси якынлыгыбыз булмады. Доктор Әхмәт Мазһар Өзман (1929–1999, табиб, Мәрмәра университетының табиблык факультетын коручы – авт.) бар иде, ул хәзрәтебез янына килеп-китеп йөри иде. Әрбакан килеп йөри иде. Ул Германиягә китәр алдыннан Газиз әфәнденең кулын үпте, Аллаһка тапшырдык, диде һәм китте. Мин дә анда идем.

***– Илебездә 1950 елдан бүгенге көнгә кадәр булган вакыйгаларны ничек бәялисез?***

– 1950 елда җәмгыять корылды. Имам-хатыйплар мәктәпләре ачылды. Аллаһы Тәгалә тагын да дәвамлы итсен, иншаллаһ! Исламга хезмәт итүче яңа яшь буын тәрбияләү мөһим. Төркиядә Ислам динен өйрәнгән, тоткан яңа яшьләр булдыру кирәк. Каршы тараф бик яхшы эшли, без эшләмибез. Тагын да күбрәк эшләр өчен, эшләребезгә юнәлеш бирәчәк лидерлар кирәк. Җәмгыятебезнең шундый инсаннар җитештерүе мөһим.

*Интервью алучы: Али Осман Пекмезче, «Гыйлем тарату вакфы» журналы (Ali Osman Pekmezci, İlim Yayma Vakfi Dergisi).*

Бу әңгәмәне укыгач, җәмгыять тарихын өйрәнә башладым һәм берничә сорау туды.

Беренчедән. Ни өчен, оештыручыларның берсе мәгълүмат бирүгә карамастан, җәмгыятьне оештырган 68 кеше арасында Абдулгазиз Беккинә язылмаган?! Шулай ук рәсми сайтның тарихи мәгълүматлар урна-

штырылган сәхифәсендә нигә исеме телгә алынмый?! Бәлки, ул вакытта хаҗда булгандыр, авырган чагы туры килгәндер, һәм шул сәбәпле читтә калгандыр, дигән уй башка килде. Җәмгыятьнең оешу датасы буларак, сайтта 1951 елның 11 октябре күрсәтелгән. Беккинәнең 1952 елның яз айларында хаҗга китүе һәм 1952 елның 2 ноябрь аенда мәрхүм булуы билгеле. Димәк, җәмгыять оешканда ул Төркиядә, Истанбулда булган, дип фаразларга җирлек бар.

Икенчедән. Интервьюны укыганда, оештыручыларның берсе – сәүдәгәр, икенчесе ресторан хуҗасы булуы бераз сагайтты. Аннары 68 кешедән торган оештыручылар исемлегендә тагын кемнәр бар соң дип тикшергәндә, сәүдәгәрләрдән тыш, адвокат, тукымачы, автобус йөртүче, пенсионер, тегүче, аптекарь, амбарчы һәм башкаларны күрдем. Гыйлем тарату башлангычында торучы һөнәр ияләреме болар?! Ә бит бу җәмгыять корылганнан соң имам-хатыйплар әзерләүче мәктәпләр ачыла башлый һәм алар бүгенге көнгә кадәр эшчәнлекләрен дәвам иттерәләр.

Әлеге икеләнү хисе уяткан сорауларга җавапларны Абдулгазиз Беккинәгә кагылышлы китапларда күрмәдем. Гомумән, аларда аның мондый төр җәмгыять оештыруы хакында әйтелми дә. Эзләнә торгач, ачыкламаны Беккинәнең шәкерте, инженер, сәясәтче, Төркиянең элеккеге премьер-министры Нәҗмәттин Әрбаканга (1926–2011) багышланган «Аллаһ дусты Әрбакан» исемле китаптан таптым. Ул китапта Әрбаканны якыннан күреп белгән бик күпләрнең хатирәләре урын алган. Шуларның берсе Осман Акдүн аңлата:

«...Үзеннән (Әрбаканнан – авт.) ишеткән «Гыйлем тарату җәмгыяте»нең ничек корылганы хакындагы бер вакыйганы аңлатырга телим.

Әрбакан остазыбыз 22 яшьләрендә вакытта, ягьни 1948нең бер көнендә, Абдулгазиз Беккинә хәзрәтләренең бакча эчендәге өендә бер тупланты була. Бу тупланты төнге сәгатьләргә кадәр дәвам итә. Һәр кеше китә. Бары тик Әрбакан остазыбыз шәехе белән кала. Ишек шакыйлар, өй ишеген. Төнге сәгать 02.00. Абдулгазиз әфәнде ишекне үзе барып ача. Веһби Чыкрыкчы дигән бер адвокат килеп керә. Әрбакан остазыбыз да анда.

Адвокат шулай ди:

– Әфәндем, бүген гамәлдәге хөкүмәт бер карар кабул итте. Хөкүмәт үзләре теләгән рәвештә, Исламга түгел, аларга хезмәт итәчәк ысулдагы һәм квалификациядәге имамнарны җитештерергә телиләр. Бу имамнарны без Исламга хезмәт итүчеләр буларак җитештерә белербез!

Абдулгазиз әфәнде:

– Бу бик мөһим! Безнең теләгәнебез дә нәкъ бу. Ярый, бездән ни телисез? – ди.

Миңа җиде кеше бир. Фотографияләре һәм документлары белән.

Икенче көнне Абдулгазиз әфәнде, Әрбакан хуҗабыз ярдәме белән фотографияләр һәм документлар туплап бирелә.

Әрбакан остабыз шулай аңлатты. Ул мин эшләдем, мин булдырдым, димәс иде. Мин Әрбакан остазыбыз моны Абдулгазиз әфәнде әмере белән үзе башкаргандыр, дип уйлыйм. Веһби Чыкрыкчының ул сәгатьтә килүе һәм өйдә бары тик ике кешенең генә булуы Әрбакан остаз әзерләгән бер хәл, дия төшенәм.

Тупланган һәм документларын биргән кешеләр 65–70 яшьләрендәге баккал (кибет), касап (ит кисүче), аяк киеме төзәтүче кебек кешеләр. Адвокатка бу исемнәр бирелә. Адвокат 1948дә «Гыйлем tarату җәмгыяте»н менә шушы рәвешле кора.

Озак вакыт та узмый бу кешеләрне хөкүмәт җыеп тикшерә. Сорау ала. Карыйлар да: «Бу балтачы Ниязидан берни чыкмас, бу ярма сатучы Әхмәт ни кыла белер? Бу аяк киеме төзәтүче адәм – үзенә дә файда итә алмаган бер карт адәм, безгә нинди зарары тияр?» – дип, эшчәнлекләренә ризалык бирәләр.

«Гыйлем җәмгыяте» шушы рәвешле казасыз-бәласез эшчәнлеген башлый. Берникадәр вакыттан соң юнәлтүчеләре үзгәреп, белемле кешеләр идарәгә килеп, бүгенге «Гыйлем тарату җәмгыяте» туа.

Мин моны хәзер шулай аңлыйм. Җәнабел Хак бер милләткә үсеш бирәсе булса, аның җитешкән буынын акыллы итеп җитештерер. Бу вакыйгада адвокат белән Абдулгазиз әфәнде арасындагы элемтәне Әрбакан рәхмәтле коргандыр. Әмма моны Әрбакан башкарганы күренсә, дөрес булмас иде. Чөнки Абдулгазиз әфәнде бар иде, аның эшләве дөрес булыр иде. Әмма «Гыйлем тарату җәмгыяте»нең бу рәвештә кыенлык чикми, ясакланмыйча тормышка ашырылуы, минемчә, Әрбакан остазның бер планы иде».

Әгәр дә бу хатирәдән сөйләүченең кайбер шәхси фикерләрен сөзеп алсак, Әрбакан әфәнденең сөйләгәннәре кала. Ә алардан Абдулгазиз Беккинәнең нинди зур фикерләр белән яшәве күренә. Өендә бүгенге һәм киләчәк буыннар өчен мөһим мәсьәләләр каралган бу дин әһеле кем соң?

***Әүлия итеп зурланган хәзрәт***

Абдулгазиз Беккинәнең әтисе – Харис хәзрәт Солтанов, бабасы – Мәхмәт (Мөхәммәт) мулла. Ул – Харис хәзрәтнең Истанбулда туган малае, Казанга кайта, Бохарада укый. Аннары кабат кардәшләрен алып, Төркиягә китәргә мәҗбүр кала. 1926 еллардан башлап, 1952 елда мәрхүм булганчыга кадәр дингә хезмәт итә. Истанбул әүлиялары энциклопедиясенә кергән хәзрәт. Чыннан да, халык аны гомере буе әүлия итеп кабул итә, әүлия итеп зурлый...

Шуңа да аерым басым ясау мөһим, 40 нчы елларда үз дәрһагына төрле уку йортлары студентларын туплый алган һәм аларга юл күрсәткән дин әһеле ул. Төркиянең дини, сәяси, фәлсәфи, фәнни һәм техник тормышына өлеш керткән билгеле шәхесләрнең остазы. Шәкертләреннән берсе – Премьер-министр булган, профессор Нәҗмәттин Әрбакан. Ул исә, мәгълүм булганча, Төркия Җөмһүриятенең элекеге Президенты Абдуллаһ Гөлнең һәм бүгенге Президенты Рәҗәп Тайип Эрдоганның остазы. Аның шәкертләре арасында Төркиядә атаклы тагын бик күпләр бар. Шәкертләре тарафыннан Беккинә гарәпчәдән төрекчәгә тәрҗемә һәм тәфсир иткән, аңлаткан «Рамуз әл-Хәдис» китабы 1982 елны ике китап итеп туплап бастырыла. Китап авторы – шәех Әхмәд Зыяэтдин Көмешханәви.

2018 ел ахырында Абдулгазиз Беккинәгә кагылышлы китапларны, мәкаләләрне, үзенең һәм шәкертләренең хатирәләрен өйрәнеп, барлап «Казан әүлиясы» дип аталган хикәя яздым һәм ул 2019 елның март санында «Идел» журналында дөнья күрде. Хәзрәтнең кем булуын, нинди тәрбиядә үскәнен аңлатыр өчен шул хикәямнән, аның шәхси хатирәләренә таянып тасвирланган бала-чагына кагылышлы бер өзек белән уртаклашасым килә.

*«Әүлия җаннарны юкка чыгарырлык яки илдән җибәрерлек хәлләрне күзалларлык идеме соң?!*

*Казан мөселман байларының, алыпсатарларның күбесе инкыйлаб әле булмас, революционерлар көч алмас, ничек тормыш барган – шулай дәвам итәр дип ышанды. Әллә беркатлылыктан, әллә тупланырга ниятләре җитмәүдән башларына ни киләсен артык сизенмәделәр төсле. Кисәтүчеләр, фикерләшүчеләр дә булмады түгел, булды...*

*Изгеләргә кем тисен соң?!*

*Әмма...*

*Берничә елга сузылган болганышлар һәм көзге инкыйлаб барысын чәчеп ташлады. Әйтерсең, бер уч гарәбдәй ялтырап торган кадерле, кыйммәтле бодай бөртекләре ташлар астына күмелде. Һәм, ул ташлар милләтнең бер урынына, хәтта ун мәртәбә күбрәк уңыш бирерлек кыйммәтле бодай бөртекләрен күзәнәкләренә кадәр изде. Затлы бер буын вәкилләре – әүлияларын белгәннәр һәм әүлиялар шәҗәрәләрен дәвам итүчеләр таш диварлар эченә ябылды, аннары атылды, юкка чыгарылды. Берәм-берәм инкыйлаб ташлары астында басылды, күмелде, пыран-заран китерелде...*

*Шөкер, Аллаһ кодрәте һәм ярдәме зур, кайсыбер бөртекләргә шытым җибәрергә бүтән җирләр табылды. Аларны газап, кыенлык, якыннарыннан аерылу хәсрәте, нужа озата йөрсә дә, бу инде таш астында калып юкка чыгу түгел иде. Әйтерсең, Ходай Үзе шундый сынаулар биреп саклады, Үзе яклады...*

*... Поезд Баку тарафына ашыга. Илдән гомерлеккә ераклаша баралар. Вагондагыларның күңел халәте – киеренкелек күзгә күренми генә һәр күзәнәкне айкарлык.*

*Менә шулай, инкыйлабтан соң кемнәрнеңдер чарасызлыктан, кемнәрнеңдер үз теләкләре белән туган җирләреннән аерылып китүләре. Хәер, барсы да туган җирдән аерыла микән?!*

*23 яшьлек Газиз туган җиреннән түгел, бабалары җиреннән-нигезеннән каерылып бара. Башка юлдашларыннан, хәтта кайбер кардәшләреннән аермалы буларак, аның туган җире Истанбул бит. Димәк, ул, киресенчә, туган җиренә юл тота.*

*Мәхмәт мулла малае Харисның 1895 елда Төркиядәге өендә икенче җәмәгатеннән дөньяга килгән өлкән улы ул. Харис әфәнде үзе Казан татары, гаиләсе белән 1880 елларда Истанбулда яшәп, күпләп май сату белән сәүдәгәрлек итте, үзен дини, гыйлми хәл иясе итеп танытты. Унынчы елларда исә Русия хөкүмәте тикшерүләре нәтиҗәсендә гаиләсе белән Казанга кайтырга мәҗбүр калды. Шул елларда улы Газизне Бохарада биш ел укытырга өлгерде... Аннары, дистә ел да үтмәс борын, суфый Харисның дәвамчылары, бабалары җирендәге бар мөлкәтләрен, шәкертләр укый торган 32 бүлмәле зур йортларын калдырып, янә Төркиягә юл алдылар. Бу мәҗбүри күченүне инде әтиләре дә, әниләре дә күрмәде, алар инкыйлабка кадәр дөнья куйдылар.*

*Газиз кардәшләре белән бергә башка бик күпләрнең газаплы язмышларын уртаклашты. Ни көткәнен бер Аллаһ белә, әмма барыр тарафлары билгеле...*

*Бервакыт Казанда кичке дини укудан кайтып барышы иде Газизнең. Урамда каршына мылтык тоткан гаскәри килеп чыкты. Усал, җитди тавыш белән акырды: «Әй, малай! Каян киләсең? Кая барасың?»*

*Газиз дә, җитди бер кыяфәт алып һәм шәһадәт бармагын солдат йөзенә юнәтеп: «Аллаһтан килеп, Аллаһка китәм», – диде.*

*Моны көтмәгән солдатның хәтта кулыннан коралы төште. Урынында шашып басып калды, Газиз аңардан ераклашырга ашыкты.*

*...Әти-әнисеннән дини тәрбия алган, Русиядә яшәгәндә Бохарага китеп биш ел гыйлем җыйган Газиз Истанбулда дини гыйлем алуын дәвам итәргә булды. Шәһәрнең Чаршыкапы бистәсендәге Бәязид мәдрәсәсенә гыйлем тупларга керде. Дөрес, Төркиягә килгәч, кардәшләре белән берникадәр вакыт әтиләре хезмәтен дәвам итеп карады. Әмма бу эш белән озак мавыкмады, имамлык юлын сайлады. Шулай ук бер мөршидкә сыену вакыты килгәнен төшенде. Рухи үсеш һәм Аллаһ каршына камил инсан булып бару өчен шәехкә баглану кирәклеген кечкенәдән аңлап үсүе моңар этәрде дә.*

*Ул бала чактан ук әтисенең озын вакытлар бүлмәдә калып, ялгызы гына рухи халәт эчендә гыйбадәт кылып утырган чакларын күп мәртәбәләр күрде. Аңар аеруча тәэсир иткән вакыйга исә Казанда яшәгән вакытларында зиратта булды.*

*Төрбәләр бикләнгән бер заманда, әтисе аны шәехенең каберен зиярәт итәргә алып китте. Кышкы бер көн, тирә-юньне кар каплаган иде. Төрбәнең ишеге зур бер асма йозак белән бикләнгән. Әтисе төрбәгә ун метр чамасы кала туктады. Сәлам биреп, догалар укырга кереште. Әле балалыгыннан чыгып җитмәгән яшүсмер малай әтисен читтән шыпырт кына күзәтте. Харис әфәнде укыйсыларын укып тәмамлагач, ягымлы, басынкы бер тавыш белән: «Әфәндем, мине гафу итсәң, йозак ачылсын да эчләргә керим», – дип үтенде. Шул мәлдә йозак «тры-ы-ыкк» итеп үзе ачылды. Әтиле-уллы төрбә ишеген ачып, эчкә үттеләр. Әтисе кабернең аяк очына утырды, «Ясин-шәриф» укыды. Бераздан соң йозакны урынына асып, төрбәдән ераклаштылар. Бу көнне Газиз әтисенең мөршиде белән булган якын мөнәсәбәтен һәм әүлияның тәсарруфын – идарә итү сәләтен күрде. Гыйльми хәл иясе, суфый булган әтисенең тормыш алып бару үрнәге, шәехен зиярәт кылгандагы гаҗәеп вакыйга шулчакта күңеленә дини юллар белән кызыксыну оеткысын салды. Ә зираттагы төсле могҗизаи вакыйгалар аны гомере буе озата барды...».*

### ***Төркиядә Солтановлардан тагын кемнәр бар?***

Төркиягә күченгән Мәхмәт мулла Солтановның 5 баласы булган. Хәзерге вакытта аларга кагылышлы берникадәр күләмдә мәгълүмат туплый алдым. Шуларга нигезләнеп, Солтановлар нәселеннән булган һәм аларга бәйле кайбер исемнәргә тукталасым килә.

*Фәрхүндә һәм Саимә Өнҗәл*

Төркиянең Бурса шәһәрендә яшәүче татар хаттат Саимә ханым Өнҗәл – Абдулгазиз Беккинә әл-Казани кебек үк Солтановлар нәселеннән. Саимә ханым бертуган апасы Фәрхундә белән бергә шәһәр үзәгендә тарихи урын Тозхан базарындагы әтиләре – хат сәнгатьчесе Мәхмәт Харис Өнҗәлдән калган ательеда хаттатлыкны дәвам итә. Саимә ханым сөйләвенчә, алар – Казаннан 1870–95-нче елларда Төркиягә күчәргә мәҗбүр булган Солтановлар нәселеннән. Һәм, нәкъ менә ул, «Гыйлем тарату җәмгыяте» идеясен тормышка ашырган кешенең Абдулгазиз Беккинә булганын раслады төсле. Туганы хакында сөйләгәндә, болай аңлатты: «Әбием белән Абдулгазиз Беккинә – туганнан туганнар, без монда кузеннар дип әйтәбез. Әтием Абдулгазиз абыйның малае Мәхмүт белән күрешеп торды. Төркиядә Беккинә: «Алдан – гыйлемне, соңыннан динне өйрәнегез», – дигән беренче тарикать кешесе. Төркиядә аңардан алда мондый сүз әйткән кеше юк. Һәрвакыт

дин өйрәнегез, диләр. Әмма динне өйрәнербез, гыйлем дә кирәк бит. Әтием әйтә иде: «Гыйлемсез дин – аксак, динсез гыйлем – сукыр булыр», – дип. Аллага ышанмаган кеше гыйлемне аңлый алмый. Бу нигә алай? Ничек алай булган? Күп сорауларга җавап табылмас. Асылда бит, бөтен дөнья күләмендә карасак, бары тик безнең болгар бабаларыбыз каләм белән, ягъни гыйлем белән исламга килгән. Һәм гыйлем белән исламга чакырганнар да».

Саимә ханым әйтүенчә, Солтановлар турындагы белгәннәре Төркиягә килгәннән соңгы чорга карый. Аңа кадәрге Россиядә кем булганнар, ничек яшәгәннәр, бу турыда өлкәннәр һич сөйләмәгәннәр, курыкканнар. Шул сәбәпле хатирәләр аз. Шуңа карамастан, әтиләре аларның татар икәнен әйтеп тәрбияләгән. «Аллага мең шөкер, без яттык-калыктык, гел татар дип сөйләделәр... Бездә бабамнар хатирәсе – Коръән саклана. Ул – әти ягыннан әбиемнең әнисенең Коръәне. Әбием Казанда туган, аны Төркиягә әтисе 3 яшьлек вакытта алып килгән, дип беләм. Өлкәннәр аңлата иде. Казанда вакытта рус гаскәриләре килде, дип. Өйдәге люстраларны ваталар икән, шунда әбием бик үртәлгән. «Алыгыз үзегезгә, өегезгә элегез. Ватмагыз, кырмагыз...» – дигән. Шунда аңар: «Йөрәгең янамы, татар хатыны?!» – дигәннәр. Тагын да ватып-җимергәннәр. Төркиягә килгәннәр кемлекләрен яшергәннәр. Кыенлыклардан качтык, дигәннәр, сөйләргә курыкканнар».

Саимә ханымның бабалары ядкаре булган китап тышлыгын галим Фәрит абый Яхин төгәл укырга ярдәм итте: «Каләме-Шәриф. Мөсхафе-шәриф, бәлидаи Казанда табигъ Вячиславта, Лаеш мосафәте Максабашы карьясенең Мөхәммәтзариф бине Әхмәтҗан ихраҗаты илә 1301 сәнә Мөхәррәм әүвәлендә ибтида кылынды. Басмасына изән вирелде Санкт-Петербурхта 28-нче апрельдә 1883 нче сәнәдә (Бу мусхаф шәриф Казанда Вячеслав типографиясендә Мөхәммәдзариф бин Әхмәтҗан тарафыннан (яки мөдирлегендә) һиҗри ел белән 1301 елның мөхәррәм ае башында басылган. Басма өчен рөхсәт Санкт– Петербургта бирелгән, 1883 елның 28 нче апрелендә (милади календаре буенча)». Саимә ханым белән кат-кат сөйләшүләрдән соң, нәсел җебен тикшерә торгач, китапны Төркиягә алып килүче һәм аның иясе Казанда яшәгән Мәхмәт мулла Солтанов булганы ачыкланды. Әлеге мулланың, ачыклый алган кадәре, шәҗәрәсенә күз салыйк.

Мәхмәт (Мөхәммәт) мулла хакында гаилә шәҗәрәсендә туган урыны буларак Үзбәкстан, Ташкент күрсәтелә. Саимә ханымнан мулланың ни өчен Ташкент белән бәйләнүе хакында сорагач, өлкәннәрнең нидер сөйләгәннәрен исенә төшерде, әмма төгәл генә хәтерли алмады. Балалары: Абдураһман (1843–1913, Ташкентта туган. Төркиядә, Искешәһәрдә ва-

фат), Али Минһаҗ (1880–1910, Дагыстанда туган. Төркиядә, Истанбулда вафат), Хөсәен, Харис (?–1921, Татарстан, Казанда вафат), Мөнирә.

Мәхмәт мулланың алда телгә алынган оныклары:

Харис хәзрәтнең улы – Истанбулда Казан әүлиясы буларак танылган һәм күп сандагы шәкертләр тәрбияләгән Абдулазиз Беккинә.

Харисның кардәше Хөсәеннең ике кызы була. Мөшфикә һәм Мөнәввәр. Мөшфикәнең улы – «Гыйлем тарату җәмгыяте»нең (İlim yayma cemiyeti) рәсми оештыручыларыннан берсе, интервью биргән Өмәр Лүтфи Таке.

Мөнәввәрнең малае – Харис Өнҗәл – Бурса шәһәренең танылган хаттаты, аның кызы – хаттат Саимә Өнҗәл.

*Камил Абдүш*

Истанбулның Тузла районында зур тарихка ия бер гаҗәп урын бар. Шәһәрдәге бердәнбер термаль чыганак урнашкан җир ул. Төрки телдәге язмаларда гасырлар дәвамында халыкның биредәге чишмә суларын эчеп шифа күргәне хакында шактый мәгълүмат язылган. Мәсәлән, Әүлия Чәләби үзенең сәяхәтнамәсендә ел саен июль аенда, бөтен Истанбулдан һәм башка төбәкләрдән меңләгән кеше бирегә җыелуы һәм суны эчкәннән соң, Аллаһ ярдәме белән, бик күп чирләрдән котылулары хакында җентекләп тасвирлый. Шулай ук Госманлы армиясе гаскәриләре үләр чиккә җиткән атларын монда калдырып киткәч, кайтышлый аларның сәламәтләнүен күрүләре турында хикәятләр бар. Төркия Җөмһүрияте төзелгәч, минераль суларга бәйле яңа тарих башлана. Медицина туризмына хезмәт күрсәтү өчен шифалы суларны төрле төркемнәргә аеру алга куела, чөнки Ататөрек сәламәтлек саклау өлкәсенә аерым бер игътибар бирә. Шул елларда термаль су чыгынаклары тикшерелә, аларның файдалы булуы фәнни яктанраслана. 1926 елның 10 декабрендә Ататөрек имза куйган Министрлар Кабинетының карары нигезендә, Сәүдә министрлыгының рәсми хаты чыга. Һәм анда Тузла сулары өчен «Камил бәйгә 77 елга куллану хакы» бирелде, дип язылган. 1927 елда 100 мең лирага ия «Тузла эчә торган минераль сулар» төрек аноним ширкәте корыла. Әлеге ширкәтнең гамәлгә куючылары дүрт доктор һәм бер эшкуар. Ататөрекнең табиблары Мәхмәт Камил, Акил Мухтар, Нешет Өмер, Хикмәт һәм бизнесмен Камил Абдүш. 1929 елда бу шифалы минераль суларны халыкка сату компаниясе дә Камил әфәндегә бирелә. 1930–1934 елларда биредә «Grand Hotel» («Бөек отель») төзелә, 3 мең агач утыртыла. Ул җир Төркиянең саулык сагында торган зур бер мөһим үзәгенә әверелә. Бирегә Төркиянең беренче Президенты Кәмал Ататөрекнең еш килүе мәгълүм, ул кала торган бүлмә бүгенге көндә музей буларак кулланыла. Ләкин күп еллар дәвамында уңышлы эшләп килгән оешма, 1970 елда Камил Әбдүш вафатыннан соң, кызганыч хәлгә төшә. Чөнки аның үзеннән соң калган

16 варисы тиешле дәрәҗәдә эш йөртә алмый, биредә 20 елга хезмәт күрсәтелү туктатыла. 1990 елда бу милекнең яртысыннан күбрәген башка бер кеше сатып ала, шуннан соң аңа кабат җан керә. Бүгенге көндә төрле дәвалану ысулларын тәкъдим иткән отель эшләвен дәвам итә. Тозлы районындагы заманында тоз чыгарылган күл «Камил Абдүш күле» дип аталып йөртелә, чөнки күл дә Камил әфәндегә бирелгән була. Әмма варислары тиешенчә хуҗа була алмагач, кул кабат дәүләт кулына күчерелә. Бүгенге көндә күл тирәсен дәүләт тарафыннан заманча проектлар нигезендә яңарту турында сүз бара.

Кем соң ул Камил Абдүш һәм аның Солтановлар нәселенә нинди катнашы бар? Ул – Казан тарафыннан булган Исмәгыйль хаҗи һәм Мөнирә Абдүшнең улы. Мөнирә – Мәхмәт мулла Солтановның кызы. Димәк, без хәзер, аз дигәндә, Истанбулда татар кешесе исемен йөрткән күл бар, дип әйтә алабыз... Әлеге күл Истанбулда яшәүчеләр өчен күп төрдәге күчмә кошлар яраткан урын буларак бик таныш. Чөнки анда кошлар күзәтергә йөриләр.

*Кәмал Локманның хатыны Сабахат ханым һәм аның абыйсы*
*Һилми Зыя Өлкән*

Солтанов фамилиясе белән мин Төркиянең беренче нефть инженеры Кәмал Локман хакында бәян язганда да очраштым. Ул – татар мөһаҗирләреннән С. Максуди, Г. Исхакый, С. Гыйффәт, Ә. Тимер кебек мәшһүрләр белән таныш булган шәхес. Заманында Исхакый татарлар җәмгыятен җитәкләүне К. Локман дәвам итәр, дип уйлаган. Әмма ул вакытта дәүләт кануннары дәүләт хезмәткәрләренә җәмгыять җитәкчесе булуны тыя, Кәмал Локман, кара алтын чыгару эшләрен башлап йөрүче дәүләт хезмәткәре буларак, иҗтимагый-сәяси эшләр башында тора алмаячагын, ә оешмага ярдәмче буларак күбрәк файда китерәчәген аңлап, баш тарта. Менә шушы шәхеснең җәмәгате Сабахат ханымга килик. Ул – Төркиянең беренче хатын-кыз мөгаллимнәреннән, Төркиянең танылган фәлсәфәчесе, профессор социолог Һилми Зыя Өлкәннең (1901–1974) бертуган сеңлесе. Әниләре исә татар кызы Мөшфикә – Кәрим хәзрәтнең (1805–1865) оныгы. Бу хакта Кәмал Локман һәм Сабахат ханым вафатыннан соң язылган кайгы уртаклашу мәгълүматларыннан аңлашыла.

Берничә төрекчә мәкаләдә Абдулгазиз Беккинәнең Сабахат ханымга, профессор Һилми Зыя Өлкәнгә гаилә мөнәсәбәте барлыгы әйтелә. Әмма бу гаилә шәҗәрәсен тикшергәч, аларның Казанның башка бер данлыклы шәехе, Истанбулда вафат булган Кәрим хәзрәт торыннары булуын ачыкладым. Бу ике нәсел: Мәхмәт мулла һәм Кәрим хәзрәт нәселе ничек бәйләнгән соң? Бәйләнеш Абдулгазиз Беккинәнең әнисе тарафыннан булып чыкты. Бу хакта Әхмәт Ерсөзнең «Абдулгазиз Беккинә хәзрәтләре»

дип аталган китабында шундый җөмләгә тап булдым: «Һилми Зыя Өлкән белән туганнар иде. Кыз кардәшләрнең балалары кебек бер якынлыклары бар иде». Димәк, Абдулгазиз белән Һилми Зыяның әниләре: Фатма һәм Мөшфикә кардәш булырга тиеш. Әмма Мөшфикәнең Кәрим хәзрәт нәселеннән булуын ачыкласам да, әлегә Фатманың фамилиясен, кем кызы булуы турында төгәл мәгълүмат таба алмадым.

*Мәҗит Сакмар һәм аның хатыны Алия ханым*

Албай Мәҗит Сакмар (1888–1978) – Казан татары, Сакмар авылында туган. 1905тә Истанбулга күченә. Беренче Бөтендөнья, Госманлы империясенең Балкан һәм Төркиянең Бәйсезлек сугышларында катнаша. Төркия армиясенең Һава оешмасын төзүчеләрнең берсе, Һава Көчләре киңәшчесе. 1954 елдан үлеменә кадәр «Идел-Урал Милли Мәркәзе» җитәкчесе. Мәҗит Сакмарның һәм хатыны Алия ханымның сәясәтче, язучы Гаяз Исхакый белән берлектә җыелышларда катнашуы билгеле. Бу хакта Али Акыш хатирәләреннән укырга мөмкин. Шулай ук Г. Исхакый мәрхүм булганнан соң, татарлар, Мәҗит Сакмар өендә җыелып, җитди карарлар кабул итәләр. 1954 елның 12 августында үткән бу җыелышта Мәҗит Сакмар – җитәкче, ә аның ярдәмчесе итеп Кәмал Локман сайлана.

Ире белән бергә милли туплантыларга йөргән Алия ханым (1902–1978) кем соң? Алия – Мәхмәт мулланың улы Минһаҗ Солтанов кызы.

***Йомгак***

Мәхмәт мулла нәселе мисалында мөһаҗир дин әһелләренең балалары һәм оныкларында татарлыкны саклау күренә, Хәтта бу башка татар мөһаҗирләрнең балалары белән гаилә коруларында күренә. Дин әһелләре һәм аларның балалары, оныклары үзара элемтәдә торганнар, димәк. Һәрхәлдә Төркиягә күченгәннәрнең баштагы өч буыны, дип әйтергә мөмкин. Шулай да еллар узган саен нәсел әгъзаларының күбесе татарлыктан ерагая барган, исемнәре үк төрекләшкән кебек. Истанбул татарлары тормышына кагылышлы вакыйгаларда, чараларда аларның активлыгы күренми. Әлбәттә, бу әлегә бер күзәтү, дип әйтергә мөмкин. Нәселне дәвам итүчеләр белән танышуларны дәвам иткәндә яхшырак беленер.

Төркия дә башкалар кебек үз сәяси, иҗтимагый системасы, инкыйлаблары, каршылыклы тарафдарлары белән яшәгән бер ил, илдәге вазгыять исә аның җирле халкына гына түгел, һәркемгә йогынты ясый. Ә язмада телгә алынган Мәхмәт, Кәрим, Исмәгыйль кебек хәзрәтләр үз җирләрендә, Россиядә калсалар?! Балаларының язмышы кыл өстендә калган булыр иде. Төркия исә алар өчен, нинди генә кыен шартлар белән очраштырса да, ничек кенә йогынты ясаса да, гомер биргән ил. Һәм, татар нәселләренең гыйлем, алгарыш энергиясе биредә үзенә урын тапкан. Хәзер иң кызганычы – бу гыйлем, алгарыш гамәлләре башында торганнар төре-

кләр өчен онытылган, үткәндә калган сәхифәләр кебек... Ә татарлар өчен аларның күбесе бөтенләй мәгълүм түгел.

**Әдәбият**


1. Ahmed Ersöz. Abdülaziz Bekkine hazretleri, İzmir: Nil Yınlari A.Ş., 1992.
2. Ali Akış. Aklımda kalanlar, Ankara: Neyr Matbaacılık, 2002.
3. Artunkal, Gülseren, «Hayatı ve Eserleriyle Babam Ülken», Sosyoloji Konferansları, 1979 Yılı, 17. Kitap, İstanbul: İstanbul Üniversitesi İktisat Fakültesi Sosyoloji Enstitüsü Yay., 1979.
4. İlim Yayma Cemiyeti Bülten, "Ömer Lütfi Take ile Röportaj", İ.Y.C. yay., S.15, İstanbul, 2007.
5. Ekrem Şama. Allah Dostu Erbakan. İstanbul: Ege Basım Yayın, 2015.
6. Orhan Okay. Silik fotoğraflar, Ankara: Özener Matbaası, 2005.
7. Milliyet. 1970. № 12250.
8. Milliyet. 1978. № 12448.
9. Özel Şahingiray. «Atatürk'ün Son Nöbet Defteri», Ankara: Türk İnkılap Tarihi Enstitüsü Yayınları, 1955.
10. Eyyüp Sanay. Hilmi Ziya Ülken, Gazi Üniversitesi Yay., Ankara, 1988.
11. Vergili Ayhan. Hilmi Ziya Ülken Kitabı, Kitabevi Yay., İstanbul, 2006.

**Шәхесләребез**

**Известные личности**

***Б.А.Заһиров***

## «БИЛГЕСЕЗ» ТӘРӘККЫЯТ КӨРӘШЧЕСЕ

### *СССРда беренче цифрлар белән эшләүче хисаплау машинасының проектын ясаучы Бәшир Рәмиевнең тууына – 100 ел*

*Башир Рамеев – первый разработчик проекта и конструктор первых серийных цифровых электронных вычислительных машин «Стрела», «Урал», сегодня известен очень узкому кругу специалистов. Несмотря на унижения и лишения в молодости, он поднялся до уровня конструктора самой передовой техники в СССР. Разработчики первой серийной ЦЭВМ «Стрела» получили Сталинскую премию (в 1954 г.).*

1948-нче елның 4 декабрендә СССРның Министрлар Советының яңа техниканы халык хуҗалыгына гамәлгә кую буенча дәүләт комитетының патентлар бюросы «*Саннар белән эшләүче электрон хисаплау машинасы*», дигән яңа ачышны терки. Уйлап табучыларга – Б.И.Рәмиев белән И.С.Брукка, бу ачышны раслап, 10475 саны белән беркетелгән, беренчелекне тәгаенләүче таныклык бирелә.

СССР чорында яшәгән татарлар күбесе татар шагыйре Дәрдемәндне белсәләр дә аның оныгы Бәшир Искәндәр улы Рәмиев (атасының фамилиясе Рәмиев) – галим, СССРда беренче электрон хисаплау машиналары конструкторын белүчеләр бик сирәктер. Кызганычка каршы, ул бүгенге көндә дә күпләр өчен «билгесез тәрәккыят көрәшчесе» булып кала. Бәшир Рәмиев (1918–1994), кимсетелүләргә дучар булып, үзлегеннән радиотехника, электроника һәм аларга якын торган фәннәрне тирәнтен өйрәнеп, уйлап табучы, галим югарылыгына күтәрелә. Бәширгә яшьтән үк ятимлектә, «халык дошманының улы» кушаматы белән яшәргә туры килә. Әмма аңа нәсел тамыры тормыш авырлыкларыннан сыгылмаска, алга куйган максатка ирешергә көч биргән, күрәсең. Аның тормыш юлы маҗаралы роман кебек, кыерсытулар, каршылыклар белән тулы, шул ук вакытта уйлап табучы, галим буларак, дәүләт алдында кылган зур хезмәтләре белән кызыклы һәм данлыклы.

Әлмәт төбәгендә туган галим Риза Фәхреддин төзегән Бикчура хан шәҗәрәсе билгеле. Аның буенча, XIX һәм XX гасырларда яшәгән күренекле татар эшкуарлары һәм беренче гильдия сәүдәгәрләре (купцы) Рәмиевләрнең бабалары да башта Өфе өязе Байлар волосте Әлмәт, Мортыш Тамак авылларында (хәзерге ТР Сарман районы), Нәдер волосте Тайсуган авылында да (хәзерге ТР Әлмәт районы) яшәп, XVIII гасыр ахырында Стәрлетамак өязенә күчеп китәләр, ә соңрак Оренбург шәһәренә киләләр.

Бу шәҗәрә Бикчурадан башлана, ул Җаек елгасы башы Карагай дигән урында яшәгән икән, кайсы гасырдадыр балалары вә оныклары Минзәлә һәм Зәй елгалары буйларына килгәннәр. Нәсел тармагы түбәндәгечә: Габдулла – Илаз – Симән – Йагькуб – Йанбулат – Бикмөхәммәт – Туймөхәммәт – Әлмөхәммәд. Әлмөхәммәднең бер улы Рәхмәтулла Зәй елгасы буендагы Әлмәт-мулла авылында имам вә мохтәсиб буларак хезмәт итеп вафат булган. Хәзерге Әлмәт төбәге тарихын өйрәнүчеләр башка уллары Габдерәхим белән Рәхманкул (Рәмәй) Тайсуган (Зәйсуы) авылында яшәгәннәр, дип тәгаенлиләр. Шулай ук Әлмөхәммәднең бертуганы Габдерахман (Муртыш Тамак авылында 1691-нче елда туган) озак вакыт белем алу юлында йөреп, галим булып җитешкән, Тайсуган авылында имам һәм ахун булган [Әхмәтҗанов: 2011].

Зәй буенда яшәгән Рәхманкул оныгы – Мөхәммәтсадыйк, атасы Габделкәрим күченеп утырган Акидел елгасы буендагы Җиргән авылында яшәп, башта Оренбург, Стәрлетамак шәһәрләренә барып, ефәк тукымалар, чәй, һ.б. товар белән сатучылык итеп йөри, соңрак Урал тавы буендагы Сакмар елгасы янында, Юлык авылында йорт сатып алып (1862-нче елда), сабын ясау фабрикалары ачып җибәреп, зур мөлкәт туплый.

Соңрак Мөхәммәтсадыйк алтын приискалары сатып алып, алтын чыгару белән шөгыльләнә башлый һәм бу эшкә күп көч куя, акча кертә (20 приискасы була). Уллары Мөхәммәтшакир (1857–1914) һәм Мөхәммәтзакир (1858–1921) аталары башлаган эшне тагын да үстерәләр. Аларның XX гасыр башында 79 җирдә алтын приискалары булып, алтын чыгаруны оештырып, зур байлык туплап, беренче гильдия сәүдәгәрләр югарылыгына ирешеп, чит илләр белән дә сәүдә итәләр.

Зур капиталга ия булган Рәмиевләр губернада татар мохитен, мәдәниятен үстерүгә күп акча кертәләр һәм хезмәт куялар. Алар губернада дистәләгән мәчет, мәдрәсәләр ачалар. Мөхәммәтзакир, үзенең басмаханәсен ачуга ирешеп, татар телендә «Вакыт» гәзитен һәм «Шура» журналын бастырып чыгара башлый. Шулай ук бу басмаханәдә Коръән, мөселман динендә укыту китаплары, Европа иле язучыларының китапларын рус

һәм татар теленә тәрҗемә итеп, күп данәдә чыгара башлыйлар. Мөхәммәтзакир үзе дә Дәрдемәнд исеме астында шигырьләр яза, алар бүген татар поэзиясенең алтын фондына кертелгәннәр.

Мөхәммәтзакир Рәмиев 1906-нчы елда Оренбург губернасыннан Беренче Дәүләт Думасына сайлана. 1917-нче елда Казанда узган Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда катнаша, Вакытлы Милли дәүләтнең Финанс министрлыгы әгъзасы итеп сайлана. 1918-нче елдан соң большевиклар бу нәселгә күп бәлаләр алып киләләр: аларның алтын приискалары, типографияләре, башка мал-мөлкәтләре, йорт-җирләре тартып алынып, Совет дәүләте карамагына күчә.

1919-нчы елда Оренбург губернасында тиф һәм холера чире тарала, Мөхәммәтзакирның кызы да авырып вафат була, үзе Орск шәһәрендә яшәгән улы Искәндәр гаиләсенә кайта, 1921-нче елда шунда вафат була.

Мөхәммәтзакирның гаиләсендә 8 бала була, улы Искәндәрне, Петербургта гимназия тәмамлагач, шөһрәтле Фрейберг тау академиясенә укырга җибәрәләр. 1914-нче елда Германиядә укуын тәмамлап, атасы кулы астында эшли башлый, гаилә кора, соңрак аны бакыр эретү заводының баш мөхәндисе итеп билгелиләр. Искәндәрнең тагын бер яраткан шөгыле була, ул да булса үз куллары белән радиоалгычлар ясау. Искәндәр җәмәгате Шәрипзәдә белән (дворян Дашковлар нәселеннән булган) озак яши алмый, уллары Бәширгә өч яшь булганда ул вафат була. Үсә төшкәч, әтисенең шөгыле – радиоалгычлар ясау белән Бәшир дә кызыксына башлый.

Искәндәр Октябрь инкыйлабыннан соң да «Башкирзолото» трестында эшләвен дәвам итә, әмма 1938-нче елда кулга алына һәм, «халык дошманы» ярлыгы тагылып, мәҗбүри хезмәт лагерена озатыла, шунда вафат була. Ул 1957-нче елда гына аклана.

Бәширгә «халык дошманы»ның улы булганга, урта мәктәптә укырга ирек бирмиләр, ләкин ул Уфада 10 классны тәмамлау турындагы шәһадәтнамәне үзлегеннән укып ала һәм, Мәскәүгә барып, Энергетика институтына укырга керә. Моннан да аны «халык дошманы»ның улы икәнен белеп алып, икенче курстан куып чыгаралар.

Берәр «йомшак кеше» булса югалып, бернинди чарасыз калыр иде, әмма ул туган ягына кайтып, ничектер, Башкорт радиосына радиотехник булып урнашып, ипи-тозлык акча юнәтергә мөмкинлек таба. Аңа тагын икенче бәла килә, үпкәсе авырта башлый, Кырымга дәваланырга китә. 1940-нчы елны ул Мәскәүгә килә һәм анда элемтә буенча Үзәк фәнни-тикшеренүләр институтында техник булып эшли башлый, берничә яңа прибор уйлап табып, аларның проектын тәкъдим итә.

Ватан сугышына үз теләге белән китә һәм элемтә батальонында хезмәт итә, аның осталыгын күреп, Югары Хәрби Ставканың идарәсенә мәгълүматны шифрлау бүлегенә алалар. 1944-нче елны армиядән чакырып алып, радиолокация аппаратлары проектлаучы академик А.И. Берг җитәкләгән институтка (ЦНИИ-108) эшкә юллыйлар.

Бәшир 1948-нче елның май аенда Мәскәү энергетика институтының механик рәвештә дифференциаль тигезләмәләрне хисаплаучы җайланмалар проектлаучы лабораториясендә эшли башлый, аның башлыгы математик И.С. Брук була. Эштән бушаган вакытта (эшли башлаганнан соң өч ай дигәндә) саннар белән автоматик рәвештә эшләүче хисаплау машинасының проектын ясый һәм лаборатория мөдире Брук белән бергә патентлар бюросына тапшыра.

Бәширгә бу проектны тормышка ашырырга мөмкинлек бирмиләр (тагында шул «кара сакалы» комачаулагандыр), аны Мәскәүдән бик еракка, СССРның Ерак Көнчыгышына, хәрби хезмәткә озаталар. Аның турында, Америка белгечләре атом-төш коралын проектлауда электрон хисаплау машиналары кулланулары турындагы мәгълүмат «югары органнарга» барып җиткәч кенә искә төшерәләр. Аны тиз генә армия хезмәтеннән чакыртып алып, СССРның Машиналар һәм приборлар төзү министрлыгының хәрби көчләргә электрон хисаплау машиналары (ЭХМ) төзү өчен махсус оештырылган СКБ-245 конструкторлар бюросына лаборатория мөдире итеп билгелиләр. Моның өчен СССРның машиналар һәм приборлар төзү министры П.И. Паршинга Бәшир Рәмиевкә ышанычын белдерү турында «кәгазь» тутырырга туры килә. Бу бюрода иң беренче итеп ЭХМ «Стрела» (ук – татарларның Ауропаны яулаган коралы) ясалып, ул күп данәдә чыгарыла башлый. СКБның баш конструкторы булып Ю.Я. Базилевский саналса да, чынында бу хезмәтне Бәшир Рәмиев башкара («халык дошманы» улының баш конструктор булырга тиеш булмаган). Шушы урында эшләү вакытында Бәшир Рәмиев СССРның иң абруйлы Мәскәү инженерлык-физика институтында (МИФИ) электрон хисаплау машиналары буенча укыту эше алып бара, ләкин аны бу эшеннән читләштерәләр («халык дошманы»ның улы Коммунизм төзүче яшь буынга белем бирергә тиеш булмаган).

1954-нче елда югары сыйфатлы ЭХМ «Стрела»ны ясаган һәм күпләп чыгаруны оештырган җитәкчеләр: СКБ башлыгы М.А. Лесечко, баш конструктор Ю.Я. Базилевский, баш конструктор ярдәмчесе Б.И. Рәмиев Сталин премиясенә лаек булалар (1954-нче елдан Дәүләт премиясе дип аталган).

«Стрела» атамалы ЭХМны ясап чыгаруны оештыргач, аның алдына яңа әһәмиятле дәүләт бурычы – СССРның халык хуҗалыгы өчен күпләп

ЭХМлары ясап чыгаруны оештыруны куялар. 1953-нче елдан ул, яңа БЭСМ атамалысы ЭХМнан (конструкторы – С. А. Лебедев) күпкә отышлы, очсызракка төшүче «Урал» атамалы ЭХМны күпләп чыгару өчен проект ясый башлый (Урал таулары – кәшфиятченең туган төбәге). Шуның өчен ул 1955-нче елда Мәскәүдән үзе белән эшләгән яшь һөнәрмәндләр белән Пенза шәһәренә, НИИ УВМның баш констукторы вазифасын башкарырга күчеп килә. Бу беренче буын «Урал-1» ЭХМларын Пенза шәһәренең «Аналитик хисаплау машиналары» заводында ясый башлыйлар һәм алар 183 данәдә 1961-нче елга чаклы чыгарылып, конструкторлык бюроларына, институтларга, хәтта «Байконур» космодромының очышлар белән идарә итү үзәгенә дә куелалар.

Соңрак, 1965–68-нче елларда, Бәшир Рәмиев яңа, икенче буын, техник эшләнеше ягыннан да, язылган программаларның эшләве ягыннан да бер үк булган ЭХМнарны ясап чыгаруга керешә һәм егерме төрдәге (модельдәге) ЭХМлар эшләп чыгаруга ирешә.

Бәшир Искәндәр улы Рәмиевкә электрон хисаплау машиналарын уйлап табуда һәм аларны халык хуҗалыгында гамәлгә куюдагы зур казанышлары өчен, диссертация якламыйча гына, югары белем дипломы булмаса да, фәнни дәрәҗә – техник фәннәр докторы исеме бирелә. Шулай ук, ул «РСФСРның атказанган уйлап табучысы» исеменә лаек була.

СССРда 1960-нчы еллар уртасына 50гә якын төрле проектлар белән ЭХМнар эшләнгән һәм аларны ясаганда үзгә радиокомпонентлар кулланылган, һәрберсенә үзенчәлекле программалар язарга туры килгән, бу җитешсезлекләр хисаплау машиналары сәнәгатенең үсешенә комачаулык китерә башлый, бер архитектурадагы хисаплау машиналарын ясау (Ряд Единой Системы ЭВМ) бурычы алга килеп баса. Бу проект өчен 1968-нче елдан яңа фәнни-тикшеренү үзәге (НИЦ ЭВТ) оештырыла, аның баш конструкторы урынбасары итеп Бәшир Рәмиев билгеләнә (конструкторлар советы рәисе). Ни кызганыч, эшләр нәкъ Крылов мәсәлендәгечә килеп чыга, көндәш институтларның һәрберсе үзенең проектын алга сөрә, бердәм фикергә килә алмыйлар. Бәшир Рәмиев бу торгынлыктан чыгу өчен Британиянең яңа архитектурадагы «Система-4» атамалы компьютерлар җитештерүче «АйСиЭл» фирмасы белән бергә хезмәттәшлек итү нияте белән сөйләшүләр алып бара башлый.

Бердәм ЭХМ системасы проектының юнәлешен очраклы вакыйга икенче юлга бора (ул чорда еш кына шундый хәлләр булган). СССРның Министрлар Советы рәисе А. Н. Косыгин җитәкчелегендәге делегация Америка Кушма Штатларына бара, анда аларны «АйБиЭм» фирмасы белән таныштыралар һәм яңа «IBM-360» компьютерларын күрсәтәләр,

бу компьютерларның сәнәгать, фән, космос, хәрби өлкәләрдә дә уңышлы кулланылуы турында сөйлиләр. Бу сөйләшүләрдән соң СССРның тәрәккыяткә этәргеч булырга тиеш булган Бердәм ЭХМ системасы проектына соңгы «нокта куела», илдә «АйБиЭм» фирмасы архитектурасы нигезендә ЭХМлар ясап чыгара башлыйлар. «АйБиЭм» фирмасы башта бу проектта катнашу теләген белдергән булса да, соңрак хезмәттәшлек итүдән баш тарта, чөнки информацион технологияләр өлкәсендә дә «салкын сугыш» башлана. СССРда чыгарылган Бердәм система (Ряд ЕС ЭВМ) буенча ясап чыгарылган ЭХМлары Америка, Англия, Япония машиналары белән көндәшлек итә алмадылар, бу чорда СССРда җитештерелгән электрон компонентларның сыйфаты түбәнрәк булуы, хисаплау машиналарының җитештерүчәнлегенә дә йогынты ясады. Бу Бердәм системадагы ЭХМлар чит ил технологиясе буенча (IBM-360, IBM-370 «клоннары») 1980-нче еллар ахырынача ясап чыгарылып, СССРның хисаплау машиналары сәнәгатен «билгесезлеккә» китереп җиткерделәр. Ни кызганыч, Бәшир Рәмиевкә дә үзе башлаган һәм югарыга күтәргән хисаплау системалары сәнәгатенең җимерелүен үз күзләре белән күрергә туры килә.

Бәшир Рәмиев хезмәт юлының соңгы чорында, СССРдагы тәрәккыяткә юнәлеш бирүче иң югары җитәкче урыннарда эшләп, Фән һәм Техника буенча Дәүләт Комитеты җитәкчесенең урынбасары вазыйфасын башкара. СССРда ракета техникасы, космонавтика фәне күтәрелеш алган чорда космик аппаратлар белән идарә итү проектларында да катнаша (юкка гына СССРда беренче канатлы ракета «Искәндәр» дип аталмагандыр).

*P.S.* 1990-нчы еллар башында, СССРда хисаплау системалары тәмам эшләп чыгарылмый башлаган чорда, Бәшир Рәмиевнең шәкертләре яңадан Британиянең «АйСиЭл» фирмасына йөзләрен бордылар һәм моның нәтиҗәсе булып, 1991-нче елда Казан хисаплау системаларын җитештерү берләшмәсе (КПО ВС) белән Британиянең «АйСиЭл» компьютерләр җитештерү компаниясе арасында килешү төзелеп, «КПО ВС-АйСиЭл» ширкәте оештырылды (РСФСР Финанс министрлыгында 1991-нче елның 2 июлендә беркетелгән). 1994-нче елда, икътисад үзгәрешләре аркасында, ул акционерлар җәмгыяте итеп үзгәртелә (2002-нче елдан Британиянең «АйСиЭл» компаниесе үзе Япониянең «Фуицу» корпорациясенә карый).

«Эксперт» журналының билгеләве буенча, «КПО ВС-АйСиЭл» компаниясе 2011-нче елда Россиядәге информация технологияләре белән шөгыльләнүче өченче урындагы компания итеп күрсәтелә. Соңгы вакытларда алынган мәгълүматлар буенча, «КПО ВС-АйСиЭл» компаняесе

2012-нче елда Казан шәһәре янындагы Усад авылы кырында электрон хисаплау, автоматика җайланмалары чыгару өчен яңа завод төзи башлаган. 2013-нче елның яз аенда заводның беренче корпусы төзелеп, ул сәнәгать өчен электроника компонентлары һәм компьютерлар, ноутбуклар, башка җиһазлар эшләп чыгара башлаган.

*Татарстан Республикасында гына булса да, хисаплау системалары өлкәсендә белем алучы алдынгы студентларга «Рәмиев стипендиясе» билгеләнсә, ә галимнәргә алгарышка илтүче хезмәтләре өчен «Бәшир Рәмиев лауреаты» исеме тапшырылса, бу бик күркәм гамәл булыр иде.*

**Әдәбият**

1. Бадрутдинова М. Ш. История жизни замечательных людей России – Башира Искандаровича Рамеева, его отца и деда. ВКМ. Раздел: Галерея славы // www.computer-museum.ru.
2. Журнал «История науки и техники», 2002. № 1.
3. Казакова И. А. История Пензенской научной школы вычислительной техники. ПГУ, 2012.
4. Хамидуллин Л. Дэрдменд. Казань, ТКИ. 2010.
5. Әхмәтҗанов М. И. Татар шәҗәрәләре. Казан. 2010.

## ОБ ОДНОМ КРУПНОМ УЧЕНОМ-ХИМИКЕ ИЗ СИБИРСКИХ ТАТАР

### *РЕВА САФАРОВИЧ САГИТУЛЛИН (09.03.1931–02.06.2010)*

Рева Сафарович Сагитуллин родился 9 марта 1931 г. в с. Еланское Дубровинского района Тюменской области. Первые четыре класса он закончил в татарской школе. Родители рано поняли, что дальнейшее обучение на татарском языке не перспективно для одаренного мальчика. Желание его отца, Сафара Хабидулловича, обеспечить сыну Реве возможность получения хорошего образования, было главным стимулом собственного карьерного роста и географического перемещения из таежного села в Москву. Среднюю школу Рева Сафарович окончил в г. Петушки Московской области, в 1949 г. он поступил в МГУ им. М.В. Ломоносова. В 1951 г. его отец получил должность зам. главного бухгалтера в Министерстве легкой промышленности, и семья Сагитуллиных переехала в Москву. Выбор профессии Рева Сафарович сделал в четвертом классе после чтения книги Якова Перельмана «Занимательная химия». Судьбу ученого предопределило знакомство с профессором А.Н. Костом в практикуме органической химии. На третьем курсе университета Рева Сафарович приступил к научным исследованиям под его руководством. А.Н. Кост, создатель научной школы химиков-гетероциклистов России, был руководителем курсовой, дипломной и диссертационной работ Сагитуллина. Главным научным достижением их многолетней совместной научной работы было открытие семейства новых перегруппировок азотистых гетероциклов (перегруппировка Коста–Сагитуллина). Рева Сафарович вспоминал всю жизнь необыкновенную химическую эрудицию и многогранное обаяние личности А.Н. Коста. Внезапная, преждевременная смерть А.Н. Коста в декабре 1979 г. была потрясением для Ревы Сафаровича. Об этом печальном событии он узнал в лифте химфака, из которого сразу вышел и несколько часов бесцельно бродил по Москве, пока не замерз.

В 1981 г. Р.С. Сагитуллин переехал в Омск, где заведовал кафедрой органической химии в течение 29 лет. Более 10 лет Р.С. Сагитуллин был единственным доктором химических наук в городе промышленной химии и поток посетителей на консультации к нему не прекращался. Организацию научной работы в Омском университете Рева Сафарович начал с формирования библиотеки иностранной литературы. Через несколько месяцев из Новосибирского филиала ГПНТБ в Омске были получены справочник Бельштейна, реферативный журнал Chem. Zentralblatt, журналы Berichte, JACS, Tetrahedron, Tetrahedron Letters, Coll. Czech. Chem. Commun. Одновременно были заказаны и приобретены спектрометр Tesla 60, освоен и

внедрен элементный анализ, куплены первые роторные испарители, химическая посуда. В 1993 г. была опубликована первая статья в международном журнале (G.P. Shkil, R.S. Sagitullin, Tetrahedron Lett., 34, 5967, 1993), выполненная в Омске. Эта публикация означала полное освоение научной целины по органической химии в Омске. Рева Сафарович бережно относился к созданной им кафедре и любил всех её сотрудников, каждого из которых он лично принимал на работу – подолгу, неспешно беседуя.



Рева Сафарович Сагитуллин был классическим профессором классического университета – высокопрофессиональным и широко образованным человеком. Он хорошо знал русскую и зарубежную литературу, любил поэзию, классическую музыку, обладал развитой, афористичной речью и изысканным юмором. У него была феноменальная память – помнил себя и всё, что с ним происходило, с 4 лет, прочитанное в 7 классе он помнил до конца дней. Автор научного открытия № 205 и лауреат премии им. А.М. Бутлерова был исключительно скромным человеком. Большинство его коллег на химфаке ОмГУ узнали о том, какой он выдающийся учёный, лишь после его смерти из телеграмм соболезнования, в которых об этом было написано.

*Г.П. Сагидуллина*

*Журнал «Химия гетероциклических соединений», 2011. № 4.*

*А. Г. Хәйретдин*

## ӘРВАХЛАР ӨЧЕН ДОГА КЫЙЛЫЙК...

*(«Коръәндә реинкарнация тәгълиматы»ның ахыры)*

### *Рух, җан, нәфес*

«Әрвахлар өчен дога кылыйк!», «бездән дога өмет итүче әрвахлар...», «әрвахлар шатлансын!» кебек гыйбарәләрне һәркайсыбызның ишеткәне бар. Сүзнең ни турында барганын аңлатасы да юк кебек, чөнки мәгълүм ки, Коръән ашларына, мәҗлесләргә җыелган милләттәшләребез бу дөньядан киткәннәрне шул рәвешле искә алалар, Аллаһтан аларның ахирәттәге халәтен җиңел кыйлуын үтенәләр.

«Әрвахлар» дигән сүздән *-лар* күплек кушымчасын аерып алсак, *әрвах* булып кала. Бу *әрвах* (ارواح) дигән сүз безнең телебезгә гарәп теленнән кергән һәм ул *рух* (روح) сүзенең күплек шәкелен белдерә. *Рух* сүзе дә телебездә бар, әмма ул сирәк кулланыла. Кулланылган очракларда да бу сүз туры мәгънәсендә кулланылмый. Ягъни *рух*ның кешене терек итә торган, кешегә Аллаһның үзеннән бирелгән һәм безне Аллаһ белән тоташтырып торучы бер нәрсә булуы турында ишеткәнебез юк диярлек.

Әмма, ни генә булса да, халкыбыз Аллаһтан бирелгән, кешене Аллаһ белән тоташтырып торучы бу *рух*ның иң әһәмиятле нәрсә булуын һәрвакыт аңлаган, шуңа күрә дога кылганда «бездән дога өмет итүче әрвахлар өчен дога кылыйк», дип әйтергә күнеккән. Халкыбыз «мәетләр өчен дога кылыйк», дип дога кылмый, чөнки һәркем күңеленең иң түрендә *рух*ның терек, ә мәетнең үлек булуын аңлый булса кирәк. Димәк, укылган догаларның мәеткә ярдәм итмәячәген, догага мохтаҗ булган бере булса да, ул мохтаҗның нәкъ менә терек *рух* булачагын халык бик яхшы аңлый.

Әмма, ни аяныч, соңгы вакытта чыккан дини китапларда «мәеткә файдасы булган гамәлләр», «мәет өчен хәер дога кылу» [Мәет озату йолалары: 2018. Б. 49] кебек гыйбарәләр күренгәли башлады. Алдарак шул ук чыганакның шул ук сәхифәсендә «Коръән укып, савабын мәетнең **рух**ына багышлау», дип язганнан соң алга таба нигә «мәеткә файдасы

булган гамәлләр», диясе урында «мәетнең **рух**ына файдасы булган гамәлләр», дип язмаска иде? Нигә «мәет өчен хәер дога кылу», диясе урында «мәетнең **рух**ы өчен хәер дога кылу», димәскә иде?

Инде дини китапларыбызда да *рух*ны читкә куеп, *рух*ны күрмәмешкә сабышып нәкъ менә мәетне терек итеп күрсәтү, мәеткә догалар багышларга кирәклеге турындагы уйны халык аңына сеңдерү дини тормышыбызның, дини күзаллауларыбызның дөрес булмавының бер билгесе булып тора. Гомумән алганда да, дин борынгы заманнарда ук бер бозылган икән, ягъни *рух*ның/*әрвах*ның әһәмияте читкә куелып, халыкның дини күзаллауларын бутау үткәндә бер башланган икән, динебезне ул бозык алга таба да черетәчәк, диннең таркалуын дәвам иттерәчәк, ахыр чиктә, бәндәне дә гаҗиз итеп белемсез калдырачак, аны җәһәннәм утында мөмкин кадәр озак җәзаланачак хәлдә тотачак.

Әмма өмет бар, чөнки халкыбыз «әрвахлар өчен дога кылыйк», дигәндә, бу *рух*/*әрвах* сүзен дөрес мәгънәдә куллана. Тик бу кадәре генә аз. Бу сүз, бу төшенчә дөньядан киткәннәрне искә алганда гына түгел, терекләр турында сүз йөрткәндә дә кулланылырга тиеш.

Бу мәкаләмдә алга таба ни өчен *җан* төшенчәсен *рух* төшенчәсеннән аера белүнең кирәклеге дә аңлатылыр. Дөрес юлга чыгу өчен, җәһәннәм газабыннан котылу өчен моңа күнегә башларга кирәк: кешенең нәкъ менә Аллаһтан бирелгән *рух* исәбенә тереклек итүен, *рух*ның бәндәне Раббысы белән тоташтырып торучы нәрсә икәнлеген аңлап-белеп торырга күнегергә кирәк, бу аңлауны аңыбызга, күңелебезгә сеңдерергә, дөньяга шул караш күзлегеннән карап әйләнә-тирәбездәге чынбарлыкны да шул ноктаи назардан кабул итәргә өйрәнергә кирәк.

Шулай итә башлар өчен Коръәнгә мөрәҗәгать итик.

Кешенең терек булуы нәкъ менә *рух* исәбенә, аның Аллаһ тарафыннан рухландырылган булуы исәбенә тәэмин ителүе турында Коръән кәримдә болай диелә: ***«Мин аны бар иткәч һәм аңа үземнең рухымнан (җаным) өргәч...»*** (15:29) [Исаев: 2018. Б. 205.]; ***«Аннан соң аны һәрьягы килгән хәлгә китерде һәм аңа үзенең рухыннан җан өрде»*** (32:9) [Шунда ук. Б. 343]; ***«Аны тәмам җиткереп эзләгәч һәм аңа үземнең рухымнан өргәч...»*** (38:72) [Шунда ук. Б. 383]. Димәк, рухтан кала кешене терек итүче башка нәрсә юк.

Биредә Габделбари әфәнде Исаевның тәрҗемәсен китерү урынлы булып чыкты, чөнки бу тәрҗемәләрдә мөтәрҗимнең рух белән *җан* төшенчәләре арасында икеләнеп калып ни кылырга белмичә аптырап калган булуы яхшы күренә: бер урында ул *рух* сүзен генә куллана (***рухымнан өргәч***), башка урында рух янына җәя эчендә (*җан*) дип өстәп куя (***рухымнан (җаным) өргәч***), тагын бер очракта җанны рухның бер өлеше итеп күрсәтә (***рухыннан җан өрде***).

Әмма Коръәндә һәр очракта да бары тик рух сүзе кулланылган: 15:29да һәм 38:72дә ***мин рӯхӣ*** (من روحى), ягъни рухымнан; 32:9да ***мин рӯхӣ-һи*** (من روحه), ягъни *рухыннан*. Коръәндә Аллаһның кешене терелтүе турындагы бу аятьләрдә җан сүзе кулланылмаган.

Габделбари әфәнденең бу икеләнүен аңлап була, чөнки чынлыкта үлгән кешенең кабергә салынганыннан соң кичерәчәк хәлләре турында, аның андагы халәте турында төгәл генә мәгълүмат хәтта дини китапларда да юк бит. Һәрхәлдә, бу язмамның соңгы өлешен язу вакыты килгәч, әйтәсе сүзләремне «әрвахлар өчен дога кылыйк», гыйбарәсе белән башлау кирәк, дигән илһам килгән иде. Бу гыйбарәдә чыннан да тирән белем, тирән фәлсәфә ята булып чыкты, чөнки ул гыйбарәне искә алып кына, аның мәгънәсен ачыклап кына алга таба атлап китеп, әйтеләсе фикерләремне бәйнә-бәйнә тезеп китеп булмады. Җепнең очыннан тартуым булды, китмәсенме йомгак тәгәрәп, эчендә ниләр яшеренеп ятканын фаш итеп! Нәтиҗәдә, дини китапларда, дини фикеребездә кешенең кабердәге халәте турында таралган карашларның төрлелеге, төгәлсезлеге, каршылыклылыгы, буталчыклыгы ап-ачык күренде. Бу буталчыкка юлыккач, үземне бер сазлыкка кереп бата башлагандай сизә башладым.

Димәк, миңа «әрвахлар өчен дога кылыйк», гыйбарәсе рәвешендә килгән ул илһам юкка гына килмәгән икән, чөнки кешеләрнең башларын бутый торган, фикерләрен чуалта торган, күңелләрен саташтыра торган уйдырмалар чытырманын ботарлап кырып-себереп читкә атмыйча алга таба атлап китү дөрес булмас иде. Бу йөздән, ошбу реинкарнация турындагы тәгълиматны ислам динен җыеп төзек хәлдә тотарга тиешле «Казык йолдыз» буларак күзаллавым да юкка гына булмаган. Кабердә кичереләсе халәтләр мәсьәләсенә дә, димәк, ачыклык кертергә, аны кичектергесез рәвештә хәл итәргә кирәк.

Инде мөһим төшенчәләргә, дөресрәк әйткәндә, ул төшенчәләрне белдерү өчен кулланылган сүзләргә тукталыйк. Югарыда китерелгән Коръән аятьләрендә *рух* сүзе искә алынды. Шунда ук тәрҗемәче тарафыннан кулланылган *җан* сүзе дә күренеп алды.

Иң элек ошбу ике сүз белән белдерелгән төшенчәләрнең үзара тәңгәл булмауларын ассызыклап үтәргә кирәк. *Рух* – Коръәндә кулланылган сүз, аны гарәп теленнән татар теленә дә үтеп кергән, дигән идек. *Җан* сүзе Коръәндә кулланылмый, чыгышы белән дә ул фарсы теленнән, шул телдән безнең телебезгә дә килеп кергән.

Югарыда китерелгән аятьләрнең тәрҗемәләрендә рух белән җан сүзләре бер үк төшенчәне белдерә торган сүзләр буларак кулланыла: ***«Мин аны бар иткәч һәм аңа үземнең рухымнан (җаным) өргәч...»*** (15:29); ***«Аннан соң аны һәрьягы килгән хәлгә китерде һәм аңа үзенең рухыннан җан өрде»***

(32:9), дип язган Г. Исаев. Минемчә, болай итү зур хата, чөнки башка урында *җан*–сүзе сиздермичә генә *рух*ны түгел, бөтенләй башка нәрсәне белдерә башлый. Мәгънә алмашуының никадәр хәтәр нәрсә икәнлеген күрсәтер өчен бер аятьне мисал итеп китерәм: «әл-Фәҗер» сүрәсенең 27-нче аятен Габделбари хәзрәт Исаев: ***«И тыныч җан»***, дип тәрҗемә кыйлган.

Бу аятьнең гарәпчәсе, ягъни Коръәндәгечәсе, ничек яңгырый? Аятьнең әйтелешенә карыйк: ***«йә әййү-һа-н-нәфсү-л-мутма'иннә»***. Моннан алдагы мисалларда (15:29; 32:9) рух сүзе тәрҗемәче тарафыннан *җан*ның бәрабәре буларак кулланылган иде. Болай булганда биредә китерелгән гарәп телендәге аятьнең хәрефләтә күчерелмәсендә дә *рух* сүзе күренергә тиеш, ***«и тыныч җан»***, диелгән ләбаса! Тик, юк, *рух* сүзе анда күренми, анда *нәфес* сүзе күренә: ***н-нәфсү-л***... Шулай итеп, Г. Исаев тәрҗемәсендә әле бая гына *рух* белән бер рәткә куелган *җан* бу очракта *нәфес* булды да калды!

Коръәндә китерелгән төшенчәләрне үзара тиңләштереп, аларны белдергән сүзләрнең мәгънәләре белән уйнау дәвам итәлә. Мәсәлән, «әл-Мөдәссир» сүрәсенең 38-нче аяте Г. Исаев тарафыннан болай тәрҗемә ителгән: ***«һәрбер кешегә–үзе эшләгән эшенең әҗере»*** (74:38). Аятьнең гарәп телендәге яңгырашы болай: ***«күллү нәфсин би-ма кәсәбәт раһина»***. Бу очракта баягы аятьтә *җан* дип тәрҗемә ителгән *нәфес* сүзе *кеше* мәгънәсендә бирелгән.

Кыска гына тикшеренүебезнең башыннан башлап сүз вә мәгънә үзгәрешләрен әлеге урынга кадәр күзәтеп килсәк, ни күрербез икән? Менәниләр күренәчәк:

1) *рух* = *җан*, ягъни *рух*, димәк, *җан*, димәктер;

2) *җан* = *нәфес*; ягъни *җан*, димәк, *нәфес*, димәктер;

3) *нәфес* = *кеше*, ягъни *нәфес*, димәк, *кеше*, димәктер.

Шулай итеп, тәрҗемәләргә ышансаң, ахыр чиктә *рух кеше*гә тиң булып чыга, *кеше*нең бәрабәре булып кала: *рух-җан-нәфес-кеше*. Әмма Коръәндә кешене белдерә торган махсус берничә сүз була торып (мәсәлән: *инсан*, *бәшәр*, *раҗүл*, *мәр'*ә кебек сүзләр), нигә кирәк иде *кеше* мәгънәсенә бик сирәк очракларда гына ия булган *нәфес* сүзен, һич тә тартынмыйча, кешене белдерә торган сүзләр рәтенә кертергә?

Коръәндәге бер төшенчәне белдергән сүзне башка төшенчәне белдергән икенче сүз белән тәрҗемә итүнең нинди яман хаталарга китерү югарыда бәян ителгәннәрдән аңлашылды булса кирәк. Шулай да мин мәрхүм Габделбари Исаев хәзрәтләрен ялгышкан, дип, фәлән сүзне дөрес тәрҗемә итмәгән, дип гаепләмим. Аның гаебе юк, чөнки ул кеше буларак үз дәверенең җимеше булган сыман, дин галиме буларак та дини гыйлемнәр дип аталган борынгы корылманың нәтиҗәсе булып тора. Дини гыйлемнәрдә, дин галимнәре арасында Коръән сүзләренең мәгънәләре

белән уйнау, бер сүзне икенче бер сүз урынына куллану, төрле мәгънәләргә ия булган берничә сүзне бер мәгънәгә генә ия итеп күрсәтү, кайбер аятьләрнең кайбер гыйбарәләрен тәфсир-тәрҗемә итмичә читләтеп узу – болар күптән күнегелгән хәл, тагын да дөресрәге – Коръәнне аңлату гыйлеменә күптән «йоккан», ә тагын да дөресрәк әйткәндә – йоктырылган бер чирдер. Борынгылардан калган калып кысаларында җитешеп дин галиме булдың икән, димәк, син дә бу бозык уенның маһир остасысың. Бу бозыклык дини китапларда кабер хәлләре мәсьәләсендәге буталчыкта чагыла һәм ул буталчык алга таба әле кат-кат күрсәтеләчәк.

Искәртеп узам – биредә без Коръәндәге төшенчәләр, дөресрәк әйткәндә, ул төшенчәләрне белдерү өчен кулланылган сүзләр һәм алар арасындагы мәгънәви аермалар турында фикер йөртәбез. Дәвам итик.

Әлегә кадәр без өч төрле төшенчәне белдергән өч сүз белән эш иттек: *рух*, *җан*, *нәфес*. Боларның икесе генә, ягъни *рух* белән *нәфес* кенә Коръән сүзләре. *Җан* – фарсы сүзе, дидек. Шулай да, бу төшенчәләрнең татарчасы ничек булыр икән? Чөнки Коръәнне татар теленә тәрҗемә иткәндә, *рух*ны белдерер өчен дә, *нәфес*не белдерер өчен дә һаман шул бердәнбер *җан* сүзен генә куллану дөрес түгел. Аны бөтенләй читкә куеп торыйк.

Коръәндә *рух* булып килгән сүзнең татарчасы ничек булыр икән?

Бу сорауга җавап эзләп Казанда 1920-нче елда С.Рахманкулов белән Ә.Кәрам тарафыннан төзелеп чыгарылган «Русча-татарча мөкәммәл лөгать» исемле сүзлеккә мөрәҗәгать иттем. Анда ике сүз бар 1) *дух*, һәм 2) *душа*.

*Дух* дигәне татарчага *җан*, *рух*, *нәфес* // *тын*, *сулыш*, *ис* дип тәрҗемә ителгән.

*Душа* татарчага *җан*, *рух*; *нәфес*, *күңел* дип кайтарылган.

*Душа* белән *дух* икесе ике нәрсәне белдерсәләр дә, татарча икесе дә *җан*, *рух*; *нәфес* кебек нәрсәләргә тәңгәлләр, имеш. Димәк, *душа* ни, *дух* ни – аерма юк булып чыга.

Юк, болай булмый. Болай ярамый.

Миңа калса, *рух*ның (дух) татарчасы *кот* була: котны алу, кот очу, кот калмау. *Нәфес*нең (душа, эго) татарчасы бик борынгы булган *ис* сүзе була алыр иде. Бу *ис* дигән сүз сәер булып күренсә дә ул кайбер гыйбарәләрдә сакланып калган: ис китү; истә булу; ис алу/ис аву (һуштан яздыру); ис керү, ис китәрү.

*Душа*, *эго* төшенчәләрен белдерү өчен *ис* урынына тагын бер сүзне кулланып була кебек: ул да булса *аң* сүзе. Болай итүнең мөмкинлеген мин Алтайда сәяхәт иткән чагымда җирле төрки телле кавемдәшләребез белән аралашканда күрдем. Безнең татар телебездә кешедән гайре башка тереклек, гомумиләштереп әйткәндә, *хайван*, *җан иясе* кебек сүзләр

белән белдерелә. Әмма *хайван* да, *җан* да – болар асылда безнең телебезгә читтән кергән сүзләр. Үзебезнең борынгы татар телебездә *хайван*, *җан иясе* мәгънәсендә нинди сүз кулланылган булган икән? Ул сүзне Алтайда яшәүче кавемдәшләребезнең телендә таптым. Алар хайваннарны *аңдар*, ягъни *аңнар* дип атыйлар. Ягъни аңлы булу тереклекнең, ягъни хайваннарның иң мөһим билгесе буларак үзәккә куелган. Алай дисәң, *аң* кешегә дә хас булган нәрсә ич. Уйлана торсаң, бу борынгы телебездән калган сүз турында күп язып булыр иде, әмма анысы мин башлаган мәсьәләдән читтәрәк тора, бу йөздән дәвам итеп тормыйм.

Бу язмамда Коръән теленә якынлыкны саклап калу өчен мин алга таба *рух* һәм *нәфес* сүзләрен кулланачакмын.

***Кабер, бәрзәх***

Әрвахларга атап кыйлынган догалар, арабызда таралган күзаллауларга күрә, җир астында, ягъни кабердә терелтелгән һәм шунда ук яткан көйгә үзенең кубарылып мәхшәр мәйданына чыгарылачагын көтәргә мәҗбүр ителгән кешеләрнең хәлен җиңеләйтергә тиеш. Ягъни кабердә кеше терек була, имеш. Һәрхәлдә, дини китапларда язылганнарга күрә, шулай килеп чыга. Андый китапларда *«үлем – ул җанның тәннән аерылуы»* [Ислам дине нигезләре: 2018. Б. 67] турында хәбәр ителә, аннары эшләрнең болай булуы бәян ителә: *«Җанның ахирәттәге тормышы кабердән башлана. Бу дөньядагы тормыш рәвешенә, гакыйдәсенә, гамәл кылуына бәйле рәвештә кешенең кабере дә билгеле бер сыйфатларга ия була»* [Шунда ук. Б. 67], диелә.

Дини китапларга күрә, ул «ахирәттәге тормыш» нидән гыйбарәт икән?

Кабергә салынган мәеткә аның җаны, имеш, яңадан иңә дә, шул сәбәпле терелгән үлгән кеше кабер газапларын кичерә башлый, дип аңлатыла дини китапларда. Мәсәлән, миладе ел исәбе белән 1445–1505 елларда яшәгән мәшһүр һәм бик абруйлы дин галиме Җәлалетдни әс-Сүйутый болай дип язган: *«Чынлыкта, мәет юылганда, җан фәрештәдә була һәм чынлыкта фәрештә мәет белән бергә кабергә иңә, ә мәет күмелгәч, фәрештә мәеткә аның җанын кертә дә, сорау алу башлана»* [https://darulfikr.ru/articles/zhizn-posle-smerti/].

Гомумән алганда, кабердәге хәлләр турында дини китапларда төгәл генә, анык кына хөкем юк икән. Мәсәлән, Әкмалетдин әл-Бабиртый (милади 1384 вафат) исемле мәшһүр галим болай дип яза: *«В мертвые тела будет возвращена жизнь, но мы не можем уверенно говорить, будет ли им возвращена душа... Поэтому неправильно углубляться в вопрос о способе могильных мук»* [Комментарий имама Акмалюддина аль-Бабирти: 2019. С. 109].

Бу китапның гарәпчәсе миндә булмаганга күрә, китерелгән өземтәдә телгә алынган «душа» сүзенең асыл чыганакта нинди сүз белән бирелгәнен мин әйтә алмыйм. Мөгаен, *нәфес* диелгән булгандыр. Әмма нә-

фес кешене терек итми, кешене *рух* терек итә. Ә *рух* дигән төшенчәнең дини китапларда кабер хәлләре мәсьәләсендә кулланылмавын мин инде күрсәткән идем. Бу йөздән, әл-Бабиртый хәзрәтләренең дә *рух* сүзен түгел, *нәфес* сүзен кулланган булуын чамалый алам. Әл-Бабиртый кабердә мәеткә *рух* кире иңә, дип язмас иде, гәрчә шулай язарга тиеш булуын аңласа да. Шуңа күрә ул кабер газаплары турында тирәнрәк фикер йөртүне ярамаган эш дип тапкан.

Болай итү бик аңлашыла торган адым, чөнки реинкарнация төшенчәсен кабул итмичә кабер газаплары мәсьәләсен аңлап булмый. Нәтиҗәдә, бу мәсьәлә бик буталчык һәм аңлашылмый торган бер нәрсә булып тора. Чынлыкта, бик сәер бер хәл күзәтәбез: Коръән белән коралланган дин галимнәре үлемнең барлыгын таныйлар, ә кеше үлгәннән соң була торган хәлләр турында артыгын уйламаска кушалар. Әйтерсең, Коръәндә әйтелгәннәре моны аңларга мөмкинлек бирми... Коръән белгечләре, имеш, ә үзләре иң мөһим дини мәсьәләләрнең берсе булган кабердәге хәлләр турында, бер яктан, Коръәнгә таянып җавап бирә алмыйлар, ә икенче яктан, мәсьәләнең әһәмиятен аңлап, мәсьәләне ачыкларга бик тырышалар.

Нәтиҗәдә галимнәр буталчыкны арттыралар гына. Мәсәлән, дини китапларның берсендә: *«Кеше үлгәннән соң җанның Кыямәт көненә кадәр булачак урыны «Әл-Бәрзәх» дип атала. Һәрбер үлүченең бу дөньядагы тереклеге тәмамлана һәм, шул ук вакытта ул яңа тормыш һәм тереклек өчен туа. Кеше үлгәннән соң, шулай итеп, Бәрзәхкә элгә»* [Ислам дине нигезләре: 2018. Б. 67–68], – диелә.

Бу өземтәдә бирелгән фикернең никадәр аңлаешсыз икәнлегенә игътибар итегез. Мәсәлән, мин авторның ни әйтергә теләгәнен аңлый алмыйм: үзе *«җанның булачак урыны – Бәрзәх»*, ди, аннары *«кеше... Бәрзәхкә элгә»*, ди. Моны ничек аңларга? Бәрзәхтә җан буламы? Кеше буламы? Җанлы кеше буламы? Җансыз мәет буламы? Бу өземтәдән тик бер генә нәрсә тәмам аңлашыла – кабердәге тормыш белән *Бәрзәхтә* булу бер үк нәрсә буларак аңлатыла.

Китапларда кабердәге тормышның үзенчәлекләре никадәр тәфсилләп аңлатылган булса да, ул аңлатулар Коръәндә телгә дә алынмаган «кабердәге тормыш» дигән төшенчәгә корылган. Реинкарнация тәгълиматын танымаганга күрә галимнәр «кабердәге тормыш» төшенчәсен уйлап чыгарырга мәҗбүр булганнар. Нәкъ үзләреннән алда «чистилище» дигән төшенчәне уйлап чыгаручылар кебек. Уйлап чыгарганнар да, аны Коръәндә *бәрзәх* дип аталган башка бер төшенчә белән тиңләштергәннәр.

Бу тиңләштерүләре мине шикләндерде: нинди мәсьәләгә җавап таба алмыйча болай иттеләр икән, дип сорау бирдем үземә. Дөресен генә әйткәндә, билгеле бер вакыттан башлап мин ул дини китапларда язылганнарны

һич кабул итә алмыйм, чөнки аек акыллы кеше өчен аларда язылганнарның буш бер сафсатадан гайре бернәрсә түгеллеген инде күптән аңладым. Шуңа күрә яңадан Коръәнгә мөрәҗәгать итик: нәрсә соң ул *бәрзәх*?

Гарәп телендә *бәрзәх* дигән сүз суда утырган ике утрауны үзара кушкан һәм азмы-күпме озынлыкка ия булган сукмак сыман тар гына коры җирне белдерә. *Бәрзәх* сүзенең ясалышына тел белгече күзлегеннән карасаң, бу сүзнең гарәп теленә башка бер телдән алынма буларак үтеп кергән булуын күрү кыен түгел. Минемчә, ул сүз гарәп теленә йә санскрит, йә тибет теленнән килеп кергән (хәер, нәкъ капма-каршысы да булырга мөмкин).

Һәрхәлдә, тибет телендә яңгырашы белән *бәрзәх*кә охшаш булган *бардо* төшенчәсе бар. *Бәрзәх* белән *бардо* сүзләре арасындагы әйтелеш-язылыш аермасы да төрле телләрдә язылыш-әйтелеш үзенчәлекләре аркасында гына шулай үзгә булып күренергә мөмкин. Чынлыкта исә, гарәпчә булсын, тибетча булсын – бу сүзләрнең икесе дә бертөрле яңгырарга мөмкин. Мисал итеп, табигать кочагында яши торган бер мәхлукны белдергән *сасквоч* сүзен китерәсем килә: инглизчә ул – *sasquatch*, инглиз теленә ул француз теленнән күчкән, димәк, аңарчы француз колагына ничек ишетелсә, шулай язылган булган, ә французлар ул сүзне Төньяк Америкада яшәгән җирле кызыл тиреләләрдән ишеткән булганнар. Бу *сасквоч* сүзе безнең өчен никадәр сәер һәм аңлаешсыз булып яңгыраса да, әгәр без бер кызыл тиреленең үз авызыннан ул сүзнең асыл яңгырашын ишетсәк иде, шул мәлдә үк бу сәер сүзнең ниндидер *сасы кеше* турында хәбәр бирүен аңлап алыр идек. Чыннан да, күптөрле атамалары арасында *sasquatch* дигән атамасы да булган серле *кар кешесеннән* бик сасы ис аңкып тора, имеш. Болай булганда, бер Тибет кешесе дә Коръән укылганда бу *бәрзәх* сүзен ишетеп алса, аны танып алып аңлавы аркасында охшаш кичерешләр, гаҗәпләнү кичерергә бик мөмкин.

Тибет телендә *бардо* төшенчәсе шәхеснең үлеме белән аның яңадан дөньяга килүе арасындагы халәтне белдерә. Гарәп телендәге мәгънәсен югарыда искә алган идек инде. Ә Коръәндәге *бәрзәх* төшенчәсенең мәгънәсе ни? Шуны барып күрик.

Коръәндә *бәрзәх* дигән нәрсә өч мәртәбә телгә алына:

1) 23:100 ***«...һәм*** [шул ук вакытта] ***терелтеләсе көннәренә кадәр аларның артында бәрзәхтер»****;

2) 25:53 ***«Улдыр иркенгә ике диңгез чыгарган: монысы татлы, төче, ә монысы тозлы, ачы һәм икесе арасында бәрзәх*** ** ***урнаштырган»***;

* Г. Исаев тәрҗемәсендә: ***«Аларның артында кыямәт көнгә кадәр пәрдә булган нәрсә бар»***, – диелә. Биредә Г. Исаев *бәрзәх* сүзен *пәрдә* дип биргән, әмма 7:46 аятендә кулланылган *хиҗаб* сүзен дә ул *пәрдә* дип тәрҗемә иткән, ягъни *бәрзәх* белән *хиҗаб* арасында аерма барлыгына, нидәндер, игътибар итмәгән.

** Г. Исаев тәрҗемәсендә – *пәрдә*.

3) 55:20 ***«иркенгә ике диңгез чыгарды, икесе дә бер-берсе белән очрашалар, араларында икесе дә кичә алмаячак бәрзәхтер»****.

Күрүебезчә, өч аятьнең икесендә *бәрзәх* сүзе ике төрле суны бер-берсеннән аерып торган нәрсәне белдерә. Шуңа күрә бу ике аятьтә кулланылган *бәрзәх*не кабердәге тормыш, ахирәт хәлләренә карата кулланып булмый. Әмма бу ике аятьтән *бәрзәх*нең күзгә күренми торган бер нәрсә булуын аңлап була. Ул гына да түгел, *бәрзәх* ул сыйфатлары үзгә булган ике матдәне бер-берсеннән аерып торучы нәрсә булып чыга: 1) 25:53 аятьтә *бәрзәх* тозлы һәм төче суларга үзара кушылырга юл куймый торган нәрсә; 2) 55:20 аятьтә, мөселман дин галимнәренең Жак Ив Кусто (1910–1997) тарафыннан ясалган ачышка таянып аңлатуына күрә, *бәрзәх* – Ак диңгез белән Атлас мохитенең** сулары очрашкан Җәбәл Тарик бугазында*** диңгез белән мохит суларына үзара кушылырга юл куймый торган нәрсә.

*Бәрзәх*нең Коръән аятьләреннән аңлашылган үзенчәлекләре моның белән генә чикләнми, минемчә. Шулай да, йомгаклап әйткәндә: 1) *бәрзәх* пәрдә кебек, хиҗаб кебек матди төшенчә түгел булып чыга; 2) *бәрзәх* күзгә күренми торган бернәрсә булып чыга, 3) *бәрзәх* төрле сыйфатлы суларга (матдәләргә, хәлләргә) үзара кушылып буталырга мөмкинлек бирми торган бер нәрсә булып чыга.

Болай булганда, югарыда искә алынган өч аятьнең берсе генә үлем, кабер, ахирәт хәлләренә карый, шуңа күрә кабердәге хәлләрне тасвирлаганда шул аять кенә шәргый дәлил буларак кулланыла ала.

Дәвам итәр өчен баягы аять белән аннан алдагы бер аятьнең тәрҗемәсен тулысынча китерик:

***«Аларның берсенә үлем килгәндә, ул әйтә: «Раббым! Мине кире кайтарыгыз! // Бәлки мин калдырып киткәннәремдә игелек кыйлырмын!» – ди. Тик юк! Болар аның әйткән сүзе генә, һәм*** [шул ук вакытта] ***терелтеләсе көннәренә кадәр аларның артында бәрзәхтер»*** (23:99–100).

Бу аятьләргә нисбәтән дини китаплардагы *«кеше үлгәннән соң... Бәрзәхкә эләгә»* [Ислам дине нигезләре: 2018. Б. 67–68], дигән хөкемнең, миңа калса, берникадәр арттырылганлыгы күренеп тора. Аятьтә *бәрзәх*нең үлем кичергән кешенең артында торуы турында әйтелә; *бәрзәх* күзгә күренми торган матди булмаган бер нәрсә булганга күрә, *бәрзәх*кә «эләгеп» тә булмый, *бәрзәх*тә (ягъни аның эчендә) яшәп тә булмый.

Моннан тыш, ислам диненә әүвәлге диннәрдән дә байтак кына хорафатларның һәм күзаллауларның үтеп кергән булуын да истә тотарга кирәк. Бу йөздән, динебездәге бу *бәрзәх* төшенчәсе шундый диннәрнең

---

* Г. Исаев тәрҗемәсендә – *киртә*.

** Атлас мохите – Атлантик океан.

*** Җәбәл Тарик бугазы – Гибралтар бугазы.

берсендә булган «чистилище» дигән төшенчәгә туры килә булса кирәк. Ул диндә дә рухларның бер тәннән икенче тәнгә күчеп йөреп, тәкъдир баскычлары буйлап югарыга, Аллаһка кире кайтарылулары турындагы тәгълиматның* тамыры корытылгач, дин галимнәре изге китапларында телгә дә алынмаган «чистилище» дигән бер урын булуын уйлап чыгарырга мәҗбүр булганнар.

***«Аларның берсенә үлем килгәндә»*** дигән Коръәни гыйбарәдә кемнәр күздә тотыла?

Моны белер өчен, аннан алдагы 82–98-нче аятьләрне укырга кирәк. Кыскача әйткәндә, ул аятьләрдә сүз Аллаһны танып та, Аңа тиңдәшләр тиңләп ширек кыйлучылар турында һәм үлгәннән соң каберләрендә туфракка әверелгәч үзләренең янәдән терелтелүләренә ышанмаучылар турында бара. Шундыйларның берсенә үлем килгәч ул: ***«Раббым! Мине кире кайтарыгыз! Бәлки, мин калдырып киткәннәремдә игелек кыйлырмын»,*** – дип ялвара.

Дини китапларда аңлатылганча, үлем белән тартышкан кеше үзенең кире кайтарылуын үтенә, янәсе, ул исән калдырылса әгәр, дөньяда гел игелек кылачак, имеш. Дини китапларда якынча шулай аңлатыла. Моннан тыш, әлеге аятьләрнең мәгънәсен гадәттәгечә аңлатуның тагын бер җитешсезлеге бар. Ул җитешсезлекне күрер өчен «үлем сулышын тойган бәндә ни өчен ***«Раббым!»*** дип дәшә?», дигән сорау куйыйк. Коръән аятьләренә күрә, әҗәле җиткән кеше янында үлем фәрештәсе була, аның рухын тәннән кубаручы да шул үлем фәрештәсе була: ***«Вәкилегез ителгән үлем фәрештәсе сезгә тиешлесен кыйла да, аннан соң Раббыгызга кире кайтарыласыз»*** (32:11). «Сезгә тиешлесен кыйла», – дигән фигыльне тәфсир осталары һәм тәрҗемәчеләр, гадәттә, «үлдерә» дип, «җанын ала» дип аңлаталар һәм тәрҗемә итәләр һәм, һич тә икеләнеп тормыйча, сүзнең кешенең үлүе турында барган булуына инандыралар. Әмма болай булганда, үлем кочагына эләккән кеше ул фәрештәгә ***«Раббым!»***, дип дәшмәс иде, ***«мине кире кайтарыгыз!»*** дип ялвармас иде.

Инде бу аятьләргә дини китапларны язган галимнәр күзлегеннән түгел, *рух* күзлегеннән карыйк. Бу очракта үлем кешегә түгел, *рух*ка килә. *Рух* өчен үлемнең ни икәнлеген алдагы мәкаләләрдә аңлаткан идем: рухның үлеме аның кеше тәненә иңдерелүедер, дип язган идем. Кеше үлгәч, аның терек булуын тәэмин итеп торган *рухы* Раббысы хозурына җавапка тартыла, хөкем ителә һәм әгәр ул *рух* җәннәткә кертелү өчен лаек дип табылмаса, ул *рух* яңадан түбән тормышка, ягъни дөньяга җибәрелү белән хөкем ителә. Шулчакта ул рух дөнья дип аталган җәһәннәмгә, кеше тә-

* ***«Тулган ай белән ант итәмен ки, сез бер каттан (халәттән) икенче катка (халәткә) күчәсез»*** (84:19).

неннән булган кабергә кабат эләкмәс өчен ***«Раббым! Мине кире кайтарыгыз!»*** дип ялвара түгелме икән?

***«Мине кире кайтарыгыз!»*** дигәндә, рухның дөньяга кире кайтарылырга теләве түгел, нәкъ менә Аллаһ хозурына кире кайтарылу турындагы ялваруы чагыла, миңа калса. Бу фаразның дөрес булуын «кире кайтарырга» дигән фигыль дә раслый кебек, чөнки Коръәндә Аллаһ хозурына кире кайтарылу мәгънәсендә нәкъ менә шушы фигыль бихисап мәртәбә кулланыла. Мәсәлән: ***«Аның янына кире кайтарыласыз»*** (*сумма иләй-hи* ***туржәгун***, 11:34); ***«мәетләрне исә Аллаһ терелтә дә аннары алар Аңа кире кайтарылалар»*** (*сумма иләй-hи* ***йуржәгун***, 6:36); ***«аннан соң Раббыгызга кире кайтарыласыз»*** (*сумма илә рабби-күм* ***туржәгун***, 32:11) һәм боларга охшаш булган башка бик күп аятьләр.

Татар телендә *кире кайту* мәгънәсендәге фигыльләр иң кадерле урынга: туган йортка, кендек каны тамган җиргә, туган якка әйләнеп кайтуны, кире кайтуны белдерә. Мәсәлән, татар телендә «өемә кайттым», «туган ягыма кире кайттым», диелсә, хата булмый, әмма «эшемә кайттым», диелсә, бик тупас мәгънәви хата булачак.

Аллаһ тарафыннан адәм баласына өрелеп кертелгән рухның да «туган йорты» бар. Аның «туган йорты» – ул Аллаһ Үзедер. Болай булганда Коръәндә ни өчен нәкъ менә «Аллаһка (Аллаһ хозурына) кире кайтарыласыз», дигән гыйбарәнең кат-кат кулланылуы аңлашыла түгелме? ***«Мәетләрне исә Аллаһ терелтә дә аннары алар Аңа кире кайтарылалар»,*** аятендәге мәетләр, дигәндә, биредәге кабердә ятучылар түгел, ә нәкъ менә кешедә, ягъни туфрактан тукылган кабердә интеккән рухлар күздә тотыла. Нигә ул рухлар мәет дип аталганнармы? Чөнки Аллаһ белән бәйләнештә булуларын исләренә төшерәчәкләренә кадәр алар дөнья дип аталган, ягъни *түбән яшәеш* дип аталган җәһәннәмдә интегәләр.

Минем фикеремчә, *бәрзәх* ул – рухка кеше тәнендә элек кичергән яшәешләрен, кичергәннәрен исендә тотарга мөмкинлек бирми торган бер нәрсә, бер серле чара. Аллаһ хозурында җавап биргәндә *рух* үткән яшәешен исендә тота, чөнки җавабын да шул тормышында кыйлганнары һәм кыйлмаганнары өчен бирә. Ә инде кабаттан кеше тәненә иңдерелү белән хөкем ителгәннән соң, ул үткән тормышында булганнарын онытырга мәҗбүр ителә һәм аның үзе белән аның хатирәләре арасында *бәрзәх* пәйда була.

Дини китапларда бер боткага әйләндерелгән кабердәге хәлләр мәсьәләсенә тагын бер игътибар иттерәсем килә. Ул китапларда кабердәге тормыш ничек кенә тасвирланса да, кабердәге үләксәнең тере килеш ятуы турындагы нәтиҗәгә киленә: *«Үлгән кеше кабергә күмелеп аны озатучылар таралгач, шул мәет янына Мөнкир һәм Нәкир исемле ике*

*фәрештә килә... Алар мәетне утыртып куялар һәм шундый сораулар бирәләр...»* [Ислам дине нигезләре: 2018. Б. 70].

Кабердә сораласы бу сорулар турында, сорау алучы фәрештәләр турында ислам динен азмы-күпме өйрәнгән һәркем белә. Тик нигә китерелгән өземтәдә *«мәет янына»*, диелгән? Үле гәүдәгә сораулар бирү сәер булып тоела, лабаса! Болай итүнең сәбәбе астөшермәдә чыганак буларак күрсәтелгән бу **«Ислам дине нигезләре»** исемле китапны төзүчеләрнең, нидәндер, бер бик мөһим нәрсәне искә алмауларына кайтып кала, мөгаен. Ул да булса, китапны төзүчеләр җанның мәеткә яңадан иңүе турында бер сүз дә әйтмәгәнәр. Ә бит «ислами дини карашлар» дип аталган тәгълиматына күрә, үлем фәрештәсе үлгән кешенең җанын ала да (җанны, рухны түгел!), аннары ул җан күккә аша башлый; әгәр ул җан кәфер кемсәнең җаны булган булса, ул беренче күкне дә үтә алмый һәм шундук кире җиргә, кабергә, мәеткә төшерелә. Хәерле иманлы бәндәнең җаны исә җиденче күккә кадәр күтәрелә, имеш. Әмма ахырда мондый җан да кире кабергә төшерелә, үле гәүдәгә иңә. Нәтиҗәдә, мәет терелә. Сораучы фәрештәләр әнә шуннан соң гына килә, имеш.

Шулай итеп, дини китапларда тасвирланганча, кабердә булган хәлләр төрлечә бәян ителә: бер бәянда сораулар мәеткә бирелә, икенче бер бәянда сораулар җаны кире иңеп терелгән кешегә бирелә, өченчеләрендә сораулар җанга яки нәфескә бирелә. Кайбер китапларда сорауларның кешегә бирелүе турында язылган, әмма тереме ул, югыйсә, мәетме–анысы ачыкланылмаган, «бу турыда тирән уйлануларга бирелмәгез», имеш. Уйланырга ярамагач, үзләре дә язмасыннар иде бу турыда. Тик, юк шул, язалар бит.

Аларның язганнарын укый-укый тәмам буталып беттем. Ә, бәлки, мәеткә җан иңеп тә тормыйдыр? Бәлки, мин ялгышамдыр? Бәлки, фәрештәләр, чыннан да, сорауларын үле мәеткә бирәләрдер,–дип шикләнә төштем. Үземне тикшерер өчен тагын бер дини китапка мөрәҗәгать иттем. Анда болай диелә: *«Мәетне кабергә салганнарыннан соң, аның тереклеге һәм зиһенгә алу кабилияте аңа кире кайта. Шулчакта ул җәзаны да, бүләкне дә татый башлый»* [Са’ди, Абд-ал-Малик: 2008. С. 117]*.

Димәк, үле гәүдәгә җан иңми, тереклеге һәм зиһенгә алу кабилияте генә иңә, шулаймы? Ә кабергә салынган мәет нәрсә исәбенә терелә, ягъни аның *тереклеге һәм зиһенгә ала алуы* нәрсә исәбенә була,–дигән сорау бирсәм, ни булыр икән?

Аптырагач, кулларыма башка бер китап алдым. Анда болай диелә: *«кеше үлгәч, аның җаны тәненнән аерылып чыга. Җаннарны Газраил*

---

* Өземтәнең урысчасы болай: *«...когда покойного человека помещают в могилу, к нему возвращается его жизнь и способность воспринимать. Тогда-то он и начинает вкушать наказание и награду».*

*фәрештә алып китә... Кабердәге мәет янына сорау алучы фәрештәләр ... килә»* [Ислам турында сөйләшик: 2016. Б. 159]. Димәк, җан әллә кайларда, Газраил фәрештә карамагында, аның кайда икәнен Аллаһ кына белә, әмма моңа карамастан, яңа гына кабергә салынган мәеттән сорау алу барыбер башлана. Үле мәеттәнмени сорау алына?

Ягъни, дини китапларда бу мәсьәләгә карата карашларның төрле, буталчык, аңлаешсыз булуын җитәрлек кадәр күрдек. Ул китапларда каршылык өстенә каршылык өелгән. Моның шулай булуын күргәч, үзем дә аптырап калдым. Әлегә чаклы үлем, үлемнән соң яшәү, кабердәге хәлләр кебек нәрсәләр турында дини китапларда инде күптән язылган, тәфсилләп аңлатылгандыр, дип уйлый идем.

Нигә соң дини китапларда бу мәсьәләгә карата анык кына хәбәр, билге юк? Чөнки бу хакта, ягъни кешедән кубарылган рухның кичергәннәре турында Коръәндә берни дә әйтелмәгән. Дөресрәге, әйтелгән, әмма бик аз әйтелгән: ***«Синнән рух турында сорыйлар. Әйт: «Рух – Раббымның эшеннәндер, сезгә исә бу турыда белемнән азы гына бирелгән», – диген»*** (17:85).

Минем аңлавымча, кабердә череп таркалучы мәеттән кала берни дә юк. Бу турыда инде язган идем. Кеше тере чакта аның мин-минлеген, ягъни шәхсиятен тәэмин итеп торган нәфес, әҗәл сәгате җиткәч, үлә. Бу турыда: ***«Һәр нәфес үлемне татучыдыр»*** (21:35), – диелгән. Кешене тере һәм аңлы бер мәхлук итүче һәм аны Раббысы белән тоташтырып торган *рух* исә Аллаһ хозурына җавап бирергә китә. Әгәр *рух* кеше гәүдәсендә булган чагында уянмаган булса, уянмавы сәбәпле Раббысына биргән вәгъдәне үтәмәгән булса, ягъни Бөек Аллаһның барлыгын исенә төшереп Раббысы белән тоташкан булуын аңламаса, андый *рух* сират күпере аша үтмәгән булып танылa да, аңа яралгы хәлендә булган яңа кеше тәне билгеләнә, яңадан җирдә яшәү язылa. Шул рәвешле, сынауны үтә алмаган андый рухка *тәкъдир* тагыла. Тәкъдир – ул җирдәге сынауларны уза-уза үзен тагын да көчлерәк хәлгә килү, Раббысын исенә төшерерлек кадәр, үзенең кайдан килүен, кем белән бәйләнештә торуын искә төшерерлек кадәр егәр-кодрәт туплау. Шулай итеп, андый *рух* яңадан туфрактан тукылган кабергә – кеше гәүдәсенә иңдерелә, ана карыны аша яңадан кабер газаплары кичерер өчен түбән яшәеш мәйданына – бу дөньяга китерелә.

Биредә игътибар ителәсе тагын бер нәрсә турында әйтеп узасым килә. Рух, кеше гәүдәсенә иңдерелеп, дөньяга килә, дидем. Ул рухның элеккеге тормышыннан калган хатирәләре, тәҗрибәләре *бәрзәх* артында кала, ягъни рух барысын да оныта. Икенче яктан, рухка яңа нәфес бирелә, ягъни яңа шәхсият. Минем аңлавымча, шәхсият, шәхес булу ул кешенең үзенең бар булуын белүе генә түгел, аның холкы да, табигате дә, сәләтләре дә, һәвәслекләре дә. Ягъни, Аллаһ тәгалә һәр рухка аның моңарчы ирешкән

үсешенә карап, аның куәтенә карап төрле үзенчәлекле сыйфатларга ия булган яңа бер шәхсият бирә, акыл бирә.

Шуңа күрә җирдә яшәгән кешеләр арасында холык, кыяфәт, акыл ягыннан берсенә-берсе тәмам тәңгәл булган ике кемсә юк. Без барыбыз да үзгәләр. Сигез миллиардмы без? Димәк, җирдә сигез миллиард төрле холыкка, буй-сынга, кыяфәткә, акыл вә табигатькә ия булган кеше яши. Һәм иң дә әһәмиятлесе: һичкем теге яки бу холыкны, теге яки бу сәләтне, теге яки бу табигатьне ана карынынннан туганчы сайлап алмаган. Боларны рухның үткән тормыш тәҗрибәсенә күрә, казанышларына күрә, кыйлганнарына күрә аңа Аллаһ тәгалә үзе бирә. Бу үзенчәлекләр рухның алга таба да үсешен һәм кайчан да булса уянып, аңына килеп, нәфесне җиңеп, идарәне үз кулына алуына хезмәт итәләр. Ягъни кешенең холкы, аның сәләтләре, мәелләре – болар барысы да, асылда, рухка Аллаһ тарафыннан бирелгән кораллар һәм аны теге яки бу сынауга дучар ителүенең сәбәпләре.

Башкача булса, ягъни рухка акылны, холыкны, гомумән: шәхсиятне сайлау мөмкинлеге бирелгән булса, һәр рух иң яхшы сыйфатларны гына сайлап алыр иде, иң яхшы холык иясе булыр иде дә, алдында куелган вазифаны үтәр иде, вәгъдәсен дә җиренә җиткереп үтәр иде. Нәтиҗәдә, һәрнәрсә тәмам булыр иде: үсеш туктар иде, гыйбадәт туктар иде. Нәкъ менә бу йөздән, ягъни болай булмасын өчен Аллаһ тәгалә һәммәбезне дә кисәк кенә иман иясе итми, гәрчә барыбызны да иман ияләре итү өчен Аның бер генә сүзе дә җитәр иде. Нәкъ бу йөздән кодси хәдисләрнең берсендә: *«Әгәр сез гөнаһ кыйлудан туктасагыз, Мин сезне юкка чыгарып, җир йөзенә гөнаһ кыйлачак һәм шул сәбәпле тәүбә-истигфар сораячак башка кавемнәр китерәчәкмен»*, – диелә. Шуңа күрә Аллаһ Коръәндә кешеләрнең йөрәкләрен томалап куйган булуын белдерә: ***«Аны*** (Коръәнне) ***аңлый алмасыннар өчен аларның йөрәкләренә каплавыч яптык һәм колакларын ишетмәс иттек»*** (17:46).

Әгәр үзен гаделлекнең үзе буларак таныткан Аллаһ кешегә Коръәнне аңларга юл куймаганга, иманга килергә мөмкинлек бирмәгәнгә күрә соңыннан кешене имансызлыгы өчен аны җәһәннәм утына ата торган булса, мондый илаһ гадел булмас иде, тиңдәшсез бер залим булыр иде. Әмма Коръәндә Үзе турында дистәләгән мәртәбә ***«лә йухиббү әз-залиминә»***, ягъни ***«золым кыйлучыларны сөйми»***, дип тәкрарлап торган Аллаһ, әлбәттә, гаделсезлек кыйлучы залим була алмый, залим түгел дә. Әгәр Аллаһ бәндәсенә Коръәнне аңларга мөмкинлек бирми икән, димәк, ул бәндәне йөрткән *рух*, Аллаһ сүзен ишетеп, аны аңларга әле лаек түгел. Димәк, андый рухның уяныр сәгате, аның кыямәт сәгате әле җитмәгән. Андый рух җирдә өстерәп йөргән ике аяклы каберләрдән әле ничә мәртәбә кубарылыр, ничә мәртәбә җавапка тартылыр, анысын Аллаһ үзе

генә белә. Чираттагы мәртәбә җиргә килгән рух кайчан да кайчан «минем ишәгем кайда?» дип түгел, «Минем Раббым кайда?» дип кычкыра, шулчакта аңа Коръән дә ачылачак, иман да биреләчәк: ***«Аллаһның рөхсәтеннән башка кеше (нәфес) иман китермәс»*** (10:100). Аллаһ үзенең карары белән кешегә иманны бирми икән, димәк, ул кешене йөртүче рухның әле үсәсе дә үсәсе, куәтләнәсе дә, куәтләнәсе.

***Җәһәннәм газаплары***

Җәһәннәм газаплары турында да дини китаплардан укып беләбез. Аларны бәндәчелегебез белән, аңсызлыгыбыз белән генә тән газабы буларак кабул итәбез. Кеше тәнен җәзага дучар иткәндә, авырту билгеле бер дәрәҗәгә җиткәч, кеше аңын җуя да, аны киссәң дә, турасаң да, ул аны сизмәячәк. Газапның иң авыры ул – рухи газаптыр. Рух аңын җуя алмый. Ул һәрчак уяу. Ул йокыга китеп кенә булса да газаплanудан котыла алмый.

Кешенең җәһәннәмдә акылга сыймаслык һәм төрледән-төрле җәзалар белән җәзаланачагы турындагы тәгълимат безне уйга калдырырга тиеш: ул да булса, бәндәсен дөрләп, улап, котырып янып торган утка, ялкын эченә тереләй атачак Аллаһ үзен Рәхимле, Мәрхәмәтле дип, ягъни «әр-Рахман» «ар-Рахим» дип, бер илаһ буларак танытыр идеме? Коръәннең һәр сүрәсенең башында «бисми Аллаһи әр-Рахмани әр-Рахими» дип искәртеп торыр идеме? Кодси хәдисләрнең берсендә Аллаһ тәгалә үзе турында: *«Мине нинди итеп күзалласагыз, Мин шундыймын»*, – дигән. Мин, Аллаһны бәндәләрен утка атып, аларның газаплануларыннан тәм табучы бер залим буларак күзалллый алмыйм.

Инде фикеребезне дәвам итик. Җәһәннәмдә җәзалауның төп чарасы булып, мәгълүм балганча, утта яндырылу тора. Учакка атылып яндырылып үтерелгәннәр азмыни булган? Бу гына да җәһәннәмнең биредә булуын раслый түгелме? Коръәндә тәмуг газапларының төрлесе сурәтләнгән. Җәһәннәмдә кеше утта яндырылу белән җәзаланачак, диелә. Әмма беркайда да тәмуг ияләренең үз балаларын ашарга мәҗбүр булачаклары турында сүз йөртелми. Ә дөньяда, без яшәгән бу җирдә, безнең әле ул кадәр борынгы булмаган тарихыбызда аз булганмы ачлыкка дучар ителгән кешеләрнең үз балаларын ашарга мәҗбүр булулары? Мондый җәзаны кичергәннәрне нинди генә тәмуг куркыта алыр икән?

Кеше тәненнән гыйбарәт булган бер кабергә салынган *рух* күзеннән карасаң, яну, яндырылу нәрсә ул? Шул тәндә, шул кабердә булу – үзе янудыр, чөнки терек биологик җисем аның күзәнәкләрендә туктаусыз рәвештә барган яну (окисление) исәбенә генә терек булып кала. Яну өчен ягулык кирәк. Ягулык – тән күзәнәкләрендәге матдәләрдер. Ул күзәнәкләрдәге ягулык кимегән саен кешенең тәне картая бара һәм, ниһаять, яну өчен матдә калмаган мизгел җиткәч, *рух* кабердән кубарыла да, Аллаһ катына

алына. Тәкъдирендә башкача язылган булса, рухка тәннең картайганын күтеп торырга да туры килми. Мондый фаҗигале үлемнәр азмыни?

Кешене биологик бер тереклек итеп карасак, аның бәдәнендә никадәр генә җан ияләре яшәми: бактерияләр, вируслар, төрледән-төрле микроблар. Кеше эчендә бер галәм – тереклек галәме кайнап тора! Ул галәмдәге тереклек арасында паразитлар да күп. Болары, асылда, кабер булган бу бәдәнне тереләй ашыйлар, үсәләр, үрчиләр, аны үзләренең нәҗесләре белән агулыйлар, зәгыйфьләндерәләр һәм еш кына үлемгә дә дучар итәләр. Шуңа күрә җирдәге кабердә яткан мәетне ашаган кортлар турында уйлаганчы, безнең, ягъни *рух*ның, зинданы булган бу терек тәнне эчтән корыткан, ашаган кортлар турында, аның һәр күзәнәген ялкынсыз булса да чып-чынлап яндырган химик күренешләр турында уйласак, хәерлерәк булмасмы? Боларны истә тотсак, бәлки, уянып китәргә җиңелрәк булыр?

Тагын бер нәрсә турында да фикер йөртеп карыйк: җирдә булган бихисап кабер ияләренең кубарылачагы көн Кыямәт көне (*йәүме-л-кыййәмә*) дип атала. Каберләрдән кубарылган кешеләрнең хөкемгә тартылу көне – Хисап бирү көне (*йәүме-л-хисаб*), Хөкем көне (*йәүме-д-дин*) дип атала. Хәер, шулай булсын, ди. Безне бу вакыйгалар бермәлдә була торган нәрсәләр итеп кабул итәргә өйрәткәннәр. Әмма, Аллаһ барлыкны алты көн (*йәүм*) эчендә булдырды (25:58), дигәндә, бу *«көн»* дигән нәрсәне һич тә безгә мәгълүм булган 24 сәгатьлек тәүлек буларак тасвирламыйлар, ә бәлки, озак дәверләр, миллионлаган, миллиардлаган еллар дәвамында сөргән эш буларак күрсәтәләр: ***«Алар сине газап белән ашыктыралар, әмма Аллаһ вәгъдәсенә хилафлык кыйлмый. Чынлыкта Раббың хозурындагы бер көн сезнең исәп белән саналган бер мең елга тиң»*** (22:47).

Эш дигәндә, Коръәндәге «әмер» сүзе күп очракта фәрман, боерык түгел, нәкъ менә эш мәгънәсендә килә: ***«Ул эш*** (әмер) ***белән Күктән Җиргә кадәр идарә итә. Аннан соң ул эш Аның янына сезнең исәп белән үлчәме мең ел булган бер көн дәвамында күтәрелә»*** (32:5).

Аллаһ һәм кеше өчен вакыт үлчәмнәренең төрле булуына тагын бер аять ишарә итә: ***«Фәрештәләр һәм рух Аның янына микъдары илле мең ел кадәр булган бер көн дәвамында күтәреләләр»*** (70:4).

Болай булгач, Кыямәт көне, Хисап көне, дигәндә дә, бәлки, шундый дәверләр күздә тотыладыр? Бу ноктаи назардан караганда, кешелек дөньясы кичергән тарихи чорлар, кешеләрнең вәхшилек дәвере, «таш гасыр», «бакыр дәвере», «тимер дәвере», Урта гасырлар кебек нәрсәләр дә шул Кыямәтнең бер өзеге генә түгелме икән?

Ә бәлки, Кыямәт тә инде вакыйга булып, без Мәхшәр мәйданына инде китерелгәнбез дә, җавап бирәбездер? Нинди күзлектән карыйсың бит: вакыты чикле булган кеше күзлегеннән, үлемне татыячак нәфес ноктасыннан

бакканда һич тә алай булып күренми. Ә мәңгелек рух күзлегеннән караганда, тарихта калып югалган ул гасырлар, ул дәверләр, миллионлаган еллар – җәһәннәмнең мәңгелек газабы булмыйча, тагын ни булып күренсен?

Урта гасырларда яшәгән Әхмәд Биҗани исемле бер язучы үзенең «Әнвар әл-Гашыйкыйн» исемле китабында мондый бер хәдис китерә: «Гаишә р.а. үзенең хәләл җефете Мөхәммәд пәйгамбәрдән (ﷺ): *«Нигә син безне Кыямәт хәлләреннән бик аз аңартасың?»* – дип сораган. Пәйгамбәребез (ﷺ): *«Ә сез ул Кыямәтнең барганын, барыбер, белми калачаксыз»*, – дип җавап биргән. *«Ничек инде белми калачакбыз?»* – дип сорый икән аптырап калган Гаишә р.а. Пәйгамбәребез (ﷺ): *«Әйе шул, иң мөһим өч хәлне белми калачаксыз, – дигән, – ул да булса Сират күпереннән үткәнегезне белмәячәксез, гамәл дәфтәрләрегезнең кулларыгызга тоттырылып укылганын белмәячәксез, һәм, укылып барланганнан соң, ул гамәлләрнең Мизанга салынып үлчәнгәнен белмәячәксез»*, – дип җавап биргән. Тәмам хәйран калган Гаишә р.а. шулчакта мондый сорау биргән: «Алай булгач, Коръән кәримдә килгән ***«ул көнне җир башка җир белән алмаштырылачак һәм күкләр дә...»***[*]***,*** *аять кәримәне ничек аңларга соң? Кешеләр кайда булачак соң ул көндә?»* – дип сорый. Мөхәммәд пәйгамбәр (ﷺ) хатынына сокланып карап ала да, аның зирәклегенә исе китеп: *«И, Гаишә! Сиңа кадәр бу турыда һичкем сорамаган иде!»*, – ди, һәм дәвам итә: – *«Җир һәм күкләр башка җир һәм күкләр белән алмаштырылган көндә кешеләр Сират күперендә булырлар!»* – дип җавап бирә.

Пәйгамбәребезнең (ﷺ) хәдисләре арасында яңадан «тууга», ягъни рухның кабердән кубарылып җавапка тартылганнан соң яңадан җәһәннәмгә барып төшәчәгенә ишарә итә торганнары байтак. Мәсәлән, югалган ишәген эзләп йөргән вакытта үлеп киткән берәү турындагы хәдисне искә аласым килә. Пәйгамбәребезнең (ﷺ) әйтүенә күрә, кыямәт җитеп кубарылган мәлдә ул кеше, кабереннән торып басу белән: «Минем ишәгем кайда?» – дип сөрән салачак.

Беренче карашка, бу хәдис кыямәт мәсьәләсендә диндә таралган гомуми карашны бәян итә. Әмма ул хәдистә бәян ителгәннәргә *рух* күзлегеннән баксаң, чираттагы мәртәбә кеше гәүдәсенә иңдерелгән рухның халәте тасфирланганы аңлашыла. Ягъни, рухны йөртүче бәндә үсеп балигъ булгач, шәхес буларак җәмгыятьнең тулы хокуклы әгъзасы булып өлгергәч, андагы рух үзенең Аллаһка таба юнәлгән үсешен үткән яшәешендә туктап калган ноктадан, үткән тормышында ирешкән халәтеннән дәвам итәчәк. Тәмуг чокырына Сират күперенең нинди урыныннан егылып төшкән булса, яңадан җиргә килгәч, яңадан Сират күперенә куелгач, нәкъ шул егылып төшкән урыныннан «атлап» китәчәк.

---

* Коръән, Ибраһим сүрәсе (14), 48-нче аять.

Бу йөздән Мөхәммәд пәйгамбәрнең (ﷺ): *«Ялгызлык эзләп тау куышларына, далалар-урманнарга кереп югалмагыз, чөнки мәет тиңе булырсыз».*–дип, ни өчен кешеләргә җәмгыятьтән аерылмаска кушканы да аңлашыла. Рухның дөрес юнәлештә, тиешле юнәлештә үсеше аны йөрткән кешенең җәмгыятьтә, үзе кебекләр арасында яшәгәнендә генә мөмкин.

Реинкарнациянең барлыгына ишарә итә торган тагын бер хәдисне искә аласым килә. Көннәрдән беркөнне пәйгамбәребез Мөхәммәд (ﷺ) сәхабәләренә куенында баласын тотып урам буйлап сак кына атлап баручы бер хатынга ымлап күрсәтеп: *«Сез ничек уйлыйсыз, ошбу хатын баласын утка атар идеме?»–дип сораган. Тегеләр барысы да беравыздан: «Булырмы андый нәрсә? Әлбәттә, үз иркендә булса, баласын һич утка атмаячак!»–дип җавап биргәннәр. Пәйгамбәребез: «Ә нигә утка атмаячак?»–дип сораган. Сәхабәләр: «Чөнки ул–анадыр. Ана исә баласын иң яратучы зат»,–дигәннәр. Шунда пәйгамбәребез: «Шуны белегез ки, Аллаһ Тәгалә Үзенең бәндәсен, бу ана үз баласын яратканнан чагыштыргысыз дәрәҗәдә ныграк ярата!»*–дигән.

Бу хәдистән аңлашылганча, Аллаһ Тәгалә бәндәсен утка атмаячак, аны утка атып, аның шул утта куырылып янганын күзәтүдән ләззәт алып утырмаячак. Нигә соң Коръән гөнаһкярларның утта яначаклары турындагы куркытулар белән тулып ята? Чөнки куркыту дөнья белән мавыгып яшәп яткан нәфес колын, ягъни гади кешене сискәндереп җибәрү өчен кирәк. Пәйгамбәр заманында яшәгәнме андый кешеләр, хәзерге вакытта яшиме алар–аерма юк. Кешенең дөнья белән мавыгуы–аның һәр дәвердә чәчрәп торган асыл үзенчәлегедер. Шулай да, пәйгамбәр заманындагы кешеләр белән хәзерге заман кешеләр арасында аерма булмаса да, заманнар арасында аерма бар. Ул аерманың ни икәнлеген аңлап, шул аерманы истә тотарга кирәк: үлем түшәгендә ятканда пәйгамбәребез (ﷺ) имән бармак белән урта бармагын бергә кушып: *«Минем китүем белән Ахырзаман шушы ике бармак арасы кадәрдер»,*–дигән. Ул ике бармак берсенә берсе кушылганда алар арасында буш ара калмавын истә тотсак, Ахырзаманның нәкъ менә пәйгамбәрнең вафатыннан соң башланган булуын фараз итеп була. Болай булганда, без Ахырзаман дәверендә яшибез, димәк. Шуны да истә тотарга кирәк.

Алга барыр өчен җәннәт белән җәһәннәм турында тагын бер нәрсә әйтергә кирәк. Болар икесе дә булдырылган, монысы мәгълүм. Коръәндә дә, дини китапларда да бу турыда ачыктан-ачык әйтелгән. Әмма, Коръәннән аңлашылганча, җәннәт тә, җәһәннәм дә үзләренең кайчандыр билгесез киләчәктә тутырылачакларын «көтеп» ятмыйлар. Алар икесе дә үзләренә йөкләнгән вазифаларын башкарып тору өчен булдырылганнар. Димәк, оҗмах та, тәмуг та элек тә, хәзерге вакытта да һич туктамастан «эшләп» торалар.

Мәсәлән, җәннәт, ягъни, безнеңчә әйткәндә бакча, оҗмах турындагы кайбер аятьләргә күз салыйк:

***«Һәр нәфес – үзе кәсеп кыйлганының тоткынидыр, мәгәр, уң як ияләреннән тыш. Алар оҗмахларда бер-берсеннән сорашалар»*** (74:40);

***«Андыйлар оҗмахларда кадерләнүчеләрдер»*** (70:35);

***«...алар – нигъмәт оҗмахларында кадерләнүчеләрдер»*** (37:43);

***«Чынлыкта тәкъвалылар имин бер урындалар, – чишмәле оҗмахлардалар»*** (44:51–52);

***«Сабыр кыйлмышлары өчен*** [Аллаһ] ***аларны оҗмах һәм ефәкләр белән бүләкләде»*** (76:12);

***«...оҗмахка кертеләләр һәм һичнәрсә белән дә кыерсытылмыйлар»*** (19:60);

***«Тәкъвалык кыйлган бәндәләребезгә мирас итеп тапшыра торганыбыз – оҗмах шулдыр»*** (19:63);

***«Безнең аятьләребезгә инанмышлар һәм исламда булмышлар*** (ягъни мөселманнар) ***оҗмахка керегез, – үзегез һәм хатыннарыгыз»*** (43:70).

Мондый аятьләр Коръәндә бихисап. Андый аятьләрдә сыйфат фигыльләр аша җәннәт ияләренең аять иңгән мәлдә инде оҗмахта булулары турында хәбәр ителә. Аятьләрдә фигыльләр кулланылган булса, ул фигыльләр, хәзерге заман шәкелендә килеп, җәннәт ияләренең аять иңгән мәлдә үзара аралашуда булуларын, анда кыерсытылмауларын белдерәләр, җәннәтнең тәкъвалыларга тапшырылып торуын белдерәләр, ә фигыль үткән заман шәкелендә килсә, андый фигыль җәннәтнең Аллаһ тарафыннан инде бүләк ителгән булуын белдерә. Җәннәт кайчандыр киләчәктә ачылачак, дигән мәгънәдәге аятьләр юк. Бу дөньяда кеше кыяфәтендә кат-кат яшәп, Аллаһ тарафыннан куелган барлык сынауларны узган рухлар оҗмахка кертелә торалар, ә сынауларын әле үтеп бетмәгән рухлар җәһәннәмдә «януларын» дәвам итәләр. Моның шулай булуы, тәмуг турындагы аятьләргә карасак, бик яхшы күренә:

***«Чынлыкта, тәмуг тозак булып чыкты, – чаманы белмәүчеләр өчен кайту урыныдыр. Алар аңарда озак гасырлар үткәрүчеләрдер»*** (78:21–2);

***«Чынлыкта, җинаять кыйлучылар – тәмуг газабында мәңге кала бирүчеләрдер»*** (43:74);

***«Раббыларын кире какмышлар өчен – тәмуг газабы»*** (67:6);

***«Аларның торыр урыны – тәмугдыр, – ул сүнә башлаган саен аларның януларын арттырабыз»*** (17:97);

***«Чынлыкта, Раббысына гөнаһкяр буларак килүчегә, чынлыкта аңарга җәһәннәмдер, анда ул үлми дә, яшәми дә»*** (20:74).

Биредә дә җәһәннәм кайчандыр киләчәктә булачак, дигән мәгънәдәге аятьләр юк. Әмма Коръән тәфсирләрен яки тәрҗемәләрен укысаң,

җәннәт һәм җәһәннәм белән бәйле хәлләр һәрчак киләчәккә күчерелгән. Мәсәлән, соңгы (20:74) аятьтә җәһәннәм турында ***«аңарга җәһәннәм булачак», «аңарга җәһәннәм әзерләнеп куелган»***, дип тәрҗемә итәләр. Бу тәрҗемәләрнең икесендә дә җәһәннәм киләчәктә булачак бер нәрсә итеп күрсәтелгән, әмма аятьтә киләчәкне күздә тоткан һичнинди мәгънә юк. Бу аятьтә җәһәннәмнең хәзер булуы, гөнаһкярларның хәзерге вакытта шунда булулары хәбәр ителә. Шул ук аятьнең ***«анда ул үлми дә, яшәми дә»***, дигән гыйбарәсен алыйк. Минемчә, биредә сүз Коръәндә «түбән яшәеш» дип аталган безнең бу дөньябыз турында бара. Язманың башында үлемнең юклыгы турында язган идем. Шуңа күрә, үлеп булмый. Әмма яшәү дә әле башланмаган: ***«анда ул үлми дә, яшәми дә»***. Яшәүнең иң түбән бер шәкеле булмыйча, нәрсә булсын бу? Без яшәгән бу хәсрәт дөньясы булмыйча, ни булсын ди ул җәһәннәм?

Аңлашылганча, хәзерге вакытта «эшләп» торган җәһәннәмнең һәм андагы хәлләрнең киләчәккә күчерелүләре аятьләрнең мәгънәләрен бозып, ягъни аятьтә килгән фигыльләрнең хәзерге заман шәкелен тәрҗемә-тәфсирләрдә киләчәк заман шәкеленә әйләндерү аша яки бу мәлдә булган эшне белдерә торган сыйфат фигыльләрне һәм сыйфат фигыль булганга күрә исемләшкән сүзләрне һич тә тартынып тормастан киләчәк заман шәкелендәге фигыль итеп бирү аша башкарыла.

### ***Йомгак***

Минем бу язганнарым реинкарнация турында уйлап йөрүем нәтиҗәсендә барлыкка килгән нәрсә түгел. Исемдә дә юк иде бу реинкарнация дә, рухның күчеп йөрүе дә, шул рәвешле төрле баскычлар узуы да. Беткән идемени минем ике кулыма алып хәл итәчәк кырыкмаса-кырык дөньяви мәшәкатьләрем? Әмма, шулай да, тормышым дәвамында үзара бәйнә-бәйнә бәйләнеп килгән хикмәтле, гыйбрәтле, сәер вакыйгалар чылбыры да үсә торды. Шул ук вакытта, үземә дә сиздермәстән, эчке халәтем, рухи халәтем дә үзгәрә барган икән. Миңа ни булды икән, дип, Коръәнгә ябыштым, шуннан табарга тырышуым иде күңелем тынычлыгын. Бу изге илаһи нотыкны укыганымда мәгънәләре миңа инде күптәннән таныш булган аятьләр үзләренең бөтенләй башка мәгънәләрен ача башладылар. Мин Коръәндә реинкарнация турында белге-хәбәр эзләмәдем, ул тәгълиматны бәян иткән аятьләр мине үзләре ачып бирделәр.

Реинкарнация дигән нәрсәне дә мин уйлап тапмадым. Ул бик борынгы төшенчә, ислам диненә кадәр күптән элек барлыкка килгән диннәрдә ул инде мәгълүм нәрсә булган. Өстәвенә, рухның тәннән тәнгә күчеп йөрүен борынгы заман кешесе үз белдеге белән уйлап чыгара алмаган, табигый. Борынгы кеше моны ничек уйлап чыгара алсын, ди, әгәр моннан мең ярым ел чамасы элек Мөхәммәд пәйгамбәр (ﷺ) үзенең замандашларын

үлемнән соң яшәешнең дәвам ителәчәгенә ышандыра алмый интеккән булганда? Исламга кадәрге диннәрне тотучыларга реинкарнациянең булуы, әлбәттә, Аллаһ тарафыннан хәбәр ителгән булган. Тик ул чакта да дин әһелләре әлеге тәгълимат турындагы билгеләрне үзләренең тәфсирләре кәфененә төреп юкка чыгарырга тырышканнар һәм уңышка ирешкәннәр. Кешеләр бу тәгълимат турында белмәгәндә шайтаннар кешеләрне интектерүләрен дәвам итә алалар. Шайтаннар адәм баласы кичергән хәсрәт, кайгы, сыкрау, нәфрәт, явызлык кебек тискәре һәм яман тойгылар белән тукланалар. Шуңа күрә адәм баласы бу җәһәннәмдә никадәр озак калса, шайтаннарга да шулкадәр рәхәт булачак.

Зинданда туып үсеп җитешкән берәүне күз алдына китерик. Аңа: «Зиндан гына бар, зинданнан башка бер дөнья юк!» – дип тукып торсалар, андый кешенең тирә-юньне аңлавы бертөрле булачак: ул үзенең зиндандагы яшәешеннән башка яшәеш юк, дип уйлаячак. Әгәр аны: «Киләчәктә сине зиндан көтә», – дип куркытсаң, ул чакта андый кешенең тирә-юньне аңлавы бөтенләй башкача булачак, чөнки андый кеше үзенең зинданда тоткын булуын һич аңлый алмаячак. Ислам тәгълиматы Коръән аша бәян ителә башлаган елларда кешеләр бу дөньяда яшәештән тыш ахирәт барлыгын һәм ул ахирәттә дә яшәеш барлыгын ишетеп хәйран калганнар, моңа ышана алмаганнар. Әмма ахирәт барлыгына инанганнары Коръән аятьләреннән тәмугның хәзерге вакытта ук «эшләп» торуын һәм кыйлган гамәлләр өчен җәза бирелү өчен булдырылган бер урын булуын аңлый алганнар, шуңа күрә бар көчләрен куеп, җан-тәннәрен фида кыйлып, аннан котылу юлларына басканнар. Андый ихлас иманлылар китеп беткәннән соң, күк капусы ябылган сыман, ислам диненең беренче гасырларында ачылып алган коткарылу капкалары да ябыла башлаган, чөнки Коръән тәгълиматын аңлату эше белемсез, әмма шул ук вакытта зәһәр акыллы дин галимнәре карамагына калган. Болар үзләренә инанган халыкның аңына тәмуг кешеләрне киләчәктә көтә, дигән бозык тәгълимат сеңдерә башлаганнар.

Әмма монысы да Аллаһтан бирелгән сынау, чөнки үзен Аллаһ бәндәсе дип санаган һәркем икесенең берсен сайларга тиеш: үзләренә «дин галиме» исемен такканнарның сүземе, әллә Коръәндә әйтелгәннәрме хак?

Коръән һәм ислам дине рухка башка яшәешнең барлыгы турында хәбәр җиткерү өчен, ул зиндан караңгылыгыннан җәннәт яктылыгына чыга алсын өчен бирелгәннәр. Реинкарнация турындагы белем бер яктан, зинданда тоткын булып калуның ни рәвешле дәвам иттерелүен аңларга ярдәм итә, икенче яктан, иман вә гыйбадәт ярдәмендә ул зинданнан Аллаһ рәхмәте белән котылу юлларының барлыгын да күрсәтә.

Реинкарнация бар, дип язсам да, мин бары тик үземә ачылган белем белән уртаклаштым. Хакыйкатьнең чыны бары тик Аллаһ Тәгаләнең

үзенә генә мәгълүм. Камиллек тә бары тик Аңа хас. Шуңа күрә борынгы заманда иҗат иткән нәкышчеләр, төрле биналарны булсын, китапларны булсын күз явын алырдай бизәкләр белән бизәүче осталар шул бизәкләренең бер почмагында эшне тәмамламагандай калдыра торган булганнар. Шул рәвешле алар соң дәрәҗәдәге камиллекнең бары тик Ходай булдырган нәрсәләргә хас булуына, җитешсезлеккә урын калдырмыйча булдыручының бары тик Ул булуына ишарә итеп, Аллаһка карата әдәп саклый торган булганнар. Бу йөздән минем бу язмамда хәбәр ителгән карашларым да һичбер сурәттә тулы, камил, төзек бер тәгълимат буларак кабул ителергә тиеш тә түгел, лаек та түгел. Шуңа күрә минем язганнарымны укып чыккан теләсә кем: «Бу кеше Коръәндәге фәлән аятькә игътибар итмәгән, ул аять исә аның язганнарына каршы килә!»–дип җөпләп куя алачак һәм хаклы булачак. Андый бер аятьне үзем дә китерә алам: ***«Әй син, тынычланган нәфес! Разый рәвештә һәм үзенә карата ризалык казанылган рәвештә Раббыңа кире кайт! Минем бәндәләрем арасына кер! Минем җәннәтемә кер!»*** (89:27–30). Бу аятьтә ***«Минем җәннәтемә кер!»*** дигәндә, сүз нәкъ менә *нәфес* турында бара.

Бу сүзләрдән җәннәттә дә үлем-китем булачак, дигән нәтиҗәгә килеп була, чөнки шул ук Коръәндә ***«һәр нәфес үлемне татучыдыр»*** (29:57), диелгән. Бу исә Коръәннең ***«анда*** [оҗмахта] ***беренче үлемнән башка үлемне татымаячаклар»*** (44:56), дигән аятенә каршы килә. Әмма Коръәндә исә эчке каршылыклар булырга тиеш түгел. Бер аятьнең икенчесенә каршы килүе ул аятьләр язуда теркәлгәндә икесенең берсенә кеше кулы тигәннән булырга мөмкин. Андый очраклар, ягъни кешенең үз белдеге белән Коръәнне үзгәртү очраклары, тәхриф кыйлу очраклары булган. Коръәннең теркәлү тарихын яхшылап өйрәнгән дин галимнәренең бу хакта белүләре ихтимал. Әмма алар белсәләр дә белдекләрен яшерәләр, чөнки фетнә чыгуыннан куркалар.

Шулай да, Аллаһ Тәгалә Коръәнне үзе саклаячагы турында вәгъдә иткән булган. Һәм Коръәннең Аллаһ тарафыннан сакланылуы аның язуда дөрес теркәлгән булуын күздә тотмый. Сүз Аллаһның рәхмәте белән изге китапның һәр парчасыннан тулы бер Коръәннең пәйда булуы турында бара. Болай дип әйтүемдә һичнинди сәерлек юк. Шул ук «Фатиха» сүрәсен генә алыйк. Дин галимнәренең һәммәсе дә бу сүрәнең җиде аятенә Коръән кереп беткән, диләр. Чыннан да, Коръән андый үзгәртелгән урыннарны үзе үк фаш итә, чөнки андый тәхрифләр изге китапның гомуми рухына каршы киләләр. Бу йөздән, хәзерге вакытта, мин нәфеснең дә җәннәткә кертелә алуы турындагы аятьне әнә шул күзлектән кабул итәм.

Әмма башка ихтимал да бар. Мәсәлән, фараз итик, җәннәттә дә кеше рух һәм нәфестән торган зат буларак яшәячәк, дип. Тик бу очракта, җәннәт

булганына күрә, рух нәфеснең тоткыны булмый, киресенчә, нәфес рухка тулысынча буйсыначак. Кешенең барлыгы нәфес белән түгел, рух белән бәйле булачак. Аның күзләре дә, акылы да тирә-якны нәфес, мин-минлек күзлегеннән түгел, рух күзлегеннән кабул итәчәк. Җәннәт иясе ителгән бәндә үзенең барлыгын, үз-үзен белүне рухы белән бәйләячәк һәм шул сәбәпле, үлемсез булачак. Җәннәт иясе үзен рух дип беләчәк. Ягъни, фараз итик, рух бу дөньяда яшәгән чагында тәннәрне ничек алыштырган булса, җәннәттә дә тәннәрнен алыштырып торачак, әмма бу алыштыру аңлы булачак, без бу дөньяда кием-салымнарыбызны алыштырган кебек, үлемсез ителдегебез ул җәннәттә тәннәребезне шулай алыштырачакбыз. Бу очракта рух үлемне юкка чыгаручы көч буларак түгел, яңа мөмкинлекләрне ача торган капка буларак кабул итәчәк.

Бу турыда әле тагын да дәвам итеп булыр иде, әмма озакка китәчәк. Шуңа күрә туктый да белергә кирәк. Дөресен бары тик Аллаһ Үзе генә белә.

Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтуһу!

**Әдәбият**


1. Габделбари хәзрәт Низаметдин улы Исаев. Коръән кәрим тәрҗемәсе / Фәнни мөхәррире Ә.К. Бостанов. Казан: Издательский дом «Казанская недвижимость», 2018.
2. Ислам дине нигезләре. Казан: «Хозур»-«Тынычлык» нәшрият йорты, 2018.
3. Ислам турында сөйләшик. Дин белән кызыксынучылар өчен кыскача энциклопедия, 2 нче басма. Казан: «Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты, 2016. Б. 159.
4. Комментарий имама Акмалюддина аль-Бабирти к «Завещаню» («аль-Васыя») имама Абу Ханифы. Казань: «Издательский дом Хузур» – «Спокойствие», 2019.
5. Мәет озату йолалары. Казан: «Хозур»-«Тынычлык» нәшрият йорты, 2018.
6. Са’ди Абд-ал-Малик. Исламское вероучение: толкование акыды «Ан-Насафия» / перевод с арабского языка. Казань: Институт истории АН РТ, 2008. С. 117.
7. https://darulfikr.ru/articles/zhizn-posle-smerti/.

## ТАТАР ДАСТАННАРЫНДА МИЛЛИ ТАРИХ

*Исең барда ил таны, көчең барда җир таны, дигән бабаларыбыз. Тарихчы, этнолог Дамир Исхаков җитәкчелегендә Башкортостандагы изге, мәшһүр җирләребезне – Балкан тауны, Аслы күлне гизеп кайту, шөкер, менә шул хәтерне яңарту, борынгы бабаларыбызның тәгәрәп-аунап буй үскән төшләрен күрү булды да инде.*

*Юлдашларыбыз – морза нәселләренең дәвамчылары булган эшкуар Рәис Яушев белән тарихчы Мәгъсүм Акчурин шактый кызыклы әңгәмәдәшләр булып чыкты. Аерым алганда, Мәгъсүм морзаларыбыз турында бик бай мәгълүматлар туплаган. Рәис өчен, гомумән, Балкан тауны күрү, борынгы бабалары йөргән (ул турыда алга таба карый аласыз) сукмаклардан йөрү үзе бер якты хатирә булып истә калгандыр, дип уйлыйм.*

*Башкортостанда безне каршы алып кунак иткән, бергәләп изге җирләрне ураган милләтпәрвәрләребез – җәмәгать эшлеклесе Кадерле Имаметдинов, тарих фәннәре докторы, этнолог Фаил Сафин, икътисад фәннәре докторы Ринат Гатауллин, тарих фәннәре кандидаты Илнар Гарифуллин өчен дә шанлы тарихыбызны барлаган бу сәфәр тиз генә онытылмастыр. Казанга кайтып, юл тузаннарын каккач, Дамир әфәнде безгә сәфәрнең максаты, тарих фәнендә әле яхшылап ачыкланып бетмәгән кимак (йәмәк) бабаларыбызның милли тарихыбызга керткән өлеше, яңа гына тәмамлаган «Татар дастаннарында милли тарих» дигән хезмәте турында тәфсилләп сөйләде.*

– Бик кирәкле, кызыклы сәяхәт булды бу. Әлеге Балкан тавына һәм Аслы күлгә бәйле «Түләк һәм Сусылу» дастаны, минемчә, зур игътибарга лаек. Әсәр исә – татарларда сакланган борынгы дастаннарның берсе. Мондагы вакыйгалар, минем тикшерүемчә, ундүртенче йөзнең икенче яртысына карый. Китап турында әйткәндә, ул – өч татар дастанына багышланган, ике йөз биттән артыграк кульъязма. Аның беренчесе – шушы «Түләк һәм Сусылу» дастаны. Икенчесе – «Идегәй», өченчесе – «Чура батыр» дастаны. Әлеге хезмәткә алынуымның сәбәбе – фольклорчыларыбыз дастаннарны теле, сюжеты ягыннан гына өйрәнгән, ә анда нинди тарихи мәгълүматлар булуы алардан бераз читтә калып килде. Өйрәнү барышында бик кызыклы нәрсәләр ачылды. Шушы өч дастан арасында борынгылыгы белән беренчесенең аерылып торуын күрсәтү кирәк. Бу дастан татарларда һәм башкортларда гына бар. Теге икесе кыпчак телле байтак төрки халыкларда сакланган. Башкортларда язып алынган вариантларда Түләк берничә төрле атала. Әйтик, берсе – Заятүләк. Тик шунысы бар: башкортларда язып алынганнары унтугызынчы йөзгә ка-

рый. Татарларда исә бу эпос язма рәвештә сакланган. Аны Миркасыйм абый Госманов табып алды. Ул – иң борынгысы: уналтынчы гасырга карый. Теле ягыннан уналтынчы, унҗиденче гасырларга караучы башка язма чыганакларга охшаш. Шулай итеп, дастанның иң борынгы өлеше татарларда табылган. Шуңа күрә дә аны безнең милли мирас, дип әйтә алабыз.

***– Шулай да бу дастан ни өчен аерым игътибарга лаек?***

– Анда Түләкнең язмышы сурәтләнә дә, Түләкнең кем баласы икәне әйтелә, аңардан соң кем килгәнлеге искәртелә. Дастанның ахырында булган мәгълүмат нигезендә татар тарихында билгеле булган Болгар хөкемдары Габдулла искә алына. Аны хан дип тә йөриләр. Дастан буенча, Габдулла Түләкнең улы булып чыга. Ә Габдулланың Алтын бәк белән Галим бәк дигән ике улы турында риваятьләр бар. Иске Казанга нигез салучы бу шәхесләр, димәк, шушы бер үк нәселдән булып чыгалар. Әлеге дастанны өйрәнгәндә мин шундый нәтиҗәгә килдем: бу шәхесләр, кыят кабиләсеннән булып, Чыңгызханның үз кабиләсе вәкилләре. Иң кызыгы шунда: алар элеккеге Болгар вилаяте җиренең бер өлешендә хөкемдар булып утырган.

Түләк турында дастанда шундый юллар бар: ул, даулы, шаулы вакыйгалардан соң, «Олуг шәһәр» янына күчерелә. Олуг шәһәр ул – чынлыкта Биләр шәһәренең башка исеме. Урыс елъязмаларында аны «Великий город», дип язган булганнар. Биләр үзе дә – шундый мәгънәдәге сүз. Биләр шәһәрендә кыят кабиләсеннән булган хөкемдарлар утырган булып чыга. Аларны урыслар «Болгар кенәзләре» дип йөрткән. 1487-нче елда урыслар беренче тапкыр Казанны басып алганнан соң, бөек урыс кенәзләренең титулларында «Болгар кенәзләре» дигән титул элементы барлыкка килә. Соңрак хакимлек иткән урыс патшаларының титулларында да «Болгар кенәзләре» дигән титул бар иде. Монголлар Идел буен яулап алганнан соң, аларның вәкилләре Болгар вилаятендә утыруын күрсәткән бер дәлил бу. Димәк, Түләк шушы атаклы нәселдән килеп чыккан. Дастан буенча ул шушы Олуг шәһәрдә хан булып та тора. Дастанда язылганча, аннан алда хан булып торучы үлеп китә дә Болгар җирендә яшәүчеләр (анда татары да, болгары да булган), хан нәселеннән дип белеп, аны ханлыкка күтәргән. Соңыннан аның нинди нәселдән булуы ачыклана. Әмма инде ул тәхеттән төшми. Алай гына да түгел, тәхетне малаена калдыра. Малае Габдулла хан Аксак Тимер килгән вакытта Болгардагы хөкемдар булып саналган.

Бу дастанның әһәмиятенә килгәндә, анда бик еш «Балкан тау» һәм «Аслы күл» искә алына. Балкан тау Түләкнең үз җирләре итеп күсәтелә. Түләк «Олуг шәһәрдә» хан булганнан соң, шушы Балкан тауга барып,

«алтын тәхеттә» утырып, музыка коралларында уйнап, утлап йөргән малларын югарыдан карап торганы тасвирлана. Димәк, бу төшләр аның үз җире булган.

Археологларның әле анда барып тикшергәне юк. Унтугызынчы йөздә, фольклорчылар бу дастанны халыктан язып алганда, анда Түләкнең һәм аның хатынының кабер ташлары торганлыгы әйтелә. Кызганыч, Балкан тауда бу ташлар бүген күренми. Шуңа күрә археологларның анда булып казу эшләре алып баруы зарур. Күргәнебезчә, ул әллә ни зур тау да түгел. Бәлкем, ул ташлар авып, җир астында калгандыр. Ташлар табылса, бик әһәмиятле булыр иде.

Бу хәл башкортлар тарихына да карый. Чөнки дастанның баш өлешендә Бачман хан искә алына (кайчак ул солтан дип тә әйтелә). Түләк – шушы Бачман ханның нөкерләреннән, ягъни хезмәтче-якыннарыннан берсе, кенәз нәселеннән булган. Бачман солтан – бик әһәмиятле шәхес. Ул – югарыда телгә алынган Яушевның бабаларыннан берсе. Бачман солтан унөченче гасырда монголлар белән бик нык сугышып, Иделнең түбән агымында һәлак булганлыгы билгеле. Ул Идел буеннан көнчыгышка таба – Җаек бассейнында яшәгән көнчыгыш кыпчакларның – кимакларның башлыгы булган. Алар болгарлар белән бергә монголларга каршы сугышкан.

***– Кимакларның ул вакытта үз дәүләте булганмы соң?***

– Булган. Үз заманында хәзерге Оренбург урынында Актүбә дигән шәһәр торган. Шушы шәһәр – аларның башкаласы. Дәүләтнең исеме төгәл генә билгеле түгел. Аны Кимак каһанлыгы дип атаргамы, белмим. Һәрхәлдә, алар – кимаклардан бүленеп чыккан көнчыгыш кыпчаклар. Актүбә янындагы әлеге кыпчаклар бу якларга XI гасырда ук килә. Алар Хәрәзм шаһлар дәүләтенә бик нык береккән була. Кимаклар, ягъни көнчыгыш кыпчаклар, шушы Хәрәзм шаһ дәүләтендә гвардия буларак хезмәт иткән. Соңгы Хәрәзм шаһларының аналары шушы кимаклардан чыккан. Иң кызыгы шунда: әүвәл кимакларның дәүләте – Кимак каһанлыгы, Иртыш елгасы бассейнында булган. Әлеге дәүләтнең башында татар кабиләсеннән чыккан шәхесләр торуы билгеле. Шуңа күрә көнчыгыш кимакларны берникадәр татар булган, дип карап, безнең бабайлар дип саный да алабыз.

Менә шушы «Түләк һәм Сусылу» дастанына Бачман солтанның килеп керүе тагын да борынгырак бер дастан булуы турында сөйли. Соңыннан ул кимаклар монголлар кулы астында калган. Чөнки Түләк, әйтүемчә, кыят кабиләсеннән. Чынлыкта монда урта гасыр татарларының формалашу процессы күрсәтелә. Биредә кыпчаклар да, монголлардан калган татарлар да бар. Болар тора-бара береккән, без бер халыкка әверелгән-

без. Чынлыкта монда сүз безнең бабалар турында бара. Балкан тау, Аслы күл тарафлары – безнең белән барган Рәис Яушевның бабалары торган, дәүләт тоткан җирләр. Ул шуларны күреп кайтты да инде.

Дастанның эченә кереп китсәң, бик кызыклы нәрсәләр күзәтелә, әйтик, сихри элементлар да бар анда. Мәсәлән, Түләкнең хатынына әйләнгән Сусылу – су пәрие патшасы Чаждар ханның кызы. Әлеге ханның исеменә килгән вакытта, минемчә, монда Алтын Урданың хөкемдары күз алдында тотыла. Чаждар ул – чәчле дигән сүз. Монголлар озын чәч йөрткән. Нугайлар да шундый булган. Болгарлар мөселман булгач, чәч йөртмәгәндер, шуңа күрә аларга мондый хәл сәер тоелгандыр, күрәсең. Чаждар ханның шәхси биләмәсе кайдадыр читтә – Җаек елгасы буенда күрсәтелә. Дастанда Түләкнең үз ханы – Бачман хан җирләреннән качып киткәндә, Сусылуны Аслы күл янында күрүе һәм аңа гашыйк булуы турында әйтелә. Сусылу суга сикергәч, Түләк аны чәченнән эләктереп ала. Соңрак ул, су астына төшеп, Чаждар ханның рөхсәтен алып, сөйгәне белән кавыша. Күпмедер вакыт үткәч, аның ярдәме белән бабалары торган Олуг шәһәргә кайтарыла. Әлеге легендар шәхесләрнең, инде күренгәнчә, тарихи җирлеге бар. Шуңа күрә безнең өчен бу төбәкне барып күрү кызык булды.

Татар тарихында әлеге кимакларның роле, ни кызганыч, начар яктыртылган. Шуңа күрә Рәис Яушев үз бабалары турында китап язуымны сорагач, аның шәхси шәҗәрәсеннән тыш, кимаклар турында да бүлек яздым. Ул китапның исеме – «Средневековая история Яушевых и Кимакская проблема». Анда татарларның борынгы бабаларыннан берсе кимаклар булганлыгы дәлилләнә. Бу мәсьәлә хәзер безгә ачыграк күренә башлады. Моны татар галимнәре арасыннан Петербургта эшләгән шәрык белгече, филолог галим Әмир Нәҗип кенә яхшы чамалаган булган. Бартольд та ул мәсьәләне тотып-күреп ала. Аларның язуынча, монголлар килгәнче үк, безнең якларда, далаларда яшәгән татарлар булган. Монда нәкъ менә кимаклар күздә тотыла.

***– Кимаклар белән кыпчаклар икесе бер халык булып чыгамы инде?***

– Әйе, кимаклар – шул ук кыпчаклар, көнчыгыш як кыпчаклары. Тарих болай барган: Иртыш бассейнында – Кимак каһанлыгы XI йөздә оеша, соңыннан Кимак каһанлыгыннан кыпчаклар бүленеп чыга. Аларның көнбатышка киткәне – кыпчак (ягъни, «половцы» дигән исем ала), көнчыгышта калганы, борынгы өлешләре, кимак дип атала. Кимаклар арасында уйгырлар да, татарлар да булган, төрле-төрле кабиләләрдән торган алар. Араларында ким дигәндә җиде кабилә ачык чамалана.

Ни өчен моңа игътибар итәргә кирәк? Башкортостанның көнбатыш өлешен, Татарстанның көнчыгыш төбәген – Ык бассейны буйларын ал-

саң, анда кимакларның эзләре сакланган. Әйтик, Алабуга һәм Минзәлә якларында булган байлар кабиләсе шуңа ишарәли. Анда байаут, баят дигән атамалар чагылыш таба. Шул ук кабилә ул. Алар янында гына каңглы дигән кабилә атамасы бар. Без булган Аслы күлдән ерак түгел бу урын. Каңглы – шулай ук көнчыгыш кыпчакларның бер өлеше.

***– Ык буендагы табын, тамьян кабиләләре?***

– Алары соңрак килгән. Болар монголларга бәйле. Тик монголлар түгел, Алтайдан чыккан төркемнәр. Самара өлкәсенең төньягында соңрак башкорт булып йөргән бушман-кыпчак дигән төркем дә бар. Бу турыдан-туры теге Бачманга карый. Монда нәрсәне күзаллыйбыз? Монголлар килеп, әлеге көнчыгыш кыпчакларны җиңгән. Шулвакытта аларның бер өлеше хәзерге Башкортостанның көнбатышына, Татарстанның көнчыгышына, чиктәш өлешенә качканнар һәм шунда утырып калганнар. Башкортостанның көнбатыш өлешендә ни өчен халык татар телле, дигән сорауга җавапны менә шуннан да эзләргә кирәк. Алар борынгы вакыттан ук чын башкорт түгел, кыпчаклар, кимаклар һәм алар арасында, инде әйтелгәнчә, татарлар да булган. Башкортларның да, татарларның да борынгы бабалары монда уртак тамырлы булып чыга. Болар бик әһәмиятле. Тик бу хакта моңарчы әллә ни ачык язылмаган.

Татар телле башкортларның да бер бабалары кимак булып чыга бит. Моны Раил Кузеев үз вакытында бераз чамалаган. Ләкин ул иҗат иткән вакытта бу мәсьәләләр әле начар өйрәнелгән иде. Шуңа күрә ул бөтенесен дә тирәннән аңлап бетермәгән. Бер өлешен язган, аның хезмәтендә дә кыпчаклар еш кына искә алына. Әмма, нинди кыпчаклар турында сүз бара, аларның татарларга мөнәсәбәте нинди – бу хакта бер сүз дә язмаган ул. Монысы инде – безнең эш. Бу җәһәттән эзләнүләрне дәвам итәргә кирәк. Минемчә, әле бу яңа ачышларга китерәчәк.

Алтын Урда халкын гадәттә монгол-татарлар дип йөртәләр. Менә аның татар өлешен, татарларның кемнәрдән торганын аңларга кирәк. Татарлар чынлыкта кыпчаклар, кыпчакларга бәйле тагын да борынгырак төркем –татарлар. Болар – теге Үзәк Азиядәге татарлар. Шушы Үзәк Азиядәге татарларның бер өлеше, соңрак элиталы төркем булып (борынгы Төрки каһанлык егылгач, Кыргыз каһанлыгы оешкач), Иртыш бассейнына китә, анда яңа дәүләт – Кимак каһанлыгы коруда катнаша. Шулар эчендә кимаклар, кыпчаклар формалаша. Болар барысы да – татарларга бәйле төркемнәр.

***– Рәис Яушев Лениногорскида булган вакытта әнисе ягыннан – уналты буынны, әтисе ягыннан егерме буынны ачыклаганын әйткән иде.***

– Рәиснең әнисе ягыннан шәҗәрәсен төзүдә минем катнаш юк, ул аны документлар нигезендә үзе төзеде. Әтисе ягыннан шәҗәрәсен, әйе, мин

тикшердем. Анда тарихи документлар бик күп иде. Аңарчы да бу темага бер китап язган идем. Аның шәҗәрәсе, чынлап та, бик озын булып чыкты. Без аны Бачман солтанга, унөченче гасырның егерменче, утызынчы елларына кадәр җиткердек.

***– Егерме буын гына булмый бит бу?***

– Егерме буынны тәгаен ачыкладык, дип әйтә алам. Әмма Бачман солтанга җиткәндә ачыкланып бетмәгән өзеклекләр бар. Шәҗәрәләр барыбер Бачман солтанга барып тоташа. Җитмәгән буыннарны санасаң, чынлап та, бик күпкә китә. Татар дөньясында ачыкланган, сакланган иң борынгы шәҗәрәләрнең берсе бу. Моның белән Идегәй нәселе генә ярыша ала. Алай ярышырлык башка нәселләр күренми.

***– Идегәй нәселе сакланганмыни?***

– Үземнең кәгазь-документларын тәгаен күргәнем юк. Әстерхан якларында бар, диләр. Әстерхан ягында үзен, мин – бәк, кенәз, дип йөртүче кеше миңа таныш. Димәк, нәселе бар. Мондый зур шәҗәрәне төзеп чыгу безнең өчен бик әһәмиятле. Шул шәҗәрәне төзегәннән соң, аның тарихын караганда татар этногенезы мәсьәләсе бик ачык булып күзаллана. Болгарчылар рухында язылган нәрсәләргә бөтенләй туры килми бу. Башка әйберләр килеп чыга. Бик борынгы элементлар бар. Иң кызыгы шунда: Рәис Яушев шәҗәрәсендәге кайбер шәхесләр «Дәфтәре Чыңгыз-намә» дә дә бар. Анда шундый эпизод телгә алына. Чыңгыз хан кабилә бәкләренә халыкны, җирне, тамга, уранны бүләк итә. Шул бүләк ителүчеләр арасында Рәиснең бабасы да бар. Димәк, Чыңгыз хан төзегән Алтын Урдада боларның үз урыннары булган дигән сүз бу. Чыңгызыйлар кимакларны җиңсә һәм дәүләт эченә кертсә дә, алар юкка чыкмаган, аерым бер берләшмә, кабилә буларак сакланган. Шуңа күрә бу дастанда Бачман солтанның исеме, аның турында мәгълүмат килеп чыга да. Димәк, кимакларның тарихи хәтере сакланган булган.

***– Димәк, Бачман кыят нәселеннән булса да, хәзерге Башкортостан җирендә яшәгәндә төркиләшкән, татарлашкан булып чыга?***

– Алай түгел. Алар хөкемдар булып утырган, халкының эчендә кыпчаклар (бу очракта кимаклар) да булган. Монда Бачман үзе кыят түгел, аның белән бәйле аксөякләр кыят булганнар. Алтын Урданың кечкенә генә микромоделе бу. Сәфәребезнең әһәмияте шунда: татарларның бик күп тарихи урыннары бар. Без шуны аңлап бетерә алмыйбыз. Хәзер «изге җирләр» дип ислам диненә бәйле урыннарны өйрәнә башладылар. Ләкин изгеләр күмелгән урыннар да кайвакытта тарихи шәхесләргә бәйле була. Мәсәлән, Биләр шәһәре янындагы Хуҗалар тавында күмелгән Мәүлем хуҗа, ул, чынлыкта, шушы Яушевлар нәселендәге бер шәхес, Бачман солтанның дәвамчысы. Аның чын исеме – Балын хуҗа. Бу исем «Дәфтәре

Чыңгыз-намә»дә бар. Шуңа күрә бу урын тарихыбызда ислам диненә дә, бөек шәхескә дә бәйле. Ни өчен бу җирне изгеләштергәннәр? Тикшеренүләрем буенча, Хәрәзм дәүләтенә бәйле көнчыгыш кыпчаклар, ягъни кимаклар, инде XI гасырда ук ислам дине кабул иткән булган. Соңрак алар Алтын Урданы исламлаштыруда да катнаша. Ягъни, боларны исламны кертүчеләр итеп тә карарга була.

***– Димәк, болгарлар гына түгел, кимаклар да безнең җирлекне исламлаштыруда катнашкан?***

– Әйе, шулай. Шундый тарихи мәгълүматлар бар: безгә, Алтын Урдага, ислам дине кертүчеләр, укытучылар Хәрәзм ягыннан (Ясәвия тарикатеннән, бездә Төркестаннан дип әйтәләр) килгән. Алар кимакларга бәйле булган. Димәк, алар үз кардәшләре янына килгән. Монда татарларның исламны берничә мәртәбә кабул итүе күренә. Иң әүвәл болгар бабаларыбыз унынчы гасыр башында, аннан соң уберенче гасырда кимак бабаларыбыз кабул иткән, аннан соң Алтын Урдада исламлашу булган. Шулай караган вакытта өч зур чор күренә. Татарга ислам дине керүе менә шушындый тарихи процесс булган. Бер генә дәвергә карамаучы, бик әһәмиятле, катлаулы процесс бу. Шуларга бәйле урыннарны һәм шәхесләрне без яхшы чамаларга, белергә тиешбез. Бәхеткә, археологлар, бу күренешне чамалаган. Мәсәлән, Урал буена монголлар килгәч, анда ислам һәйкәлләре пәйда була. Әлеге археологик һәйкәлләр билгеле. Аларны кайвакыт Болгар ягынан килгән, дип әйтәләр. Бу күренеш кимаклар ягыннан килгән йогынтыга да бәйле, чынлыкта.

*Әңгәмәдәш – Рәшит Минһаҗ*

## Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар

## Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики

### ХРОНИКА

15–17 ноября 2019 г. в Тюмени прошел Форум татарской молодежи Тюменской области, организованный областной молодежной общественной организацией «Яшь буын». На форуме присутствовали также представители татарских молодежных объединений соседних регионов (Пермского края, Свердловской, Омской, Новосибирской областей, Москвы и др.). В рамках данного мероприятия отмечалось также 20-летие Тюменской областной общественной молодежной организации «Яшь буын». Среди его участников были и гости из Казани – доктор исторических наук Д. Исхаков, политолог Р. Айсин, к.ф.-м.н., руководитель Ассоциации «Магариф» М. Лотфуллин, председатель ВФТМ Л. Муслюмова, специалист по работе с молодёжью Молодёжного центра «Идел» Казани З. Ибляминова, выступившие с докладами и сообщениями. По итогам форума была принята резолюция.

* * *

31 января 2020 г. в Ульяновске, состоялся IV форум татарских краеведов области. В работе форума приняли участие краеведы, ученые, представители органов региональной и местной власти, религиозные и общественные деятели, работники областного краеведческого и школьных музеев и архивов, активисты татарских организаций и журналисты местных изданий, представляющие все районы и города Ульяновской области, а также Самарскую область и Республику Татарстан. Среди участников находились академики, профессора, доктора и кандидаты наук, заслуженные деятели науки РТ, заслуженные работники культуры РТ, заслуженные учителя РТ, почетные работники общего образования РФ, авторы краеведческих книг по истории населенных пунктов Ульяновской области.

В ходе форума были заслушаны и обсуждены более 25 докладов, были показаны видеосюжеты об истории и современном состоянии эпиграфических и архитектурных памятников региона.

* * *

В редакции газеты «Казанские ведомости» 7 февраля 2020 г. состоялся круглый стол по краеведению на тему «Татарская городская слобода:

прошлое, настоящее и перспективы развития» (по итогам Всероссийского Форума татарских краеведов «Татарская городская слобода: прошлое, настоящее и перспективы развития (в рамках стратегии сохранения татарских слобод в городах РФ)» в Томске, на примере изучения татарских городских слобод в Казани и Томске).

В ходе круглого стола известные ученые, краеведы, искусствоведы, экскурсоводы, журналисты, представители туристических фирм и префектуры «Старый город» Казани, активно обсудили и ответили на нижеследующие вопросы.

1. Чем актуальна и важна тема, связанная с историей, сегодняшним состоянием и перспективами развития татарских городских слобод в городах Российской Федерации и сопредельных государствах, которую мы сегодня обсуждаем в редакции газеты «Казанские ведомости»?
2. История и основы процесса урбанизации, развития городской цивилизации, ремесла и торгово-караванных связей у тюрко-татар.
3. История татарских городских слобод XVIII–начала XX вв. в Казани, Оренбурге, Уфе, Екатеринбурге, Тюмени, Таре, Тобольске, С-Петербурге, Минске, Павлодаре и других городских центрах Центральной России, Поволжья, Урала, Сибири и других регионов Евразии, их роль во внутренней и внешней торговли Российской империи. В чем причина и основы процветания татарских городских слобод в Российской империи?
4. Современное состояние и перспективы развития татарских городских слобод и городских кварталов (микрорайонов) в местах компактного проживания татар.
5. Татарская городская слобода города Томска как пример развития городских слобод в России. Какова роль и итоги Форума татарских краеведов в Томске в 2019 г. и других мероприятий в изучении, сохранении, благоустройстве, музеефикации и использовании объектов татарской слободы Томска в туристических целях и воспитании молодежи в любви к родному краю?
6. Старо-Татарская слобода и другие природные и историко-культурные места Казани и ее окрестностей. История, современное состояние и перспективы развития.
7. Проблемы дальнейшего изучения, сохранения, активного возрождения, грамотной музеефикации и практического использования исторических мест Казани и других городов Республики Татарстан в рамках развития международного и внутреннего этнотуризма и воспитания молодого поколения в любви историко-культурному наследию и родному краю.

8. Вопросы экологии и безопасности в современных природных ландшафтов и историко-культурных зонах городов, их округи и сельской местности.
9. Проекты модернизации Старо-Татарской слободы и исторических мест Казани, а также других городов и регионов РТ и РФ.

В обсуждении этих вопросов приняли участие А. А. Бурханов, начальник Комитета по работе с краеведами Исполкома ВКТ, председатель РОО «Общество татарских краеведов» РТ, заслуженный деятель науки РТ; А. Х. Габдуллин, туристический оператор, радиожурналист (г. Казань); М. М. Гарипов, архитектор-искусствовед, краевед, автор книг по истории регионов и населенных пунктов Татарстана и Башкортостана, заслуженный деятель культуры РТ, специалист по архитектуре татарской слободы Томска и краеведению Восточного Татарстана и Западного Башкортостана (с. Агрыз, РТ); Р. З. Салиев, ветеран педагогического труда, краевед-исследователь, Почетный работник общего образования РФ, автор книг по краеведению, председатель Общества татарских краеведов Высокогорского района РТ (с. Пановка Высокогорского района РТ); М. А. Корнилов, директор МБУ «Историческая среда» при Префектуре «Старый город» Казани; А. Ш. Файзрахманов, кандидат исторических наук, заместитель председателя Всемирного форума татарской молодежи; Р. М. Хайруллин, директор по развитию турфирмы ООО «Жемчужина Поволжья», член Правления Гильдии экскурсоводов РТ, экскурсовод, генетик, историк (г. Казань).

* * *

8 февраля в Саратове при участии Исполкома ВКТ состоялась Международная конференция «Меценатство в России: история, преемственность, взгляд в будущее», посвященная памяти Эдуарда хаджи Ганеева. В рамках данного мероприятия, собравшего большое число участников – религиозных деятелей, бизнесменов, учёных и представителей татарских общественных организаций ряда областей РФ (кроме Саратовской, Ульяновской, Пензенской) и Республики Мордовия, и Казахстана, состоялись: пленарное заседание, на котором были прочитаны 7 докладов, а также две секции: «Менеджмент благотворительных проектов – региональный аспект» и «Современный вакф и эндаумент». Завершился форум вечером памяти Э. А. Ганеева. В составе делегации из Татарстана, возглавлявшегося руководителем Исполкома ВКТ Р. З. Закировым, находился и главный редактор журнала «Туган җир. Родной край», доктор исторических наук Д. М. Исхаков, выступивший с докладом «Урбанизационные процессы среди татар и формирование татарской буржуазии (XVIII–начало XX вв.)».

* * *

11–12 февраля 2020 г. в райцентре г. Мамадыш РТ, на базе Мамадышского РДК, проводилась Первая межрегиональная научно-организационная, историко-краеведческая конференция «Краеведение в Мамадышском районе Республики Татарстан: история, современность и перспективы развития».

В ходе конференции выступили ученые, специалисты, краеведы, общественные деятели, ветераны и журналисты по проблемам изучения истории Мамадышского и сопредельных территорий бассейна реки Вятка-Нократ, методики изучения и написания истории сел и деревень региона, по проблемам краеведения и др.

В рамках конференции состоялась презентация книг участника ВОВ и штурма Берлина, журналиста и писателя А. М. Малова, посвященных его воспоминаниям о прошедшей войне и истории его родного села.

Председатель РОО «Общества татарских краеведов» РТ А. А. Бурханов провел ряд встреч с коллективами школ Мамадыша и района, в ходе которых выступил с лекциями по проблемам краеведения и истории средневековых тюрко-татарских государств Евразии.

* * *

12 февраля 2020 г. начальник Комитета по работе с краеведами Исполкома ВКТ, председатель РОО «Общество татарских краеведов» РТ, заслуженный деятель науки РТ, профессор А. А. Бурханов по приглашению руководства и педагогического коллектива посетил Мамадышский политехнический колледж – центр профессионального образования РТ. В ходе встречи с группами студентов и преподавателями истории и гуманитарных дисциплин прочитал 2 лекции, посвященные к вопросам развития краеведческого движения, памятникам историко-культурного наследия и изучения истории сел и деревень Татарстана и татарского мира в пределах РФ, а также рассказал о памятниках археологии и архитектуры периода Золотой Орды на трассах Великого шелкового, Волжского и других торговых караванных и водных путей Евразии Востоком и Западом. В ходе встречи был поднят вопрос о привлечении учащихся школ и студентов колледжа Мамадыша и района в рамках подготовки к 100-летию ТАССР и 75-летию Победы в поисковую и краеведческую деятельность, а также в деятельность учебных заведений.

## «ЯШЬЛЕККӘ СӘЯХӘТ» АНСАМБЛЕНӘ УНИКЕ ЯШЬ

2019 елның 21 декабрендә Тубыл шәһәре себер-татар мәдәният үзәгендә «Яшьлеккә сәяхәт» ансамбленең отчет концерты узды. Тамашачылар тулы зал җыелган иде. Концерт башында экраннан «Яшьлеккә сәяхәт»кә багышланган, *«Әйдә барыйк аулак өйгә»* җыры белән бизәлгән, фотопрезентация күрсәтелеп китте.Аннан кызыклы, эчтәлекле концерт программасы башланды. Халкыбызга рухи азык өләшүче «Яшьлеккә сәяхәт» ансамбле җырчылары концертны «Аулак өй» күренеше белән башлап җибәрделәр. «Аулак өй» йолаларын Клим Садыков белән Римма Шәрипова оста алып бардылар. Иҗат дәрьясыннан илһам алучы өлкән яшьтәге җырчылар халык һәм эстрада җырларын башкардылар. Бәйрәм концертын татар халык иҗатыннан уеннар (*«Йөзек салыш», «Тимербай», «Чума үрдәк, чума каз»*), күмәк биюләр, күмәк җырлар, ансамбльдә катнашучы артистлар башкаруында шигырьләр, җырлар бизәде.

Өлкән яшьтәге тамашачылар артистларны җылы кабул иттеләр. Шигырь сөйләүче Римма Шәрипованың (*«Онытылмайтыгын балачак»* – себер-татар телендә), Сөнгәтулла Бекенинның (*«Быел әллә нишләдем...»*), Мәфрүзә Мортазинаның (*«Зарланмагыз тормышка»*), оста җырчылардан – Клим Садыков, Мәфрүзә Мортазина, Сөнгәтулла Бекенин, Мәхмүдә Әминова, Римма Шәрипова (*«Себер татар кызына»*), Сөнгәтулла Бекенинның (*«Елмаеп кара әле күземә»*), Гали Сәитовның (*«Эх, сез матур кызлар», «Кыр казлары»*); Сәхия Ишбулаева; Клим Садыковның (*«Карлы чыршылар»*), Мәфрүзә Мортазинаның, Клим Садыковның (*«Җизнәкәй», «Чияләр»*), Роза Яхина белән Гайния Гаитованың (*«Ярангөл»*), Сөнгәтулла һәм Заһидә Бекениннарның (*«Әйтмә, син, авыр сүз»*), Камәрия Тимированың матур җырын, Клим Садыковның (*«Иртеш буе»*), Мәфрүзә Мортазина белән Римма Шәрипованың (*«Гармун алыйк әле, дуслар»*), ансамбльнең күмәк җырларын, баянда уйнаучы Азат Абдуллинның чыгышларын тамашачылар көчле алкышлар белән каршыладылар.

«Яшьлеккә сәяхәт» ансамбле әгъзаларын, ансамбльнең җитәкчесе Роза Яхинаны бәйрәм тантанасы белән себер-татар мәдәният үзәге җитәкчесе Гөлсинә Ташкеева, Төмән шәһәренең себер татарлары мохтарияте рәисе Динар Абукин, актив җәмәгать эшлеклеләре Әнәс Гаитов, Рифхәт Насыйбуллин котладылар. Алар, милләттләр эшләре буенча өлкә комитеты тарафыннан милли костюмнар тектерергә матди ярдәм бирелгәне турында әйтеп, Рәхмәт хатлары тапшырдылар. Роза апа: «12 ел сәхнәдә булсак та, без тамашачыларыбызны ялыктырмадык. Репертуарыбызны ел

саен яңартып торабыз. Ансамбльне тамашачылар яхшы белә, без Төмән өлкәсенең күпчелек татар авылларында концертлар белән булабыз. Тубыллылар да безне сагынып көтеп алалар. Матур, үзенчәлекле тавышлы, сәхнәдә үзләрен чын артистларча тотучы җырчыларны тамашачылар яраталар. Үзебезнең тырышлыгыбыз белән яңа милли костюмнар булдырабыз. Артистларыбыз татар җыр-моңына гашыйк булган, милләт җанлы кешеләр», – диде.

Концерт программасын Тува Республикасының атказанган артисты, биюче Гыйззәт Әминов, Лангепас шәһәренең «Нефтяник» мәдәният үзәгенең татар бүлеге җитәкчесе, «Якташлар» халык вокал ансамбле җитәкчесе Сирен Хәбибуллинның, аның режиссёры һәм җырчысы Роза Низамованың чыгышлары бизәде.

Концерт тәмамлангач экраннан тамашачыларга багышланган, *«Бәхеттә, шатлыкта»* җыры белән бизәлгән, фотопрезентация күрсәтелде.

Ансамбль әгъзалары: Роза Набиевна Яхина, Азат Абдуллин, Мәхмүдә Әминова, Фәридә Бакиева, Заһидә Бекенина, Сөнгатулла Бекенин, Гайния Гаитова, Гәлҗиһан Закирова, Сәхия Ижбулаева, Мәфрүзә Мортазина, Клим Садыков, Гали Сәитов, Камәрия Тимирова, Римма Шәрипова.

*Римма Шәрипова, Тубыл*

## МИЛЛИ-ФӘННИ БАСМА БУЛАРАК БАРЫЙК*

*(Редакциягә хат)*

Күңелемдә ризасызлык тудырган ике язма да булды, алар – Буадан Рәшид Маликов һәм Казаннан Айдар Хәйретдин хезмәтләре. Болар – ислам диненең асыл нигезләренә каршы язмалар. Үзем редколлегия әгъзасы булмасам, бәлки, бу турыда әйтеп тә тормас идем. Әмма журналда минем дә исем-фамилия тора, димәк, андагы язмалар өчен мин дә җаваплы.

Рәшид Маликовның мәкаләсендә ислам динендә гафу ителми торган гөнаһ – Аллаһка тиңдәшлек китерү гамәле бар. Ягъни, кабер ияләрен арадашчы итеп алып, аларның каберләренә барып, «алар хөрмәтенә» Аллаһтан үзеңә кирәкне сорау. Бу – ислам динендә тыелган гамәл. Ризаэддин Фәхреддиннең дә күпчелек хезмәтләре шушы гөнаһны аңлату турында. Әйе, бу суфыйларда, ишан-мөридләрдә киң таралган, әмма исламга, тәүхидкә каршы килә. Бу әйберләргә уйнап карарга ярамый. Чөнки бу бидгатьне таратуда сәбәпче булганыбыз өчен җавап тотачакбыз. Мин бу язмаларны журнал кулыма килеп кергәч кенә күрдем, алдан белсәм, һичшиксез, каршы булыр идем.

Айдар Хәйретдиннең реинкарнация турында язмасы, ягъни, җаннарның кешедән-кешегә күчеп йөрүе турында фәлсәфәсе, гомумән, саташу, полный бред! Ничек шушындый тузга язмаган әйберне язарга һәм чыгарырга була?! Ничә гасырлар буе Коръән һәм хәдисләрне өйрәнгән, тәфсирләр ясаган дин галимнәре белмәгәнне, татарның бер адашкан фәйләсуфе белсен инде! Аның язганнары тәүхидкә каршы килә, Коръәнне ялгыш аңлата. Аллаһы Тәгалә Коръәндә, гомумән, җан турында артык төпченмәскә куша, бу – яшерен гыйлем, аны Аллаһ Үзе генә белә. Әмма татар тагы «мөгез чыгара» – Аллаһның үзеннән дә уздырып, җан турында әллә нинди әкиятләр уйлап чыгара. Инде егетебез үзе саташу гына җитмәгән, башкаларны да шуңа инандырмакчы була, безнең журнал аша.

Ссоңгысы. Безнең журнал – дини журнал түгел, төбәк тарихын өйрәнүче татар краеведлары журналы. Шул ук вакытта ул динсез журнал да түгел, ягъни, динне бозып аңлатуга да хезмәт итәргә тиеш түгел. Мондый әкият, ырым-шырым, тузга язмаган нәрсәләрне чыгару татар зыялылары каршында журналның бәясен төшерә. Ә Аллаһ алдында гөнаһлы итә. Шуңа күрә, мондый язмалар белән бик сак булырга кирәк дип саныйм.

*Ихтирам белән Фәүзия Бәйрәмова*

---

* Редакция бу фикерләр белән килешми, әмма аларны халыкка җиткерергә кирәк дип саный.

## Төбәк тарихына караган хезмәтләр турында мәгълүмат. Рецензияләр

## Информация о краеведческих трудах. Рецензии

### «СУДЬБЫ ЛЮДСКИЕ» М. М. АХМЕТЗЯНОВА

В Кургане вышло издание известного краеведа, ветерана педагогического труда, почетного работника общего образования РФ, жителя Сафакулевского района Махмутьяна Масхутьяновича Ахметзянова «Судьбы людские» (282 стр., тираж – 300). Спонсорскую помощь в издании книги оказал бизнесмен, бывший глава Сафакулевского района, бывший заместитель губернатора Курганской области Нияз Марсович Юсупов.

Свои очерки и публикации на краеведческую тематику автор начал издавать в районной газете «Трудовая слава» еще в 2012 г. Сейчас автор представил читателю свои рассказы под общим названием «Судьбы человеческие».

В книге, как отмечает сам автор, нет вымышленных героев, все они земляки и коллеги М. М. Ахметзянова. В ней отражены жизнь и судьба конкретного человека, жителя родного автору Сафакулевского района, в том числе судьба окружающей человека природы и взаимосвязь ее с Человеком...

